**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
ЛЕВ ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ

# ЧУВАШСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАТЫР РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫ:

диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары

# ТАТАРЫ БАТЫРЕВСКОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ЧУВАШИЯ

материалы
по диалектологии и устному народному творчеству

КАЗАН 2016

**УДК 811.512**
**ББК Ш 163.23**
**Т23**

**Төзүче авторлар**
Э.Х.Кадирова, Г.Р.Галиуллина, Ә.Ш.Юсупова

**Рецензентлар:**
филология фәннәре кандидаты, доцент А.Д.Батталова
филология фәннәре кандидаты, доцент М.Р.Саттарова

Т23 Чувашстан Республикасы Батыр районы татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары / Э.Х.Кадирова, Г.Р.Галиуллина, Ә.Ш.Юсупова. – Казан: Вестфалика, 2016. – 128 б.

Т23 Татары Батыревского района Республики Чувашия: материалы по диалектологии и устному народному творчеству / Э.Х.Кадирова, Г.Р.Галиуллина, Ә.Ш.Юсупова. – Казань: Вестфалика, 2016. – 128 с.

Бу хезмәттә Чувашстан Республикасы Батыр районының Шыгырдан, Озын Куак һәм Татар Согыты авылларында яшәүче татар-мишәрләрнең халык авыз иҗаты үрнәкләре, сөйләм үзенчәлекләре, гореф-гадәте, халык тарихы һәм тормыш-көнкүреше тасвирланган текстлардан үрнәкләр бирелде.

*Издается в рамках реализации мероприятия 3.5.2. Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014 - 2020 годы»*

© Э.Х.Кадирова, Г.Р.Галиуллина, Ә.Ш.Юсупова, 2016




## КЕРЕШ СҮЗ

«2014-2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г. Тукай исемендәге татаристика һәм тюркология югары мәктәбе студентлары һәм галимнәре катнашында, Чувашия Республикасының Батыр районында яшәгән татар-мишәрләрнең рухи мирасын өйрәнү максатыннан, фольклор-диалектологик экспедиция оештырылды. Шыгырдан, Озын Куак һәм Татар Согыты авылларында булып, биредә яшәгән халыкның тел үзенчәлекләрен, фольклорын һәм этнографиясен өйрәнү, аларны туплау юнәлешендә эш алып барылды. Тупланган материаллар арасында тарихи-этнографик характердагы язмалар, халык авыз иҗаты үрнәкләре, халыкның тормыш-көнкүрешен чагылдырган текстлар бар. Сайлап алганда аларның төрле эчтәлектәге һәм төрле торак пунктлардан булуына да игътибар ителде.

Экспедицияне оештыру һәм мәгълүматлар туплауда ярдәм иткәннәре өчен, Чуваш Республикасы Батыр районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениесе «1 нче номерлы Шыгырдан гомуми урта белем мәктәбе» директоры Абейдуллова Гелсирин Гаделҗан кызына, Чувашстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте аппараты җитәкчесе Хайбуллов Мансур Мәсхуд улына, безне хөрмәтләп каршы алган, сорауларыбызга ачык һәм төгәл итеп җавап биргән, күңелләрендә йөрткән мәгълүматлар белән уртаклашкан кадерле Шыгырдан, Озын Куак, Татар Согыты авыллары халкына рәхмәтебез чиксез!

## ЧУВАШСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАТЫР РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘМ ҮРНӘКЛӘРЕ

### *АВЫЛ ТАРИХЫ, ТУГАН ЯК ТУРЫНДА*

[урыннарыбызнымы / шул бикшек йулында исеңдәме // кас′ы йулны әт′әләр / анда изге / алты нарат асты диләр // бишет йулында / ул безнен ызын куак йулында тигел// әбиләр/ әниләр укыган вакытта шул алты // багышлыйлар иде инде //алты дийәләр идеме инде// тебендәге изгеләргә дийеп // кайан ул сугыш заманында күмелеп нителгәнме инде// нәстәдер шындый сүз әнәйләрдә җери иде ул // ну хазыр ул ынытылып бара дисәң дә була // мыни әле сез изге дип сораучы булганга гына искә теште ул // алты нарат тебендәге изгеләргә дип багышланган//]

*Информант: Апанаева Минҗиһан Халиулла кызы, 1946 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[сарымсак күп булган дип сүлиләр иде мыни // әнәйләр/ канн′ам // имештер йанында бик каты күп сарымсак үскән дә// сарийә әптәй шылай дийәләр иде бит // сарымсак бикүп үскәнгә күрә мыни / ни инде чисновка диләр бит инде// шылай атамасы калган инде //]

*Информант: Апанаева Минҗиһан Халиулла кызы , 1946 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[туган аwыл турында бик каты җырлар чыгара идем // туган йак тарта бит инде ул // туган йагым турында бу җырны ишеткәнегез йук // җырлап бирим әле//
ак былытлар кайа агыласыз //
җилләр белән кайсы йакларга //
сезнең белән миндә агар идем //
кат′ыр идем туган йакларга //
кат′ыр идем инеш буйларына //
туктар идем таныш тауларга //
җылы йаңгыр булып йаwар идем //
сезнең йакта үскән талларга //
иртә таңнан әңкәй элеккечә //
ак керләрен элгән кыймага //
сийләнмәгән бөтен шатлыкларны
сийләр идем кайтсам мин аңа //
сийләнмәгән бетен борчуларны //

сийләр идем кайтсам мин аңа]

*Информант: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[безнең аwыл иң иң элгәре мында килеп / беренце безнең аwыл ул кайандыр мәнә мәскәү астыннан бик җырактан килеп урнашканнар мында // безнең аwыл шындый ул бик күркәм/ бик берсенә берсе булыша тырган / бик берсен берсе җаклый тырган булган // берсендә нәстә дә булса нитцә// шылай шыгырдан беренце шыгырдан /икенце шыгырдан / арйак / бирйак / безнең йак мында инде беренце шыгырдан / икенце шыгырдан / убы йагы / арйак// барына да исем кушылган авылларның инде //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[әнәйләр сүләwе буйынца // ул җиде күл / әнәйләр сүләwе буйынца / җиде күл кецерәк кенә булган ул// шул йылга / йылга үтә // йылга йанда анда бер күл формасында бер ни күл кебек инде ул // күл // анда теңне ни йана торган булган / турыфда ут йана торган булган // аны безнең әнәйләр белмәгәннәр // шайтан дип уйлаганнар // шайтан мыни тенне утны кабызды // шайтан йандыра дип белгәннәр // действительны безнен җирдә нифт булган // ескәрәк күтәрелеп / ницектер үзенә үзе дийәргәме инде // тенне йанып утта күренә торган булган // ул кендез дә йанган да / кендез күренмәгән инде ул // тенне күренгән // бу безнең әнәйләрнең / ул әнәйләр үлгән инде // алар сүләwе буйынца // җиде күл ницек барлыкка килгәнен белмибез инде анын // анда сулар зыйыла иде // керләр йуарга йери идек // тазга / ул вакытта су йук// вадакачка суы йук // кый[1] сулары йук // мыни хазерге заманда сулар ескә күтәрелде диләр // ескә күтәрелде су // кыйларыбызда да / кизләwебездә[2] дә су аллага шекер нитеп тора // ул вакытта йауса / йаңгыр суы белән кер йуган / йаумаса / шул җиде күлгә бара идек // җиде күлгә йылга буйы белә әл′әнеп / аннан соң иген[3] аша йул салдылар инде // сукмак салдылар // шул сукмактан барып / керләр йуып / керләрне берсәк[4] шында бәләп / элеп шыннан апкат′а идек // хазыр ул җиде күл дигән анда именный күле җиде булмагандыр // ник җиде күл дигәннәр соң инде // ну анда җиде хазыр // казылган җиде // кецерәк кецерәкләр алар // основной

[1] кый – кое
[2] кизләү – чишмә
[3] иген – басу, кыр
[4] берсәк – бераз

зур бер // анда кышлар[5] киләләр терле терле // аист та бар диләр // анда хазыр куаклык // куак круговой гына ул // ну анда кышлар күп //]

*Информант: Даутова Рузалия Алимҗан кызы, 1961 елгы,*
*Чуваштан Республикасы, Батыр районы*

[безнең awыл бик шындый күркәм бик ни тату йәши тырган awыл булган // балык йылгасы дип атала майлы йылга // суы шындый йымшак булган // йымшак булган // аны кер йуганда да күп вакыт вакыт йуарга булган // сабыны цыгып бетәлмәгән // шуңа күрә аның исемен майлы дип атаганнар // майлы йылга //аннары сың тагын нинди йылгалар бар иде әле безнең / балык җылгасы / кәчем йылгасы // шылай исем кушканнар инде // исемен кушканнар ул кәчем йылгасы аның суы бик бик тәмле булган // безнең awыл зур шул / зур awылга суы бик күп булган / суы тәмне булган // кәчем тәмәткән[6] / кәнфит тәмәтә тырган су дип әткән дә берсе шуннан киткән ул кәчем йылгасы дип шылай аталган // бер сүз генә цыккан инде // халыкка шылай гына кирәк бит инде ул // кәчем йылгасы дип аталган // аннары сың тагын нинди йылгалар бар әле // меслим йылгасы / кәчем йылгасы / аннары балык йылгасы // аннары тагын елгәре бер маурийә атлы карцык булган // ул маурийә әби инде бик бик күп күп йыллар йәшәгән дә аннары сың бер дә чирләмичә генә үлә дә китә // мәүрийә әби мәүрийә үлгән/ мәүрийә үлгән дийәләр дә йылга мәүри йылгасы дип калган // шындый атамнар[7] булган инде елгәре // нинди нәстә урынына йарый шынарга куйа белгәннәр //изге урыннар бар меслим буйында // анда ул батырдан килгән урман бар бит безнең канаштан килгән вакытта // анда ни меслим йылгасы дип атала // ул меслим йылгасында бик шылай изге йылга изге меслим йылгасы // аннары сың меслим йылгасы // аннары каракитә / карабау йылгасы дип аталган // теге йылгасының суы бик куйы ни булган / куйы булган / куйы суы кара күренеп тырган //ул җылга карабау дип аталган / выт шылай исемгә кереп калган инде ул // аннары сың тагын нинди йылгалар бар әле / кәчем йылгасы // кәчемне әт′тем бугай инде // меслим йылгасы // аннары меслим йылгасы меслим йылгасыннан сың тагын ике йылга булган урман йанында // ул кура йылгасы дип аталган // бик куйы суы булган // суы күп булган // аның йанына оланнар бармасын дип кура[8] тотып куйганнар // ул кура йылгасы булып саналган // гел шылай исем куйганнар инде // ехе// хәрберсенә дә бер исем булган аның // шылай иттереп берсе белән берсе бик тату йәшәгән / хәзер дә

[5] кыш – кош
[6] тәмәтү – тәм кертү
[7] атам – исем
[8] кура – киртә

тату безнең аwыллар тату // бер циләк бәрәңге булса инде мени / бер примир / кешенең тегенең йук ашаргасы / кил әд′ә циләгеңне тыт та кил / шылай бергә бергә бергә бергә зыйылып ашый тырган булганнар // аннары сың сыр′ катыклары елгәре пугар′апләр[9] булган // пугарәпләргә инде кем дә килсә дә шул бабай булган баш // кемгә бирегә / кемнең авыррак тырмышы анарга бирә // тешергә күбрәк иттереп// шындый берсенә берсе күркәм йәши тырган аwыл булган безнең елгәредән үк берсенә берсе булышып //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[тагын бер кәберлек бар/ керәшеннәр кәберлеге// керәшеннәр булган безнең аwылда// керәшеннәр шул кәберлеккә күмелгән // керәшеннәрне килеп йортларга килеп инде теге үзләренцә эшләп киткәннәр // безнең татарларны да шулай чукындырма теләгәннәр дә алар идән астына тәреләрен алып цыкканнар // и аннары сразу йәшереп куйганнар // шул каберлек тора безнең керәшен кабере // мазарлык[10] дигән сүз йук бездә // менә күрше аwылда безнең анда мазарлык // безнең бу йак йагыбызда чуwаш аwылы бар анда да мазарлык // бездә мазарлык дигән сүз йук // бездә зийарәт / кабер бар // ташка йазалар // хәзер ташка йазалар // хәзер инде рәшәткә тоталар // аннары кайсы берләре рәсемен дә куйдылар / рәттән генә бара // бар бар шылай // безнең әтиләр дә бер тирәдә / алар инде урын алып куйалар // аңа катыны үлсә ире урын алып куйа// йәнәшә күмелә инде алар// нәсел генә дибез инде без //]

*Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

[мин кувакалова галийәбану абзал кызы // мең тугыз йез алтмышынцы йылның сигезенце окт′аберендә чкалов аwылында туып үскәнмен // мең тугыз йез җитмеш сигезенце йылны ун класс петердем / казан дәүләт университетына укырга кердем // шушы институтны бик йакшыга гына петереп / үзебезнең чуаштанга ал′анып кат′тем// бер фамилийәләр турында бер историйә сүләп үтмә келим // безнең фамилийәләр ницек килеп цыккан // безнең аwылда фамилийәләр кушаматтан килеп цыккан // без чуашийәдә йәшибез // безнең шул фамилийәләрыбызны / чуаш телендә кушамат фамилийә дигәнне белдерә // безнең фамилийәләр дә шул кушамат сүзеннән цыгып бызылып петкәннәр // мыни / например / берәр пример китерсәң инде / мацы // ул безнең фамилийә булып тыра нидә / шыгырданда // ә кушамат чуаш телендә туже фамилийә //

[9] пугар′ап – кар базы
[10] мазарлык – зират

шул чуаш писыр′лары безнең фамилийәларны менле кушамат дип фамилийәларны шылай бызганнар // табер шындый фамилийә мыни / например / куакал // куакал ул татар телендә безнең / мишәр телендә кушамат / ә чуаш телендә фамилийә кушамат // кайан цыккан ул куакал фамилийәсы // әби бабайларның сүләwе буйынца / безнең әби белән бабай бик күп үрдәк тытканнар // шул бер аны чуаш мужигы инде сүләп күрсәткән / шул кешләрдә бик күп үрдәк бар иде / бердән бер кенне шул үрдәкләр ыцып киткәннәр // бабай цыккан да икән үрдәкләр кайа китте / кайа китте // бер чуаш узып бара тырган булган // кывакаллар ыцып киттеләр/ ыцып киттеләр дигән // шыннан инде безнең бабайга куакал дигән кушамат тагылып калган // шыннан инде балалар тугацтан инде / йаздырырга тешәләр дә метрикага / чуаш писаре сырый инде / бабушка менле кушамат[11] // куакал // значит куакалов // ике балага шылай куакалов фамилийәсы бирелгән // олы балага да инде / икенце балага // шыннан сың күпмедер үткәцтән инде / ике бала тагын туа да / тагын тешәләр батырга / ә / чыкалов районы булган әле ул бахытта / батыр районы булмый / шыгырдан чыкалов дип аталган ул бахытта // сырыйлар инде / ну / менле кушамат // куакал / ул бахытта инде чуаш берсәк грамытныйрак була / фамилийа дип сырый // фамилийәгез ницек дигәцтән / шарафутдинов дип әт′еп бирәләр // шылай иттереп ике бала / еценце белән дүртенце бала шарафутдинов фамилийәсен алалар // выт шылай семйада дүрт баланың икесе кувакалов / икесе шарафутдинов булып киткәннәр // без дә инде шул әби белән бабайның ылы баласының / абзал балалары кувакаловалар // ә в харефе кайан килеп естәлгән // әпәт кывакал дип сүләп киткәннәр дә / шыннан в ны да естәп куйганнар // шылай иттереп фамилийә кувакалов килеп цыккан // ул безнең белүебезцә // аның историйәсе может үзгә терледер кувакалов // ә бу шындый бер ривайәт сакланып калган // шул кушамат буйынца бирелгән фамилийәләр безнең аwылда бик күп // мәсәлән / мацы / куакалов / бүре / кара карама / санап китсәң / бик күп инде алар / да / кушамат буйынца киткән фамилийәләр // кушамат инде / урысца ал′андырганда кличка / кличка белән киткән фамилийәләр шыгырдан аwылында бик каты күп // да / кас′е берсе инде бегенге кендә аларны алыштырып та маташа / мацы / мацы фамилийәсен алыштырдылар үзләренең бабаларыннан калган исемгә // ну күбесе сакланып калган / алыштырмыйлар / шылай тыра // ул инде тиге историйә / шынарга күрә аларны алыштырмасаң йакшырактыр да / санап китсәң / андый фамилийәләр бик күп //**]**

*Информант: Кувакалова Галиябану Абзал кызы, 1960 елгы,*

---

[11] менле кушамат чув. – фамилиягез ничек?

*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ул җирләр бар инде // исемнәре / безнең ишәк оцы бар инде // шында йылга инде // чиснук йылгасы // сарымсак йылгасы инде ул // сарымсак йылгасы безнең арттан да үтә иде ул // анда кыргый сарымсаклар күп үсә иде // анда кыргый жен′шеннәр бар йарларында // без йарларында шылай ун′ап йери идек инде // элек булган инде ул / хә алай күргән йук // елек бит андый куркыныч ниләр дә бар // йүер апа сейли / цәй суына / йылга аша цыктым да дир // ислам бабайлар арты дигән кизләү бар // су сысам дир алдымда багана дир // ул багана ызынайа ызынайа бара дир // бу мында багана йук иде бит // ник багана ызынайа икән дир // үземнең нәстә белгәннәрен укыйм укыйм дир // таудан менеп киттем дир // шыл багана басып калды дир // әгәр менеп китмәгән булсам дир / белмим нишләткән булыр дир // тенге сәгәт унике дир // ташлы йылга бар безнең // күлләребез бар // чишмәбез кирәмәт дип атала //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[безнең урман эчендә шындый урын бар / җенне прачак дийә идек // йулаш күпере бар // адаштыручы// без кузгалак җыйырга бара идек / оланнар[12] / кузгалак җыйырга барабыз да шул җенлепрачакка// ак ат җиккән бара / бара / без барабыз // бара / бара / без барабыз / ак ат тоттырмый / ад′аштык// аннан шул җенлепрачак диделәр// аны глуфта шуны сүли бит инде/ ахун бабай йулында ул / ахун бабай йулы бар безнең урманда // ахун бабайлар мени шул урман эцендә аwыл мәзине булган / ул нәрсәсе диләр әле ыстаростамы / аннан шыгырданга барып мәцет эшләре белән шул ахун бабай йулыннан барганнар // элек бик кацып йергәннәр // барыга йарамаган төрмәгә итәләр / укырга йарамаган / кацып укыйлар иде безнең бабайлар // айетләр укыган wакытта кешеләрнең азбарында кацып нитеп укып / гырыф гадәтләребезне саклап нитеп килделәр әби бабаларыбыз// ахун бабай шуннан кат′канда туңып үлде // ахун бабайның мәцете бар // аңа мәцет салдылар // менә безнең праwадан төшкәндә туптуры ахун бабай мәцете // йураш күпере дибез инде/ ике аwыл арасы / ад′аштыра торган инде шындый // мәрсәлим бар безнең / мәрсәлим // изгеләр күмелгән / безнең тау буйы изгеләр// безнең аwыл аша сугыш // тимер акцак мәле ницек/ алар менә безнең йылга буйы белән үтеп тимер аксаклар/ шыгырдан әллә нәстәләренә барып цыкканнар сугыш белә // шул wакытта анда безнең мәйетләр бик каты күп / йылга арасында бер кәберлек бар //]

---

[12] олан – бала

*Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

## СУГЫШ ХАТИРӘЛӘРЕ

[кырык икенце йыл ахырында / кырык бишенце / ай / кырык еценценең башында нимец сталинградны алды // шыннан тытыныйкмы // выт шыны беләм мин // тарихтан да беләм / былай да беләм // шул йылны аның ни фельдмаршалы паулес иде / анарга памагать итүце / ул окруженига калгац / аны кыткарырга килүце манштейн иде // выт безнең самый ышаныцлы фельдмаршалын гитлер безнең зур шәхәрләргә җибәргән инде/ алырга// мәскәүнекырык беренцейылны алалмадылар/ аны белмим индемин/ просто историйәдән/ аны тарих укып белергә булдыраласыз// кас′е йылны дисәң / кырык беренце йылның декабер айында/ җигерме икенце декабердә беренце атпур бирелә / мәскәү астында/ беләсеңме шыны // ник бирелә ул / ник бирәләр аны / нәстә ецен / кем булышлыгы хакында // выт шул бахытта жуков петен армийәне шында зыйа / теңнә// кайа булган армийә барын да мәскәугә җибәрегә / барсын да мәскәү астында атпур бирергә // утыз киламитр / җикмеш километр / җигерме километр гитлер армийәсе мәскәүгә керәлми // укыдыгызмы историйәдән или нидән русский языктан панфиловцыларны // йукмы // выт генерал панфилов / генераллар исемендә инде ул / шынарга задача куйа / нимец илле танкы белән мажайский йагыннан / тигейак инде ул / мажайско волакаламский шоссе диләр аны/ сыңгы аплот/ шыны кергән булса/ мәскәү бирелә // анда безнең унике мең апалченцы тыра / лакан алийә әптән үлдеме / белә идеңме шыны // выт ул анда / шында / апалченцыда // аңныйсыңмы // кертмәскә / живуй щит / шында тырды / тырган // аның сүләwе бу/ бу аның сүләүләре күбесе // выт гитлер хазер давай живуй щитны атмыйк дир инде / атмаска нитәләр / алар акоп казыйлар пративатанковыйларны // уwак түәкләрне инде зыйештырып тыралардыр дигән кебек / кен дә инде шында кара каршы атышалар да / кешләр үлеп тыра / насыйлка белән ташып тыралар / йагага[13] / үлгәннәрне//]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[мәскәү белән ленинград арасында вечный глубокий балуты булды // выт аны керер ецен кайандыр абхадит′ итеп керергә нәстә белән булса да / гусеничныйы

[13] йага – чит, кырый

да бата // мыни хазер исеңә тешерәм инде / бу алийә эптәйнең әбзәсе вәли әбзи иде / танкист иде ул / аны мыни сыңрак кына таптылар / недавны / бер биш йыл тому назад // йуные слидопыты / сезнең кебекләр // танкысыннан шул / мәскәүне каулагацтыр[14] инде пажалый / ехе / мәскәү астыннан атпур[15] биргәц / ленинградны асвабадит′ итергә барганда / безнең анда бер күпме диим инде / миллион да алты йез дә / миллион да алты йез дә җигерме микән / булырга тийеш / халык / тул′кы выт нийен белмим / бу танкылары күпме икәнен / шул танкы белән шул балутыга тешәләр / ату булса инде утыз мең балутыга тешә инде ату булса / кыскасы утыз мең // шул балутыда аларны следопытлар әле таwып алдылар // шының / шул бәли әбзинең кесәсендә пистунчик була / ул пистунчик / несгарайымый пистунчикны беләсеңме // адресны тыгып куйалар// бу сугышка кергәндә үдә булган адресны тыгып куйалар // ә ул адреста безнең адрес була / патамушты безнең / синең әтәң илхан бит инде / әтәсе абзал / абзал әбзи белән хат алыша тырган булалар алар // абзал әбзи ул бахытта армийәгә китмәгән әле // бу кырык бер кырык икенце йылларны сүлим инде // иртәрәк сүләдем // бусы инде кас′е кина / кас′е сүләгәннәре / кас′е шул бәли әбзинең сеңелесе сүләгән / алийә эптәй аның сеңелесе ул // выт шында хат йазган / әбзәй белән хат йазышып тырганнар / выт шында әбзәйнең адресын тыгып куйган // шул адрес белән мында килде запрос / тапканнансың / күмәргә киләсезме // күмәргә килергә хазер алийә эптәй сиксән / туксанынцыда булгандыр // зәкийә тужы / нурулла әбзи анда үлгән иде бугай инде / аның браты инде ул/ аның кеце браты мәскүдә тыра иде / хазер үлгән / шазад бармады // шылай итеп аны братскайа магилага күмделәр //]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ул ниләрне карама келәсәң ыржев фронтында күренә инде бу / кинадамы / китаптамы / ыржев астында була бу // ни патамушты ыржевтан күп узалмыйлар/ ленинградка баралмыйлар / абаронада зак йәшиләр // ә линингradны беләсеңме нәстә ашатып тырды андагы халыкны // ә // су аша / су аша / ладыга күле аша / да / ладога күле аша / ни дарога жизни / да дарога жизни / выт бусын да этик инде / солдатлар арасында безнең чуашийәдән камсамол′ский районнан щерби аwылыннан бер чуаш бар иде / кат′т′ы ул сугыштан / шул / аларга азык ташуцы / шул азык ташыган полуторка машинасын алып катте / шул машина белән кат′т′ы / без аны карарга бардык // выт фамилиләрен исемнәрен белмим / ә кызык ецен йазып куйарга йарый /

[14]каулау – куу, куалау
[15]атпур – каршылык

камсамол′ский районнан сюрбеево дигән аwылдан чуаш / палуторка машина белән кат′т′ы // шул/ шыларга ладыга күле аша азык ташыган кеше ул // выт/ ул ладыга күлләренең ниләрен йулларын инде без шоферлар тигел белмибез // аны су сибеп туңдырып тырганнар / цыбык ташып тырганнар / үстереп тырганнар / штубы судан йугарырак китсен дип // нимец бамбит′ итеп тырган / ике йагын хаман ишеп тырганнар аның / шындый халләр иде инде // кайа тагын нәстәсеннән цыгыйк // беренце удар мәскәүдә / икенце удар нидә / безнең унмы / умберме удар/ шылар турында укыганыгыз бармы / юкмы // кецле удар / берсен генә әт′әм хазер / исемдә калганын / карпатта // карпат таwын үткәнегез / күз алнына китергәнегез бардыр / ул орел шәһәреннән быргаланып тытына / гдиты курский дуга дигәнне белгәнсездер инде / курский тирәләреннән ал′ана // мин әле машина алырга барганда / шында бардым инде //]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[тарих сүлим мин күбрәк / аннары сың мындарак / йакынрак килербез // миллионный армийә / ник миллионный армийә тытты // потому что гитлер бит инде мәскәүне мында алырга выт выт ала дип тыралар / акружит′ кына итәлми / бамбит′ иткән булса / ала иде ул / усын да аны дерес йазырга кирәк / бамбит′ итмәде ул // сталинградны алырга тытынгац / бу йагына цыккац атпур бирергә тытынганнар диик инде/ паулесны акруженига[16] алдылар бит инде йез утыз мең армийә белән // аның самолетлары безнең аша узды / шыны аңныйсыңмы // безнең аша // аwыл аша / точно аwыл аша // анарга рамка дийәләр иде / ул машиналарга / рамка / әпәт рамкалар килде / әпәт рамкалар килде // алар ни карап йергәннәр / нәстә диләр инде / разведка / халык нәшли / нинди хал′дә/ халыкны бамбит′ итәрлекме тигелме // халык анда үгез белән алма[17] утырта или тартып утырта // выт мыни алар барыбер инде аwыл халкына керә // нимец самолеты биккаты таwышлы иде / без мыни җиргә йатып шылай җылый идек / выт шылар килгәндә / бер үгез бар иде / урамда бер инде ул / кем алма утырта / азбарда[18] инде ул / тизрәк тартып цыгалар / как будто бы кешедип китмәсеннәр/ халык тарта дип / алты кеше тартып алма утырта иде / үгезне цыгаралар/  үгезне җигәргә / үгез белән имештер нитәләр / ә кайан нитәсен/ сука ике тәртәле тигел иде анда / бер тәртәле / уртадан бер тәртә / аркылы ец тайак / ец тайакта икешәр кеше / ницә кеше була / ике дүрт / алты кеше инде // алты булгандыр инде / икешәр тайак ецәр кеше / алты кеше булгандыр инде или тугызмы / шул чама /

[16]акружени – чолганыш
[17]алма – бәрәңге
[18]азбар – абзар

просто ни генә инде ул ницек әт′им инде маскировка / ә фактически тартып утырттылар // үгез җигәргә ике тәртәлене юк иде // сука башы тытуцы кыскатын[19] иде / кемнәр здоровыйрак кыскатын / пат′ зәйтунасын белә идеңме / выт шының әптәсе / астагы урамда / выт шының әптәсе мәликә әптәй бар иде / выт шул сука башы тыта иде / утыртасыңмы син / цыгарасыңмы / сызасыңмы / цыгару йук иде инде / цыгару калак[20] белән / сызу бар иде / сызганда шул сука башы тотуцы иде / кем генә булса да / кемгә генә булса да / үзебезнең тирәләргә / тагы тигендә тагы кемнәрдер бар иде инде / мин вис аларны барын да белмим / кецерәк мин / йәш // выт хазер шул самолетлар узганны хазер сүләргә кирәк // безнең врз / вагоно ремонтный завод бар / хазер канашта / әл дә бар ул әл дә бар / сугыш бахытында да анда снәрәдләр цыгарганнардыр инде // казловкада безнең снәрәдләр цыгарган завод бар / усы аның җир астында булган / ә бу врзны бамбит′ итте шында / шул бахытта / значит зур завутларны бамбит′ итәргә аларга тул′кы // ә казловкада / район безнеке / беләсең бит инде / аста булганнык белән / анарга йазып куйган булган инде елеке картофил′ный склад / әгәр нитсә дә / тешерсә дә картофил′ный склад йазылган / шыннан кецерәк кенә тишек кереп киттә / цыккан турлары тиге йактан / самолетлар тиге йактан ыцып ыцып цыкканнар // бу тишектә бернәстә дә йук / каплап куйганнар да // аннан сың вайынный завод бар иде чапайывский паселокта / аны инде сыңгы бахытта реелтехнический завод дип исем бирделәр / кас′ыдыр әлегә кадәр / әле / бомба цыгаралар алар / снәрәд / бомба цыгаралар // аны испытыват′ итәләр алар / каждый кен / иртә белә сагат′ дүрттә ецтә // әле белмим / совет заманында иттеләр ату булса / мыни сиксән бишенце йылга хатле // чабаксарда кардиологический центрны бомбит′ итте / центрны тигел / ызданйыны / тагы үзгәцәрәк аның исеме бар иде / ике йаташлы / ец йаташлы деревянный ызданйы иде ул / мин барган анда патамушты // йерәк карыйлар иде анда / волга кырыйында // анардан да зур бийек ызданйы булмаган инде / шыны бамбит′ итеп китте / шул рамкылар диик инде // эзләп йери ул зур завутларны / зур завут анда нидән украинадан күцергән электро аппаратурный завут иде инде // ну аны сталин нийе буйынца дийәләр иде инде / бер йаташлы гына йасаганнар / петен тәрәзәләре маскировкада // тыра ул завод / эшли әле дә // карлы маркс урамында / бу йак кулда // выт шыны бамбит′ итәргә барган ул // үзгәләрен петенесен магнитогорскийга күцертте инде ул / андый күцкәннәр күптер инде ул / ну бу зур завод санала инде // шул снәрәдләр / бомбалар цыгарды / ә казловкадагы / аны беркем әтергә булдыралмый / мужет ул тарихка йазмаганнардыр // самалетлар ыцырып цыгарды // варужат′ итеп цыгардымы /

---

[19]кыскатын– хатын-кыз
[20]калак– агач көрәк

самолетларны үзе цыгармагандыр димен инде / варужат′ итеп цыгаргандыр / ну бомбалар йасадылар козловкада // ул әле дә хазер ниндидер картофил′ный база булып санала/ алма[21] склаты булып тырды ул //]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ул җирләрдә булган мин / үзем / личны // анда җирләрне серәлмиләр иде әле / кырык / илле / алтмыш ике / алтмыш ец бардым мин / шында да асколкы белән тулган иде // тертеп тутырганнар колючий проволка белән тытып тытып алганнар // патамушты трактыр керәлми / ниләр белән генә / резиновый ниләр белән генә / ә ул бахытта әле резинывый тракторлар йук иде / кул′асалы // әлеге мыни касимсотлар / ниләр // выт шының ецен шындыйларны таwып кайандыр алып / шылар белән серәләр иде / серделәр инде мин анда уражайда булганда / мин анда бер ике ец ай тырдым // барыбер кендә ту берсе шартлый / аның калганы бар бит инде / кайан зыйып петерәсен // ул бит безнең кыр гына тигел / гдето җигерме утыз миллион гектар // шындый чамада // анда казыган траншейләр бар / шул траншейләр тулук су / аларга хазер волгадан су качат′ итәләр // ә нине / сталинградның шул ниләрен / артын алган бахытта придател саткан // нимец пехотасы килгәндә / йулны күрсәткән / кайан керергә / кайа акоп казылган / кайа казылмаган // выт усы да бар // аның да кешесен дә күрсәткәннәр иде / йыртын да // анда каптинка дигән пас′улкы бар иде / шул жигулевский районда / барын да ыныттым // ец йез дә илле йырт белән булган ул // анда бал′ницасы нийе / бар да / күбесе белән булган // без барганда ул калган иде җигерме биш йырт барлыгы // бал′ница да йук / йәслә дә йук / ышкул да йук / бернәстә дә йук // гдето йанаша аwылга барып эшлиләр иде // алтмыш ецтә мин бардым / выт алтмыш ецтә дә ул вастанавит′ ителеп петмәгән иде // сталинград турында әтик инде // сталинград ул смищен ул город аска таба // ницәдер километрлар / унец ышл′уз анарда / ышл′узларны үзең представ′ инде / мин аларны барын да тикшереп йеремәгән // парахудларны туктатып тиге астан цыгара тырган ниләр инде алар // аннарсың дом сержанта павлова дигән бар // китапларда бар ул / историйәдә бар // шының турында / шының йырты музей буларак тыра // ник ул дом сержанта павлова // сержант павлов аны защищат′ иткән үзенең нийе белән / салдатлары белән // шул домны таки җимереп петерәлмәгән / җимермәгән / выт / плингә дә ләкмәгән // выт шының ецен анарга дом сержанта павлова/ әледә тыра ул / как музей / әлегене әт′мим / алтмыш еценце йылны әт′әм инде мин уже // выт шул турларда сүлим мин //

[21]алма– бәрәңге

крымда инде мәнә ницек җиңүләрне мин йакшы белмим / анда мар′акларның заслугасы күп / шул мәнә мин аның ецен мама җизнине сүләткән идем бахытында // шул миндус абыйыңның әтәсен // ул анда брежневның йазганы да дерес / ул бит инде безнең брежнев гинерал′ный секритар′ булган кеше / дерес ул // иртә белән бернәстә йук иде / кицкә таба петен ни тулган дир нимец белән / без дир суга тешеп елгердек дирме / җирдәгеләрне вис кырдырды шул фау один белән // выт керч′та дир бер кеше дә калмады дир // бу җизни сүләгәннәрне сүлим инде // анда шул безнекеләр/ маряклар җиңгән инде // ул еценце удар дип аны кина күрсәтте / третий удар // ә карпаттагыны әттем инде / анда хазер мин аның танкы исемнәрен ыныткан // елеке йүрый[22] йазып куйган идем мин / патамушты мин аны ник йаздым / ник беләм // без камунис илле тугызынцы йылдан бирле // ә безгә ул ай саен ни йасарга иде / нәстә диләр әле/ инфармация // кем нәстә турында йакшырак белә // ә мин күбрәк сугыш турында эрәнңән[23] / сугыш турында салдатлардан да сырыйм // кызыксынңан инде // аwылга да килеп йасыйлар иде / кайа да инде / бал′ницта да үтә иде // выт шынарга күрә мин аның канкритно ниләре белән / даталары белән беләм // шының турында күбрәк сүләргә булдыралам // аwыл турындарак кирәк булса инде / аларны сүлим хазер / тытынам хазер // аннары инде сугышларны тигендә барганын күп белмим инде // безнең шының ецен бу карпатта җиңә / орелда безнең нимецкә каршы танкыны палтара раза күп куйа // разведка эшләүнең файдасы // әгәр кара каршы гына куйган булсалар/ алар җиңә / патамушты аларның танкы кецле / аларның тигыр дигән ни иде / ул бардыр гдето ун тунны / ә тиге бардыр кырык тунны // выт тигыр/ үзгәләрен белмим мин // ну ул тигырның арткы йагы слабы була/ алны аның мыни мышының киңнек / бернинди ни дә алмый / ә арт йагына килеп безнең шул менеп китә тырган булган даже / уничтожит′ итеп цыга тырган булган / артыннан ут тертсә / беркайа да китәлмәгән // үзе бик каты т′ажулый / неповоротливый булган // карпат таwында анда как раз тәкә кебек йерергә безнең танкылар йакшы худ биргән инде // выт шул условийәсе бар инде //]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[халык фронтка азык бирде / каждый аwыл / каждый район / каждый кеше // игенме / әпәйме / алмамы[24] / ыйыкбашмы / кизитекме[25] / былай итекме[26] /

[22] йүрый – махсус
[23] эрәнңән – өйрәнгән
[24] алма – бәрәңге
[25] кизитек – итек

батинкамы / бүркеме[27] / нәстә булдыраласың // овес / овес зыйабыз да // мыни бу аwыл хале инде // аwылда булган хал′ // аны заталар иде ибрәскә башта / аннары канашка затканнардыр / патамушты салдатлар да ибрәстән китте / йезәр ат китә иде инде // каждый калхуз ат асырый иде инде / үгез дә асырый иде / атны суйарга йарамый иде / усын да әт′ик // суйарга йарамый / выт шындый хал′ иде // кешедә асырамагандыр инде ул / белмим / ну калхузда суйарга йарамый иде // җир тешләп үләләр иде кас′е бер бахытта / ашарга җитмәгән бахытта инде / ну суймыйлар иде / мин беләм әле дә гердыш дигән атны // ак ат иде бер // халыкның ул сугыш бахытында кырахмал ашауларына тытынсак тагын // халыкның үзенең ашаргасына булмаса да / безнең калхуз / асубы безнең аwыл турында сүлим / сугыш бахытында илленце йылга хатле илле беренце йылга хатле калхуздан бернинди иген / ашарга алмады // ә кырда пешереп ашату бар иде // калхузның ысталаwайы бар иде / эшли иде / мыни бу алийә әбиең дә эшләде инде анда // аwылда әпәй салалар иде / хафизова хапҗамал / сәнәт әбзи катны / сәнәтне белә иденме/ рауф әбзәңне беләсеңме // рауф әбзәңнең әнәсе әпәй сала иде безнең урамда / кезәй зәйдук анасы / белмисең инде син аны / берцә сәйрийе/ бырцак зыйасының катны / аксяновларның ыруын беләсең / шыларның / әпәй салуцылар айырым / халык ецен / кырда эшләгән халык ецен // теш цагына[28] ашарга итәләр иде/ уракцыларга/ кул белән уралар иде // ат белән / ике атны бер сабанга җигеп / сабан серәләр иде / шының белән себеркелиләр[29] иде / жнейка бар иде/ кул белән урганга тагын жнейка дийәләр иде / ницек әт′им инде / ат атлап урып бара / ат атламаса урмый инде // выт аңнадыңмы // шындый нәстәләр бар иде / шыларны ашатырга / ат белән дә инде күбрәк / бригадир да бар инде/ кем ницек елгерәлә / патамушты бит анда урак уруцы да бар / сабан серүце дә бар / тагын кезге цәцүне дә бар / жнейкасы да бар // барын да ашатып йериләр иде // күбрәк инде салма[30] пешерәләр иде / бырцак салмасы или ул бик каты әремне иде / сартиреват′ итәргә йук ай/ кырда әремне кул белән зыйып йериләр иде цыгып / утау дигән нәстә бар иде/ тамыры белән алырга дийәләр иде// йәшләр анда пыцак алып баралар иде / кецерәк кенә пыцак // кайан аны тартып аласың / ул мышының хатле / лан[31] ашамаган // кисеп алып / җир белән тигезли идек / тигеләр күрмәгәндә дийеп инде // шылай зыйалар иде // әптәй[32] дә барды безнең

---

[26] итек – резин итек
[27] бүрке – бүрек
[28] цак – вакыт
[29] себеркеләү – тырмалау
[30] салма – токмач
[31] лан – бала
[32] әптәй – әби

/ минебану апаӊ дигән кеше барды // выт аныӊ белән мин бардым / шыннан белдем мин // син дир кецерәк кенә пәке алып бар дир / мин дә алалмыйм аны дир/ бастырып калдырырга йарамый наса[33] әле // шырт/ мин китәм дә / кисеп алам инде / выт шул аwыл тормышлары инде // аннары сыӊ аш итәләр иде шул салма инде / ә салма булмаганда / элекеге куашналарны[34] син представит′ итәлмисеӊ инде / дүрт циләкле булгандыр инде ул / шылай казып йасадыларминде аны / такта белән йасадылармы // ну куашна инде / мицка[35] дибез инде хазер / ну мышыныӊ бийеклек ул / мышыныӊ бийеклек / мышылай бик каты зур ул // шынарда быргак[36] пешерәләр иде инде / халыкка итәргә // аны бригадир да итә инде / тагы шул итүце кешләр бар иде / булгандыр инде анда // аларны белмим хазер // шыларны ашатып кат′алар / ашатып йериләр иде// трактарислар ашаткан заманны белмисеӊ инде син // трактарисларны да кырга барып ашаталар иде / мыни минсәйетнеӊ әнәсе ашатып йерде // аннарсыӊ эптәсе ашатып йерде әле аныӊ мисәдәсе / мисылу да баргандыр әле // ул сыӊыннан инде / элеге заманрак / ә башта петен халыкны шылай ашатып йерделәр // кем урагын нурмасын петереп[37] тутыра ундүрт сутый / анарга әпәй / түгәрәк әпәй ул / үдәге / уртасы тишкан иде аныӊ / мышыныӊ бийеклек // выт шыныӊ дүрттән бер элешен / кем инде күбрәк нитсәме йартысын // бер кисәген тигел / бер елешен / дүрткә бүлеп // сабан серүцегә тужы / әгәр сабан серүце күбрәк нитсә / анкын мыннан ала идем / хапҗамал эптәйгә менеп / хапҗамал эптәй бүлгәләп бирә инде // сәнәт әбзи бригадир иде / ул кат′ара иде свудкыны / выт шынарга шыныӊ хатле / шынарга шыныӊ хатле // бер бригадада унике унец сабан серүце бар иде // мин шул үз пурцымы апкат′ам инде / әнәйнекен тагын / безгә әпәй вот так бун′нан // мыни кеше йәшәр ецен эшләгән // выт шылай ашатып тырды ул // ә былай иген бирмәде / айыт[38] фәлән булган бахытта җил тирмәне[39] бар иде мышында / зайытларны пристав′ / шыларныӊ бакца башыннан тагын бер йез илле метр җил тирмәне бар иде // выт шында калхуз игенен сала иде инде / шул быдайын / арышын/ нәстәдер бутап инде / атмул дигән кебек инде / шыннан тарттырып дүрт килаграм иген бирә иде / айытка // халыкка // үзеӊнеке булса / үзеӊнекен дә итеп саласыӊ шында / син башак зыйасыӊ анда / башак // башакларны зыйган булса / зайа[40] итеп йатмастан /

[33] наса – бит
[34] куашна – күәс чиләге
[35] мицка – мичкә
[36] быргак – борчак
[37] петереп – бөтенләй
[38] айыт – гает
[39] җил тирмәне – җил тегермәне
[40] зайа итеп – әрәм булып

бездә кул тирмәннәре дә бар иде / кул тирмәне дигәнне ишеткәнең бармы // кайадыр күргәнсеңдер мужыт // музейда // ике агац / аннары тимерләр суккан / кулга тыткыц куйган / мышылай ал′андыралар иде инде аны // бу урамда кемнәрдә булганын йакшы белмим / пыркаларда бар иде бугай / түбән урамда мацы зыйасында / аларда бар иде // теңнә[41] тарттыралар иде / мында шул дүрт килаграм ул / йылга ике айыт // теләдең нәстә пешереп аша шынардан // малатилка дигән нәстә бар иде / былар урак белән келтә[42] ура / да бит // аны салдатка куйалар / салдат[43] диләр // әбийең белә инде аларын / камарийә әбийен // шул салдатлар кибә / аны зур атка куйалар / зур ат дигәне / эстәл тесле мышылай йаткызып куйалар / аны аннарысың малатилка сугарга бара / ул малатилканы тешле трактыр / ул йук хазер / рәсемдә күрсәгез генә / шул естерәп бара / шыны белән бергә / шынарга римин белән шул малатилканы естерәтеп / суктыралар иде / шул келтәләрне / кас′ы бер турда[44] цыйп[45] белән дә сугалар иде / цыйп дигәннәрне тагын күрмәгән инде сез/ музейларда күрсәгез генә // ә шыларны малатилкага күцерәләр иде тагын // аңнадыңмы// иртә белән кас′ы цакны кат′алар алар / или кетү куырга или сыр′ларын саwырга // аннары сың тагын / ланнарны тагын йаwып калдыралар // мин күп бахыт йәсләгә йередем / ну йәсләдән кацып кат′а идем мин // кецерәгрәк цакны ике кат булды ул // беренцесен шул бик каты йакшы белмим / чапайка нуртдинының атасы бригадир иде / хайертдин бабай дигән кеше // анарга утырып барыр ецен йәсләдән кацып кат′а идем // аны нуртдин әле беркен дә сүләде миңа // түтәлләр арасыннан дир / кеше күрмәсен дип // мине килеп йылатып йылатып күтәреп китәләр иде эзләп / эзләп йериләр иде йәслә рабутниклары // ә шул ризыкны тешкә кырга апбаралар дийә идем бит / шул хайертдин бабай дийә идем инде мин / хайертдин бабайның лаwында[46] хаман шул куашна[47] инде // ул җылы / барганда аның йанда бер җыклап китәм / тигендә барганнан сың / шыларга елеш бирә / әпәй апбара анда барына да / әпәйләрне анда бирә ул күбесенә кискәләп // ниләрен черпак[48] белән салып бирә / петә / бар/ улым ецена кер / ецена кереп шул куашнаның / мин сыдырып сыдырып[49] ашыйм да / шында җыклап китәм // тагын/ ул кат′кац / мине шул куашнадан цыгарган да / бик каты

[41] теңнә – төнлә
[42] келтә – көлтә
[43] салдат – көлтәләрдән өелгән чүмәлә
[44] тур – вакыт
[45] цыйп – чылбыр
[46] лау – олау
[47] куашна – күәс чиләге
[48] черпак – аш чүмече
[49] сыдыру – сыпыру

йымшак кеңелле иде / кҮтәреп Үгә кертеп куйган // әгәр кайа булса мине апбаргысы кеәмәсә / мин аның йанна менеп утыргац / мин / улым йәсләгә барырга шул беген / йәсләгә барырга дип әт′ә иде дир // усын белмим / шыпырт лау артыннан тешеп калган мин // икенце йерегән бахытта / икенце кат йередем / кырык ецтән сыңдыр / әбзәй армийәдә иде / абзал әбзи дигәне // аннан беләм уже // йакшы ук беләм // анда американский пайук дийәләр иде / калхуз ни бирсә әлеге / ашамый идек/ тиге кырга барган әремне нине / американский пайукта аппак деге иде / сахарин иде / сахаринны нәстә икәнен беләсеңме // шәкәр урнына / алар нәстәдән йасап биргәнне белмим инде // мыни примерно китерәм / кубинский шәкәрне ашаганың бармы // пачкалы шәкәрне/ суга тыгу белән изерәп китә / шыны ашаганың бармы // выт шул формарак инде ул// әз генә ызынрак тул′кы анардан/ анардан сладкыйрак / аwызда заграк тыра инде // сахарин дийәләр иде анарга // американский пайук // аннары сың хрупчатка[50] дигән ын биргәннәр // аны әнәйләр сҮләгәнен сҮлим усын / аны хрупчатканың нәстә икәнен әт′әм хазер / ак ын инде ул/ әле ак ынны саталар / высший сорт дибез бит / ул хрупчатка арыштан йасалган иде ул//]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы,*
*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## *ЫШАНУЛАР, СЫНАМЫШЛАР*

[тешкә ышану бар / ышанабыз // ырымнары бар // бура кҮрсәң Үлем була диләр // безнең мени мин наприимир кыйыдан су соссам / мәйет йуырга була // һәрвакыт мин аны сынап киләм // кыйыдан су сыстым / мәйет // аны китапта да әйткән шылай / теш йурый торган китапта // ат кҮрсәң хабәр / ак ат булса Үле була диләр / салам кҮрсәң кайгы диләр / атка утырып китсәң Үлем була диләр/ пешмәгән ит кҮрсәң / чир була кайгы була // төш кҮрсәк ходайга багышлыйбыз / тешеңне кешегә бик сҮләмә диләр // дошманнарың булыр арада // сҮләмә кешегә / лутше Үзеңдә торсын / су алып китә инде// ул да дерес // су алып киткән начар булганда // йахшысын гына йазсын инде безгә // нацар булмасын инде// төшләр алар аннары бик рас та килеп керә // бер тешемне сҮләсәм йарамый торгандыр инде/ мин төш кҮрдем // бер мәшхәр мәйданында кеше җыйылган // мәшхәр мәйданы кебек инде шылай ул′ыйм мин аны // хәзер безнең дәфтәрләребез кҮккә очты // мәшхәр мәйданында кеше зыйылган // матур гына сылу гына бер ир кеше килде дә / сезгә диде матур дәфтәрләр бирәбез диде // дәфтәрләр китереп куйдылар // миңа әт′ә сеңлем ди / бу

---

[50] хрупчатка – арыш оны

дәфтәрләр / миннән башка кагылма диде// мин кетәм кетәм ул кешене кач′ан килер дип / ул кешем килде / килде дә дәфтәремне ацты да/ йаңа дәфтәремне бисмиллаһи рахманаһи дип дәфтәремне башына йазып куйды // хәзер мин шул мәшхәр җиреннән цыгып барам // цыгып барам да матур гына сылу гына кыс катын[51] кебек кеше инде/ укый беләсеңме кызым диде // иншаллаһ дидем без сүз белән // мин диде сиңа сәдака китерәм диде / син укы диде// миңа мәйтәм ике шаһит кирәк мин укырмын син белмәсең мин укыганны / ике шаһит бар дидем // шылай ул шаһитлар мине тыңлап тордылар да / шул мәшхәр җиреннән цыгып барганда / бер әби / матур гына әби / зур ызын селге тыткан / уртасына әпәй[52] / матур әпәй инде шындый / китердем / мә / кызым / сиңа бу диде/ шуннан соң мин шул төшемне күргәннән соң нистә дә әйтергә белмәдем // кешеләргә дә сүләргә курыктым // сүләмә диделәр андый нине // аннары шыннан хаджга барырга йул булды // хаджга барып шулай мәккә мәдинәләрдә йөреп кайттык унынцы йылны // шул тешем шылай йуралгандыр дип үземә инде үземә йахшы теш инде да //]

*Информант: Салихова Шәмсеҗиһан Расыйх кызы, 1947 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

[йаңгыр булмаса/ бикаты йаңгыр теләге йасыйлар иде// йаңгыр теләге йасагац / безнең әнәй / основной/ бутка пешерә иде казанга// ни белә ын бутап// башта зыйалар иде йырт сайын// йымыркадыр нәстәдер // аннары сың аны бер әби пешерә иде// безнең әнәй йымырка мужет йымырка да зыйгандыр// ни ыннан бутап быламык пешерә иде // бер казанда йахшылап пешерә иде // ыннан инде ул // да / бутап // тызын сала да инде / нәстәсен сала да инде // аннан сың кецерәк ланнар[53] инде / без шикелле ланнар // укуцыלармы ниләрме // суга цыгалар да кайа су бар // циләкләренә тутыралар // карап тырмый синең матур / йәмне[54] кийенгәнме / йәмсез кийенмәгәнме // без йаңгыр теләге йасыйбыз дийәләр иде дә // мин үзем дә виласапит белән үткәндә йугары урамда естемә вис шыбырдатканнар иде циләк белән // ни су сибәләр ескә // йаңгыр теләге йасап инде // ну ул вакытта бер әби кеше карт кеше укый инде укый тырган кеше укып тырыга тийеш // укый // аннан шул ланнар / шул йаңгыр теләге йасап йерүце ланнар йылга кырыйына зыйылалар да берсәк[55] нәстәдер җәйәләр

[51] кыс катын – хатын-кыз
[52] иген – басу, кыр
[53] лан – бала
[54] йәмне – матур
[55] берсәк – бераз

дә / шул пешергән буткаларны инде // йымырка зыйалар дир мыни рузалийа // йымыркаларны пешреп / йаңгыр булсын дип / теләк булсын дийеп инде //]

*Информант: Даутова Рузалия Алимҗан кызы, 1961елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[аннан безнең wакытта тагын йаңгыр йаwмаса / йаңгыр теләге йасый идек // йаңгыр теләгәндә инде без бер укымышлы әбине аппара идек // бабайны // укымышлы әбине аппарып ул укый // без анда сулар җыйып инде // безнең аwылда су бик йук // йылгада буалар бар иде// шыл буадан инде есләргә су сибеп ун′и идек // шылай аннан йаңгыр йаwа иде инде// әби укый иде / алла биргән теләкләр кабул булгандыр // ул әбинең укыганы // әйтәләр иде инде// алла бир алла бир // йаңгыр бир // йахшы йаңгыр / начар йаңгыр бирмә дип шылай җырлыйлар инде//]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[әгәр дә лан[56] каты курка икән / анарга курку кыйалар // моның эцен курку кыйуцы әбиләр йанына алып баралар // курку кыйар эцен кургашин кирәк / кургашинны савытка салып эретәләр дә / ланны эскәмәйгә утыртып / баш эстенә савыт белән су куйып / кургашинны суга салалар // суга тешкәц кургашин бер форма алып катып китә // кургашин кыйган әби шул форманы ланның нәстәдән куркканына йурап әт'ә // аннары соң нәзек җеп белән бәл'әп / ланның бун'ена[57] бәлиләр // ул үенә кат'ып җиткинцә тешеп калырга тиеш // куркуы петмәсә ланның / тагын бер кат кыйалар // шыннан соң ланның куркуы петә[58] инде //]

*Информант: Кувакалова Найлә Загирҗан кызы, 1956 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ышанулар // әгәр ала карга кыцкырса инде багана башына менеп // хат хабәр була дийәләр иде // аннан әгәр тәрәзә пыйаласына кыш шакыса / тагы хабәр була дийәләр иде // исән саw хабәр булсын дип теләк тели идек инде// йахшыга йурарга инде // йахшы булсын бар да исән булсын инде/ шылай йурый идек // җиде белән сигез арасында мунца керергә йармый диләр // уникедә туже мунцага барырга йарамый диләр инде / берәw генә туже барырга йарамый инде // бер ике // йырт ийәләре бар // мин үземнең кызымнан беләм // аның

---

[56] лан – бала
[57] бун′ – муен
[58] петә – бетә

квартирыннан шылай эшкә киткәндә / безгә кайткан wакытта // һаман йырт хужа йыртны йахшы йахшы сакла дип әт′еп калдырам дир // сизәм аның барлыгын дир // аннан үзебез дә шылай йатып тырабыз // ыстенада сәгәт йук // цың цың сәгәт суккан кебек тыра // сәгәт йахшы сукса йахшы була дир // иске идән минекне[59] ийәртеп цыгарга кирәк // минек аласың // идән себерә тырган минек // әйдә йырт хуҗам шынарга атлан // без йаңы игә күцәбез дийеп // тагын бер кызларымның үзләренең йыртлары бар иде // күцтеләр // кызыма әт′әм / минек ал кызым // шылай әтеп цык / шылай кывартираларына күцерде // шылай уйлыйбыз бит инде йылалар булгац хайwаннарның ийәсе туже бар // мин кецкенәдән әни белән әтинең сүләгәнен беләм // әни әтигә керде дә әт′ә // берwакыт безнең атлар бар иде // карале дир // безнең атның цәцен тагын үргән бит дир // хайwан хуҗасы инде бу дир // әгәр хайwанны йаратмаса ни хайwаннарның хуҗасы // аны тене буйы кыйный дир // ат инде чистый тиргә бата дир // ә бу шул цәцен үргән // минем ишеткәнем бар шылай // үргәнне үзем күрмәдем // әнинең ике кат әйткәнен беләм // йараткан йырт хуҗасын шылай үреп куйа дир // әгәр йаратмаса кыйный дир //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[әби әт′ә иде сынамышлар // әби күп сынамышлар белә иде// әтәсләр кыцкырса йаңгыр була // менә бер кенне мәтәм кунакка бардык та әтәсләр кыцкыра еценце кен // йаңгыр булырга тийш алла теләсә мәтәм // әтәсләр кыцкырды ул wакытта // әтәс кычкырды дерестән дә йаңгыр булды // аннан суң әбиләр әт′әләр иде тагын нәстәләр күп күп // аннары әби тагын нәстә дийә иде әле // күп күп сынамышлар бар // шылай итсәйе шылай була // шылай булмасаң шылай була // йәкшәмбе кенне тырнакларыгызны кисмәгез / чәршәмбе кенне киссәгез шайтан тырнагы үсә // дерестән чәршәмбекен кисеп карыйм да шайтан тырнак үсә / тущна / наказат′ итә аллаһы тәгәлә // анарысы тагын нәстәләр инде// кискән тырнакларыгызны пискә бәрегә или идән йарыгына ташлагыс // дөнйалыкта кел бул / ахирәттә гел бул // мин синнән сорамыйм / син миннән сорама // каршыма килмә / кийамәт кенендә // әбиләр әт′ә иде шындый сынамышлар // шындыйлар бик каты күп булган келеп үлә торган //да анан суң әби әт′ә иде/ карале карга килеп кунды / безгә кыскыра // и кайгылы хәбәр булмасын / хәйерле генә була күрсен // карга кыскырганны күрсә // хәйерле хәбәр хәйерле хәбәр дийеп кыскырырга кирәк иде// әби карга кыскыра хәйерлехәбәр хәйерлехәбәр//]

*Информант: Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*

[59]минек – себерке

*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*
*Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[сынамышлар андыйлар бар / андыйлар инде биген җангыр йава ахры мацы тәгәри җирдә / аннары икенце кенне хазер тагын биген йаңгыр була ахры былытлар катлам-катлам икегә айрылды / куатлы яңгыр / хазер былыт тенйактан цыкты йәшенле йаңгыр була // әйтемнәр бик күп булган бик бик килештереп килештереп сүли белгәннәр алар үзләре / матур иттереп // аннары сың / кыйда су агара башласа салкын була икән / шындый әт′емнәр булган бик бик//]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

**[**куцат кыцкырса нәстә була диләр // ырымнар нәстә әле / тагын бар // кычык уласа кеше башына дир // кычык уласа кеше үлә // ашап утырганда кашык тешсә инде кунак килә дийә иде / пыцак тешсә ир килә / вилкы тешсә дышман килә //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## БАЛА ТУУ ҺӘМ БАЛАГА ИСЕМ КУШУ ТУРЫНДА

[исем куштыруны бабайларны дәшәбез // аны бабай укый инде / бер бабай мендәр өстенә бала куйа да / исем куша // анан бәби бәйрәме үткәрәбез инде // да / бәби бәр′әме дип атала // элек инде баштан бәбәйне апкайткац мунца керәләр иде // цәй эцәләр / бүләк бар иде инде // бәбигә дә әнисенә дә // бәбигә йаwлык / әнисенә күлмәк // әллә ни зур әйберләр апкилмәдек // минем бишек җырын әллә ни җырлаганым йук // ниндие телемә килә // шуны җырлыйм // ак күлләрдә килә ак болытлар/ и аллам бетереп тор әле ыныттым //
исемнәре исмегел //
уртасында бер цәцәк бар //
гел дә синең тесле ул //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[балаларга исем куштыру булган / елгәредән ук булган балаларга // пример мени биген бер кыскатын бала тапты / аның хәр бер ец дүрт кен үтә бер исем

кушалар бу балага нindiйе кирәк // алийәме / санийәме / галийәме / исем кушалар анар бер атнадан аны бик зур бәр′әм йасыйлар // бәбәй бәйрәме дип атала ул // мында барын да йәшә / күршесен барын да йәшә /кемнең халеннән килә керәләр бар да шылай // бәбәй бәр′әме дип атала тырган булган ул бик зур мәзлец булган //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[балаларга муллалар килеп куша исемен инде // әтәсе сайлый / кас′ысын әнисе сайлый / былай айрым айрым шул кеше килеп сайлап утырмаган / үз җыртындагы кеше сайлаган / ну күбрәк инде мулла кушкан шылай //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[җиде сигез малайны бер кендә кисәләр иде// бишеккә айакларын бәл′әп куйалар да анасы карый инде // пудрасын сибәсең дә тыра инде // сеннәткә утыртканда бүләкләр алып килмиләр инде // анда инде бер йакының тыта аламы // кемнең йерәге каты шул тыта инде // малайларын сеннәткә бирү бар иде инде // әле дә бар инде ул //]

*Информант: Раҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Шыгырдан авылы*
*Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## УЕННАР, УЕН ҖЫРЛАРЫ ТУРЫНДА

[бармак уйынын инде безнең йәшрәк wакытта булган хәлләр инде алар // хәзер бу йегет дир бусы кыз дир // хәзер ун′ап барганда җырлап барганда // кызга килеп цыгамы йегеткә килеп цыгамы // нәстә[60] әйтә шул бармакны бегеп кала // аннан тагын нәстәдер эшләп кала //
кулымдагы йезегемнең исемнәре әкрәм //
аклы күлмәгең бар икән // иңнәренә тар икән //
аккан суың туктатырлык мәхәббәтең бар икән //
ал син ал хазер бармагыңны // син хазер шул җегеткә шуны әйттең ди инде мәхәббәтле булдың дир //

[60] нәстә – нәрсә

аклы йаwлык бәйлә дустым //
аклы йаwлык килешә //
аклы йаwлык бәйләгән кыз
мырадына иреша //
син әйтмәдең // җегетең әйтте инде сиңа // кемне йаратасың шыны хатерләп кертәсең инде күңеленә // үзеңнең күңеленә кергән җегетнең исеме//
йезегемнең кашы теште алырсың микән алка //
булырсың микән үземә калырсың микән йатка //
син әйттең инде хазер быларга // алып куй //
ки кылак алкаларыңны
кылагың кийләнсә дә //
сей сийәсе йарларыңны
дышманнар сийләсә дә //
хәзер бу әйтте инде сиңа // җегетең сиңа // ызын бармагы йегет тегесе кыз була инде //
сандал кийеп кенә белдем //
чирәмнең салкынлыгын //
айырылгачдин гына белдем
дусларның кадерлеген //
бу миңа цыкты ич инде // хазер мин калдым инде апәт // җәза була инде хазер нәрсә булсын // нәстә йырлыйм инде хәзер // таwышымда карлыкты инде хәзер таwышым да бетте // күйе дә йук хәзер / маниры да йук //
агыйделгә тешеп йудым
ак кына беләгемне //
хасрәт уты чырнап алган
йәш кенә йерәгемне//
эх тала тала тала икән беләгем
нигә тала нигә йана икән минем йерәгем //
агыйделгә басма салдым
кайынны сайлап кына //
йаннарыңа барам әле /
кыш булып сайрап кына //
эх тала тала тала икән йерәгем
нигә тала нигә тала икән минем йерәгем //
агыйдел сулары булсам
уралып агар идем //
йаңгыр тамчылары булсаң
алдыңа тамар идем //

эх тала тала тала икән йерәгем
нигә тала нигә тала икән минем йерәгем //]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[безнең йылгада күп балцык бар шул балцыкны шарлар йасый идек кецкенә кецкенә // аны дүртләп куа идек // аннан кулга ала идек // аннан тиз генә кулга алып сикерттереп // барын да кулдан тешермицә ун′асак / җиңүче була идек // аннан урамда ни уйный идек // тигез урынга тәңгәлдәш[61] дийә идек // безнеңчә // аны сызасың шакмаклар // анда шылай бер аннан тагын дүртне сыза идек // түгәрәк банка каплаwычлары белән аны тертәсең // сызык кайа тисә / син уйыннан чыгарыласың // уҗе үнгә[62] кеше керә // әгәр һәр күзенә кереп барса/ теркәч / ул индеҗиңгән була // әгәр сызыкка еләксә / ул индеуйыннан чыгарыла инде// йәза бирү йук индешылай бер уйынчы кереп кенә бара // аны безнең кызлар уйный иде // без андый уйыннарны белмәгән // безнең кызлар урамда латарийлар // кызлар күп иде безнең // һәрбер йортта бишәр дүртәр алтышар бала бар иде // алар латарийлар ун′ап / әйберләр алып / кем ыта инде ана бүләкләр бирәләр иде //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[үскән wакытта дәңгел[63] дигән уйын ун′и тырган идек // ызба камышны[64] әйттем дәңгелне әйтми калдым // менә шылай урамга дәңгел кебек итеп сыза идек // менә шылай сызып бара идек // анары былай сыза идек // шакмаклап // дүрт биш шакмак йасый идек шылай // ике йактан да биш шакмак унау була иде // аннары менә шылай ишектән кергән кебек нәстә сыза идек // былайтереп куйа идек // сызып күрсәтсәң йарый инде былай белмисез бит әле//]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[мышылай кыругом каргалыш[65] ун′и идек / мышылай кар кар кар кар / урамда ун′и идек // түндәк алыш[66] ун′и идек/ мени шылай урамда // хар ун′амыйлар бит / кызым // безнең әнәй алты лан үстерде // әнәй эштән кат′а иде дә безнең белән

---

[61] тәңгәлдәш – уен исеме
[62] үңгә – башка
[63] дәңгел – уен исеме
[64] ызба камыш – уен исеме
[65]сәләмә – начар
[66]түндәк алыш – түмгәк алыш

цыгып мени шылай кар кар кар алыш ун′и идек мышылай // безнеӊ әнәй биккаты йәш′ли килгән / атасыз үскәннәр алар // әнәй ул кийәүгә килгән дә кецерәк кенә мышылай карзинка белән кырчак[67] тийәп килгәннәр ун′арга кырчак// кан′ам белән кырчак ун′и идек дир мышылай // аннарысыӊ ике килен тырдык дир//]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[цырнап йери иделәр пиленкага мени шылай // бу кырчак була бит инде // аннары аны адийалга цырный идек // шылай ун′и идек // кырчакларны аннары йыклата идек инде // анда аннары кецерәкләрен кецерәк йаулыктан йасап йанына йаткыза идек // шылай ун′и идек инде // былар да шылай ун′аганнар инде/ мында нинди кырцак булган //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ай әле сүләп петердегезме // башта сүләп петерергә идегез // беләләр инде минеӊ нәстә җырлаганны // апа шул җырыӊы җырлале диләр // җилфер җилфер дим дим // укачуклар дим дим // ник җилферди җилдә йук // сезнеӊ кебек дим дим/ йакын дуслар дим дим / авылда тигел җирдә йук // сезнеӊ кебек дим дим / йакын дуслар дим дим / авылда тигел җирдә йук // тан берне генә җырлыйм / куплетны гына // җилфер җилфер дим дим // җилнеӊ исеп китүе // петте йаӊлыштым[68] // әби кешләр[69] шылай була инде ул // йабалак мәрзийә әптәй[70] булса/ быларны рахатләндереп җибәрә иде // җилфер җилфердим дим // иткән чакта дим дим // җилләр ача кун′ымны // йанып / кейеп дим дим / йергән чакта дим дим // дуслар ача кеӊлемне // мышул дусларым ачалар кеӊлемне // йанымдагы дусларым шылай кеӊелемне ачалар // рахмәт //]

*Информант: Араева Сәкинә Хөснетдин кызы, 1937 елгы Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[ак күк кирәк уйыннар ун′и идек // кара каршы унар унар кеше барасын // и ак кирәк күк кирәк сездән безгә кем кирәк // безгә менә шул кирәк дип әт′ә идек инде // анда краскалар инде шылай йәшә идек тә // анан шылай тагын кара

[67]кырчак – курчак
[68] йаӊлышу– ялгышу
[69] кешләр – кешеләр
[70] әптәй – абыстай

каршы ун′и идек // ынтылып та беткән инде / анда күп ун′и идек // шул бер җыр җырлый идек //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[йезек салыш /сукыр тәкә /аннары ыркача[71] сугыш / шындыйлар иде анда // ецтә кыз /тышта йегет йарык аша сүли идек анда инде // терле халләр булып беткән // сукыр тәкә // күзне бәлиләр дә анардан каца петен кеше // шул була ул // ызбада инде ул // аннары тагын берсен тытып алсаң ул сукыр тәкә була инде / аның күзен бәлиләр / ул эзли // шылай дембер дембер цапкан инде шылай / анда кас′ы краватка да менеп баса инде / шындый инде ул сукыр тәкә // аулак ейдә инде ул //]

*Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы*
*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

## АУЛАК ӨЙ УЕННАРЫ

[кызлар зыйып йаткан вакытта аулак үзгә терле була иде ул // пирвай инде без анда зыйылабыз / безне килеп йәшәләр[72] // синең кызыңны аулакка йәшәм ди / аннары барабыз инде без күлмәгебезне түwенгә тытып барабыз /тигендә кийә тырган күлмәгебезне / ә естебездә кен дә кийә тырган күлмәк // анда барабыз да тишенәбез[73] дә / матур гына кийенәбез дә тезелеп утырабыз // аннары җигетләр килә // җигетләр килде дип хуҗалардан сырыйлар да безне пиц алдына кертеп тутыралар иде // ә пычмакка /ехе// аннары җигетләр керә дә инде / тезелеп утыралар да гармун белән бийетәләр // бер бер тешеп бии идек аннары без / пыцмактан цыгып / бер бер генә // аннары инде бер шикелле булгацтан / ул вакытларда бишәр алтышар тештә дә аулак була иде / ул вакытта шындый аулак күп була иде // анда инде кемнең җараткан җегетеме / кемнең җараткан кызымы / шындыйлар гына сайланып кала башлый инде актыкка таба // әлеге йарыктан сүләү актыкка таба булмады инде // йанаша утырып сейли башладылар // шылай тату ун′и идек / әгәр кызын бирмәсә кулына әллә ницә кат сыптырта римин белән // мының кызын мин сырыйм / бирәсеңме дир // бирәм дир // хазер алыштыралар // бирмәсә кулын куйа да римин белән кын′илар / сугалар римин белән ницә кат // кат кат та сырыйлар/ барыбер алма келиләр // шылай кан′ап петә идек инде // ул йәш цаклар кайадыр хазер // артта калды //

[71] ыркача – зур күн бияләй
[72] йәшү – эндәшү
[73] тишенү – чишенү

пычмактан чыгып биибез генә // аннары сың инде җырлаулар анда / бийүләр инде // җигетләрнең кайсысы үңгә[74] аулакка китәләр // кызлар да цыгып утыралар инде // җигетләр дә шында була // аннары кыруг ун′и идек дүрт багана ецәрләшеп // аннары сың инде гармун белән тагын бийетәләр инде // пирвай җигетләр бии // пирва кызлар тигел // кергән җигетләр бии спирва // тагын кул сүтеш ун′и идек // икәү икәү тытынышып баса идек тә // мени күрсәтик әле // кызык уйын инде ул // кызлар җигетләр шында инде бар да / анда цыккан кешене алып китә инде // безнең вакытта урлаганнар // мине урламадылар / үзем киттем // мыни мәүлидә мыртазина бар бит шыны урлап киттеләр // шындый цибәр җигетләре калды / мыртаза урлап китте // минем йараткан кийәвем ул // мине шындый йарата ул // мыни шул мендәрне цикте / ницек циккәндер инде белмим // аның малайы бар иде // тенә[75] сабан туйында бик җырлаганнар // ул безнең аwылның йезек кашы инде // дерестән дә / ул туйга бармаган йырт йук / бетенесе свидетел′га йәштеләр аны // ну үзе барма келәгән җигетенә баралмады инде // ну хазер йахшы тыралар инде / матур тыралар // шул армийәдән кат′ты җигете / кыз йук / кыз мында үзгә ырлап китте бит инде // да утыртты да китте // мана мында хазер ни малайы артыннан килгән // ни малайы / кем малайы әле/ мухтяров тигел / әле анардан сың классташы // нурбайзә әптәйнеке инде малайы / кецерәк малайы килгән дә / беренце кенне ашадылар // икенце кенне килгән бу бар әле энем йәшеп цык әле канциртка сүләшәбез / канцирт куйарга сүләшәбез // бу бит артист иде // аның аннарысың ай керде дә йәште дә мәүлидә сине анда дир артистлар йәшәләр дир // ай үзе мәүлидә артыннан килгән // йәшеп цыкты да утыр дип әтте дир / утыр да сүләшәбез дип әтте дир // утырдым да дир шафир инде әллә тешәсезме дип әт′еп тыра дир машинаны кабызмый дир // кабыз дип әтте дир // малай басып калган // былар киткәннәр // шафир инде йул буйы туктатып барды дир теш теш дип // йук белмәдем дир // ай артистларга бара / артистлар артыннан бара // үзе дә артист // шылай инде // шындый халләр була инде ул //]

*Информант: Шәрәфетдинова Сания Абделвәли кызы, 1935 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Татар Сыгыты авылы*

[чийә чийәләгәндә
чийә матур / алсу була /
йаңгыр сибәләгәндә // бусы кырук[76] бийегәндә генә инде // бийегән вакытта гына // ә / нидә / былай кырук әл′әнгәндә / айзар гелзәйемне // байзар гелзәйем //

[74] үңгә – башка
[75] тенә – кичә
[76] кырук – түгәрәк уен

айзар гелзәйемне // кушыл әле адʹа / кил әле// адʹа айзарга // адʹа айзарны җырлыйк әле // мыни матур таwышлы // беләсенме / адʹа икәү җырлыйк әле ай // адʹале // айзар гелзәйемнә // байзар гелзәйем // айзар гелзәйемнә // быйзар гелзәйем //

уртага керден̧ дә бастын̧
кемдә синен̧ уйларын̧ //
уйлаган уйларын̧ белән /
үтсен кызыл туйларын̧ //
уйлаган уйларын̧ белән/
үтсен кызыл туйларын̧ //
айзар гелзәйемнә // wайзар гелзәйем // айзар гелзәйемнә//wайзар гелзәйемне //
урталыкта син торасын̧
әлʹәнмиме башларын̧ //
сандугачка мисал килгән
синен̧ кара кашларын̧ //
// гелдер / гелдер / гелдер / гелдер //]

*Информант: Араева Сәкинә Алимҗан кызы, 1937 елгы*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[аннары сын̧ тагын нәстә /сез сораулар бирегез / мин сүләрмен // бар / петен[77] нәстә дә бар // бизәү дә бар / кершән / пудра да бар / петен нәстә / петен нәстә // бар да шылай бизәнеп цыгалар иде киц белән // гармуннар белән тан̧ аткынца / гармуннар белән унʹап утыралар /бииләр/ йырлыйлар иде// аулак ейләр була иде шылай // кызлар зыйылалар да җигетләр киләләр / гармуннар белән керәләр / бииләр / җырлыйлар / унʹилар// безнен̧ аwыл бик күркәм // бик йакшы аwыл булып йәшәде элек электән // күркәм аwыл булган// бетен илгә йарый тырган булган // бетен кешегә булыша тырган булган // безнен̧ аwылда җиде мулла булган //азаннар әтʹеп мәцетләрдә // айзар гелзәр уйыннар унʹаган инде шылай/ гел мени нинди уйыннар унʹаган инде // аулак ейләрдә кызлар зыйыла инде // җегетләр керми // кертмиләр җегетләрне // киц кырын инде хазер гармуннар белән бийетергә генә кертәләр иде җегетләрне // бийетәләр дә җырлаталар да тен ката[78] // аннары җегетләр цыгып китә // икенце кенне тагын зыйылалар иде / шылай айзар гелзәйем лә айзар гелзәйем // шул җыр исемдә калган минем // айзар гелзәйем лә айзар гелзәйем/ йаратканым син минем бергенәм // галийә/ берсәк җырлар әтʹ инде // мыни кызларга мыни бит мин кызларга айзарны җырлап күрсәттем // элгәре шул аулак ейләре булган инде теннәр / кеннәр //

[77] петен – бөтен
[78] тен ката – төн буе

кендез калхузда үткән / калхузда эшләгәннәр // аулак ейләрендә шылай ун′аган / җырлаган / тен утырганнар / киц утырганнар /сагат′ берләрдә икеләрдә цәй куйып цәйләр эцерткәннәр // безнең аwыл бик шындый күркәм / бик матур / бик кешегә йарый тырган аwыл дип атала шыгырдан // шыгырдан дип атала // шыгырдан элек электән шыгырдан шылай тәртипле аwыл булган / берсенә берсе гел булышканнар // кемгә нәстә кирәк булса / эш булса да бергә эшләгәннәр /хаман да бергә матур гына утыра да кене буйы эшлиләр дә киц аулак ейләре була // җигетләр килә дә тәрәз тебендә пыштырдап йериләр / пака ызбага[79] кертмиләр йегетләрне // ызбада кызлар гына // аннары айзар гелзәйем дә айдар гелзәйем дип җырлап җибәрәләр дә/ бетен авыл җыйылыша иде / бетен аwыл җигете кызы // безнең аwыл бик күркәм матур аwыл иде//аwылыбыз зур безнең//]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[аулакны күп инде //
ишектән килеп кердегез
исәнләшә белдегез //
мәкниң алсу чәчәгедәй
күземә күрендегез //
суда суда суда йөзәләсеңме //
мин сине күрми түзәлмим //
ә син түзәләсеңме //
йырлыйк әле / йырлыйк әле /
йырлыйк әле иптәшләр //
иптәшләр үзебезнеке
бәлки гайеп итмәсләр //
суда суда суда уда
суда балыклар уйный //
гәүдәләрең күз алдымда
сүләшеп кенә булмый //
анда җыр күп инде // хәтердә шул калган инде икәү әл′әнәсең шулай // уртага чыккан кеше ала шунда // күп йырлыйсың инде шунда җөзек салыш ун′илар иде инде // ала да инде бара бара да инде җөзекне кемгәдер салып калдыра // аңарга җаза бирәләр инде аннары йә бийетәләр йе җырлаталар // римин сугыш бар // әгәр дә торып өлгерәлмәсәң римин белән берничә кат сугып алалар // кызык эш

[79] ызба – өй

тапканнар инде шулай // матур wакытлар бар иде безнең заманда // йәшләргә сүләсәң keләләр генә алар //]

*Информант: Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ул безнең заманада без үскән wакытта аwлак үләр була иде // кызлар сейү була иде хәзер ул нәстә була иде // хәзер йук инде// менә без кецерәк wакытта без үсеп җитмәгән әле ул wакытларда унец үндүрт йәшләрдә дигән кебек инде // без айырым кызлар зыйа идек // ылы йәштәгеләр үзләренә айырым зыйалар иде // сүләшә идек // ызба йуа идек // казларын җылкып бирә идек // шылай шул эшләрне эшләгәч безгә тенге аwлак җыйдыралар иде// хазйайыннар инде хуҗалар // шында аулак өй була иде // анда инде менә ничек тилибизырдан күрсәтәләр шындый фурмада инде // йезек салыш / бийү / нинди уйыннар бар инде / шул уйыннарның бетенесөн ун′и идек инде без // аннары үсә төшкәц инде // кызлар гына тегел / җегетләр дә керә / ул тенлә генә була кендес тегел // йә казларын йылкыткан инде без аларның // йә ызбасын йуган инде без // хуҗаларның кирәк эшләрен эшләгән инде без кендес / аннан тенгегә инде тегени аулак өй // алар инде шында тырган алар караwыл кебек торган инде // анда бит әле җегетләр дә килә кызлар да килә // ишек тебендә җегетләр йергәч / аларны карап тырырга кирәк бит инде тен ката[80]// терле нәрсә булдыра ала инде// без анда кунабыз // шылай анда рәттән утыра идек // урта бер җире буш / рәттән ескәмийә тезелгән була // шында инде кызлар утыра бер йакка җегетләр утыра // гарманист килә гармун белә // ул гарманист самый кеше була инде // ул түр башына утыра // без кулйаwлыклар тытып битне каплап бии идек инде // хәзер икеләрдә ецләрдә кебек инде // таралышалар инде // кем үwенә китә // китәлмәгәне шында куна // ескәмийәләрне ниләрне цыгаргач инде // урын җире җәйеп безне җоклаталар // аннары бит инде елгәре ризык бик кытлык булган // үдән[81] шылай әпәй[82] кисеп / цүпрәккә салып нәрсәгә дә булса да цырнап / алып бара идек инде / йә алып бармаганнары хуҗаныкы була иде инде// тенлә белән шылай әпәй белән цәй ецеп йата идек // аннан икенце кенне үгә кат′кан инде// җегетләр белән шында күрешкән // ә былай кылупка чыгып йермәгәнбез // обший күрешә идек // шунда күргән сине сынаган инде ул // сине тапкан аннары соң аwлак таралгач инде хуҗа кеше ишекне бикләп куйа// кызлар эчтә кала // аннары сүләргә йәшәләр // ул сүләргә йәшү дигән нәстә / элгәре бит анда ызба түгел ишек ары гына булган // ишек ары тактадан йасалган// тактаның бит инде

[80] тен ката – төн буе
[81] Ү – өй
[82] әпәй – ипи

йарыклары да бар // анда бытак йарыклары да бар // шул йарыклардан инде кыз бу йакта җегет теге йакта шылай сүләшә идек // ну син мында / тегендәрәк берсе баскан / мындарак берсе баскан // җегетләре пайыт башында[83] да булган // элгәре пайыт[84] мындый булмаган инде // ишек алдында пайыт та ул пайытның эстендә салам // шунда менеп утырган җегет син инде анда ишек алдындалар булган // салам тырган шынарга менеп утырган // шылай сүләшкән инде// кызык булган дерестән дә //]

*Информант: Әйбәтова Гөлфисә Миннулла кызы, 1948 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[әни йалгыз үткәрде инде шылай // безнең / кылупка йөрмәдек // безнең / клубка джерүче джук иде// аwлак иде ул wакытта / аwлак // сөйләгән вакытта кара каршы тишектән генә сүли идек // җегет белән очрашуны сүләү дийәләр иде бездә // йегет белән оцрашу сүләү була // аwлакта бит инде йә ызба йуабыз инде// йә утын кисәбез инде анда / өмә белән / ниндидер биш алты кыз эш эшлибез дә / аннары инде хуҗадан аwлак сырыйбыз инде// йегетләр белән очрашкага кылуп кирәк / кылуп йук бит инде элек // шунда аwлак шунда көне буйы эшлибез инде// утын кисәбез йарабызмы анда // кызлар килә дә инде и мында йегетләр кереп утыра / без анда бит инде/ элекке мактанып әйтмим инде заманга да эләкте капрун ойыклар да йук бит инде// аннары шундый заманага эләктек бер кемнең күлмәге бар инде/ берничә күлмәге бар // курага[85] элеп куйа идек кунактан кайтач // эшләгән wакытта башканы кийәбез былай башканы // күлмәкләр алдык да тагын // канашка бардым хәзер / күлмәк табып / үгә алып кайттым / кызыл ике терле күлмәк алдым дифицит // әнвәр абый булган мәрхүм үлгән инде ул // шының белән бардык күлмәк алдык ике төрле күлмәк капрун ойык алдык инде// ул матур аппак түфли алдым // ул туфлийем әле дә ер йаңа тора // аны бик каты биригатʼ итеп алып аның краскасы әле дә бетми // андый ак беркачʼан да булмый // хатеремдә / куйдым да берwакытны үзем киттем кемнәргәдер ызба йуарга // үгә иптәш кызларым кергәннәр дә шунда аның урнына үзгә башка әбʼер куйып / өстенә тузан кунмасын дип цүпрәк йапкан // цүпрәк йабып калдырганнар / апчыып киткәннәр // күлмәгем җук туфлийем дә / бернәрсә белмим бит әле// хәзер берничә кеннән җыйындык аwлакка барырга // тытындык / фазиләттәй белән / капрун ойыгым болай болай киткән // йылим йылим да бит / күлмәгем тапланып петкән / каралып беткән // шулай беребезнекен беребез кийә идек элек // аңарга әбʼер әтʼмәгән инде йарамаган /

---

[83] пайыт башы – лапас түбәсе
[84] пайыт – лапас
[85] кура – колга

капрун нәрсәләр табып тагын /кунакка барганда сырап та алган инде без аны // гармун у′нап йегетләр киләләр инде монда ай аллам // хәзер күрсәтәләр аwлактан шул инде ул // анда җегетләр кереп тезелеп утыралар // елекке бик каты акыллы ни булган малайлар // йортның хуҗасының әб′еренә дә тимәгән // анда казлар үрдәкләр ишек алдына эленеп тора // берсенә дә әйберләренә тимиләр иде беркач′анда // менә матур гына акуратна гына кереп утыралар // аларның гарманистлары бар инде бер икеме берсе арый да берсе туктый // бер йегет бийеп ала / аннары тагын бер кыз чыга // туфлийен салдыра да тагын минекен чыгып кийә // шылайтеп чиратлап биибез инде // анда бит әле шылайтеп йаулык белән башка кулйаулык белән бит әле // шылай бииләр // аңарга без әз ләктек // безгә бит айырым айырым бийү чыкты // ә бездән ылыраклар инде әниләр шылай бийегәннәр // ник дисәң кагыйдә булган инде ул // шундый ни булган правила булган // тәртип / акуратныст как бутто дини ни кебек аннан да каплаган инде / авызны / бырынны күрсәтмәгән ничек тә / битне дә / йезне дә күрсәтми торган цак булган / элек чара булган // аннан шул инде безнең заманага шылай // анда йегетләр бииләр инде кызлар напримир бер йегет килә дә инде бер ошаткан кызын каршы килеп ала да тыпырдап тыпырдап бийеп ала да / икәү биисең инде // аннан майскийга килеп ала да тап тап итеп китереп тибә дә биисең инде // тагын бер пар чыга // кызык булган инде үзебезгә карата // аннан кемнеңдер йегете бит инде// кемнеңдер күргән ахирәте дусты // шылайтереп анда йәш кийәүләр йәш киленнәр аwлакка киләләр инде // алар парлап бийетәләр кул чабып чабып // шындый матур заманалар иде // аннан соң йырлыйбыз инде // айзар дибез инде без түгәрәк уйныйбыз айзар // безнең заманада айзар дийәләр иде// шул айзарда инде аwыл күләрне[86] элекке әниләрдән калган җырларны инде күбрәк // чыгара белгәннәргә обший җырлыйбыз // анда җегетләр дә тытынып баса инде / йырлап әл′әнәбез дә аннары икәү икәү әл′әнәбез тытынып // беләсездер инде аларны // түгәрәк ни уртада әл′әнәбез // аннары йезек салыш та ун′ап алабыз инде // бар // айзар гөлзәйем дә wайзар гөлзәйем дә // сезнең ечен минем һаман өзелә үзәккәйем // сезнең ецен һаман минем өзелә үзәккәйем // аннары бийетәләр // җырлый идек инде кызлар йанында // биибез инде йә талы талыны ун′ыйлар инде// нинди йыр булса да бер йыр ун′ыйбыз инде аннары бийетә торган такмаклар әт′әбез // да аннан соң инде монда аwлак бетә йырлыйбыз / арып җитәбез / аwлак бетә сәгәт ике җитә дә инде йегетләр цыгалар тышка цыгалар хуҗалар // аннан кызларны идәнгә түшибез[87] дә анда нәстә бар куфайкамы анда адийалмы // нәстә бар пастил анда бит андый мондый кавирлар булмаган // менә тормыш үзгә башка

[86] ү – өй
[87] түшәү – урын җәю

терле булган // аннан соң инде кызлар сузылып йатабыз // аннан бер ахир шуның хуҗа кызы туганымы шул йакның кеме дә булса цыга да инде / йегетләр цыкылдата тәрәзәне // миңа шул кызны цыгар әле сүләргә // бездә сүләргә диләр инде // хадер ни хәзер керәсең дә теге кызның колагына әт′әсең инде// сине шул җегет чакыра сүләшергә // цыгасыңмы // ә разый булса шыпырт кына тора да инде кызлар йоклаганнар / барып барып сөйләшәсең инде / алар йегетләргә цыгалар анда ишек алды[88] була инде / крыйл′ца[89] дибез инде без аны // ишек алдында утыргыцлар йук // анда бит инде мендий түгел ыстиналар // анда бит инде тишекләр йасаган була / йегетләр // йегет теге йакта сүли бу йакта шул тишек // шул тишектә сүләшәсең инде// ул сораw бирә / син җавап бирәсең // шылай йараша / тытыш йук инде / анда утырыш йук // аннары инде бер беребезне тыңлап тырыш бар иде / келеш // кызык бит инде элек үзебездә ыланнар да // бер йегет белән бер йегет кызның сөйләшкәнен баскыцтан менәбез дә тыңлап торабыз // кайбер вакытта инде зуррак тишек булса кызның бармагын сорыйлар инде килешеп // бир әле бармагыңны ни килешик әле // йә кулны сорый инде зур тишек булса // ни очрашалар инде без шылардан кат′ып кат′ып[90] келгән инде // и аллам кулын тота кулын ала // кулын тоттырды шылай булды // без әниләргә кат′ып сүли идек тә әниләр әт′әләр ийе кешегә сүләмә ул сүзеңне кешегә әт′ә күрмә / кешегә сүз цыкмасын / харап булырбыз / йатка калыр // анда үбешүләр ниләр булмаган инде // аннары шул аwлакларга цакырып алалар иде / кем кас′ы кызны тели // йегетләр цакырып алалар // азрак сүләшкәч сүзен беткәц керәсең инде // үләнәсе булса башта сүләшеп йерисең инде // сүз куйасың[91] инде аннары // шунда сырашабыз шул wакытта кийәүгә цыгабыз или анда күпмедер йыл сүләшепме или анда сүләшеп тә урлап китәләр инде бүген сүләштеңме иртәгә урлап та китәләр инде // урлаw бар иде урлаw // анда атка салып / машиналар аз булган//]

*Информантлар: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*
*Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

---

[88] ишек алды – өйалды (сени)
[89] крыйл′ца – өйалды
[90] кат′ып кат′ып – эче катып
[91] сүз куйу – сүз куешу

## *ТАНЫШУ, КИЯҮГӘ ЧЫГУ, ӨЙЛӘНЕШҮ ҺӘМ ТУЙЛАР ТУРЫНДА*

[теләмәгән кешегә цыккымыз keләми иде инде // ни ишек цакылдый / мин әниләрдә // хәзер минәйтәм цыкмыйм димен әллә нигә дә димен миннегали абзый инде алла хакы ецен бүген генә цык инде ди // бүген цыкцам булды инде ул аннары // бүген сүләдең ди дә инде икенце кенне орларга да булдыра // йук димен цыкмыйм димен // ишегеңне җимереп керцен цыкмыйм димен // тәки цыкмадым шыңарга // аннан соң нигә / батырга тештем дә инде монда ни зайым ун′аттым да миңа биш йез ул вакытта бик каты[92] акца бит инде ул // биш йез миңа зайым цыкты // хәзер шул ир шул җегет шунда зери // и алла ди / фазилә ди бергә дир башында ди мени әгәр зегет булсаң ди // бергә аракы алып ецә идек инде ди // бу инде гел сүз кушмак keләп йери шулай // йук йук димен мин әле димен кеше үенә керәм димен // ницектер инде шулай кеше үенә керәм дигән булдым да тагы аңардан ниттем инде // башка йыртка качкан // йаратмаганга цыккыбыз keләми иде шулай // йаратмаганга да урладылар инде кызларны // орлап китә кайа барасың кайтырга йарамый // тырырга тырырга шундый замана элеккерәк бик каты хәзер алай тигел теләмәсәләр тырмыйлар сүләшми дә хәзер ысбободный бит инде / башта кат′асың да инде бу йыртка кайа аппаралар инде // бер тырмаган кеше туганына аппара // орлап кат′а да // аннарсын симйасы белән үдә каршы алдылар / машинадан / дерестән тә сүз куймаган идек сүз куйышып йергән // абыйсы белән шул булачак хәләл җефетем машинада / шылай кат′ып барам да эштән майскийда эшли идем / медработница булып // автобустан паварутта тештем дә анда машина килә папутка // папутный гына сигез цакрым зәйәү атлый идек сигез цакрым автобусга ләктем шулай тештем дә карап тырам // машина килеп туктады / утырдым / бара бара / әзрәк баргацтын җегетем дә кереп утырды // мине алып киттеләр // нәстә эшли аласын анда утырттылар да апкайттылар грузовой машина белән кат′ып тештек анда / шул килендәшләрем каршы алдылар // беранда йакка цыгарып җибәрделәр менә шул // менә икенце кенне биштән тырасын иртән биштән тырдык / аннары инде бер бабайны дәшеп утырталар // әниләргә әт′әләр инде җибәрәләр бер кешене кызыгыз бездә дип әт′әргә // сәгәт бишкә кадәр мунца кереп кат′асын инде / кермәсән шунда тырасын // кат′ырга китәргә йарамый // приказ әниләрдән / киттеңме тыр // киттеңме тыр / үзең сүләшеп йергән / үзен тор / кешегә сүз сүләмә / сабыр ит / безнең әниләр шылай диделәр // баш булма // туганым абыстай [93]/ сүгәнем абыстай[94] / кайын энеләргә

---
[92] каты – күп
[93] туганым абыстай – иренең бертуган апаларына эндәшү сүзе
[94] сүгәнем абыстай – иренең бертуган апаларына эндәшү сүзе

матур җанагай[95] / шулай куша идек / матур җанагай анда / әллә нинди җанагай / җанагай йегет белән бертуганнарга инде / анда күршеләргә дә әйттерәләр иде// кан′ата [96] кана′та инде кан′ата белән бертуганнарга кан′ага [97] диләр // сүләшмибез алар белән әле сүләшмибез // без эләккән инде шуларга // хәзергеләр сүләшә // безнең балалар сүләшәләр // алар сүләшә инде / безгә нәрсәдер әт′ә дә без бер балага әт′әбез дә ул әт′еп бирә // бер бала да булмаса / нәрсәдер сыраса / тегендәрәк барасың да кайадыр йугалып әт′әсең инде / үзен күренмисең // минем кан′ам[98] айаз[99] иде кан′агамның колагы әзрәк // шулай матур заманалар булган инде// нужалы[100] булмасыннар / бәхетле булсыннар оланнар //]

*Информант: Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*
*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[нәстә сүләргә// ул вакытта мин әле уналты йәшемдә генә идем // кийәүгә китәргә уйламаган да идем // аwылга кат′канда алдылар да киттеләр // шылай бер иргә киттем // тырдым // унбер лан[101] үстердем // шекер хыдайым / мени хазер үзем генә рахатләнеп йәшим / барын да үстердем дә ыцырдым // мени бар да минекеләр / бар да минем кызларым // сигез кызым / ец малайым // шылай алхамделәхишекер // нәстә аулак ейләр / безнең заманда инде аулак ейләргә генә йери идек / клубларга ниләргә йерми идек // җигетләр кызлар белән бийеп җырлап / аннары инде үгә затыш / кат′аралар иде / күлмәкләрне алыштырып кийә идек // бик каты йәмне генә кызлар йанына кийеп барган күлмәкне инде кийеп кат′ырга ник йарамагандыр / иске күлмәкләр кийеп түwенгә түwенләп[102]// шылай ырлап кацтылар / түwен артыннан цабып үземне алып киттеләр // ирем белән таныш тигел идек инде // сүләшмәгән дә // күзләп йерегән стройкада чамалап йерегән инде бу / йәш кеше / матур булган инде шылай // ул чамалап йергән инде бу мина ышый / мының белән тырып була дип әт′еп әт′тем дир / келә инде // шылай миннән ун йәш′ ылы / алды да китте үзенә // ул йерме алтыда // бергә йәшәдек шул кенгә хатле / ул әле китеп барды / киткәненә ец йыл булды // ха[103] үзем генә тырам //]

---

[95] матур җанагай – иренең энесенә эндәшү сүзләре
[96] кан′ата – каената
[97] кан′ага – каенага
[98] кан′ам – каенана
[99] айаз –
[100] нужалы – авырлыклар белән
[101] лан – бала
[102] түwенләп – төенләп
[103] ха – хәзер

*Информант: Гафурова Минзада Сабирулла кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[карцыгымны / йараткан тырмыш иптәшемне / мин аны эштә йергәндә күрә идем // белә идем кем икәнен // качан умердә дә йук// йери идек // тырышлыгын /уңганныгын // фирмада эшли иде ул / маладец // ударник була иде// мин шынарга күрә мәтәм мыны апкат′ырга кирәк // но ницек апкат′ырга // мында машина йук безнең // машинам белән килдек тә утырттык та кат′тык // нинди утыртып // алып кат′тың да бит әле / кире китте н′ан′агым[104] // кире китсен // ул синең/ синең арканда китте ул // синең арканда китте ул // хабулла / әллә кем аркасында булса да/ кешене бер күрмәгән кешегә сразы килеп риза булмас инде // ну мин аны мыни умре буйы бик каты йакшы кыскатын белән йәшим // петен[105] нәстәсен белә / эшли // саwлыгы бар // әлеге хатле ни кирекмесе минем эшне дә / үзенең эшен дә эшли ул // мин анардан нитмим // шекер // быңга хатле шылый//]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[менә наприимир кетәргә инде аны армийәдән кат′канын / ец йыл служба иде ул wакытта // ец йыл җиде йыл иде ул wакытта // теге мар′акларның / суда йөзүцеләрнең // кулйаwлык цигеш иде ул wакытта // чаршаw цигә идек мажит[106] цигә идек // куйкаларга[107] бит инде быларны җәймәгән // пастилне дә үзен йасаган / килинкур матириал ала идек тә инде ак матириал // шыларны ецәү дүртәү кунып кунып // да аwлакта инде менә аwлак була җыйылышабыз да бер йыртка да инде бишәү алтау дүртәү бишәүме // цигәбез чигү белән // цигәбез инде царшаулар / мажитлар инде // каплый торган чаршаулар / менә монда куйка йаклары куйка башлары // анда инде ецәрне ецәрне сындыкка салып куйа идек / йахшы гына йуып инде утуклап сындыкны тутырып куйа идек // кызлар уже цигәргә тытыналар иде инде // да әб′ерләрне әнәләре әт′ә иде / циктерәләр иде // энәләр апкайтып бирәләр җепләр апкайтып бирәләр // әрәләр утырталар аннары инде цигәбез // илле ыштукмы йез ыштукмы менә шыла иттереп кенә кулйаwлык цигеп куйабыз // кецерәк кенә матириалдан аның кырйыннан тытабыз да // йасыйбыз да бер цитеннән цәцәк цигәбез // кийәүгә баргацтын туйда бик зур бүләк булган инде ул // туганнарга бүләкләр бирешә идек шылай

[104] н′ан′агым – иркәләп эндәшү сүзе
[105] петен – күп
[106] мажит – кашага
[107] куйка – карават

// цигә идек // бик цигү заманасы иде инде безнең заманда // и анары суң әлләнәстә туй килә бит инде тугыз унук киләбез дә инде / җегет йагы кызга кунакка килә туйга килә // шында инде атны тытып килүцегә кулйаwлыкны бирә иде йәш килен // шылай цигү заманасына да ләктек шылай // тагын нәстә сүләмәк кирәк инде // тугызмы анда унмы сигезме // хә машина белән баралар иде // елек атлар белән инде йазмы анда балчыкмы[108] / калуша кийенгән / кызык булган инде // киләләр инде туйга / да әниләр безнең җегет йагы килә кыз йагына / ак туй килә / бездә ак туй диләр кызыл туй диләр / без килгәц инде менә сындыкларны тутырдык / киттек дамы / мында бетен нәстәне үзең хәстәрлисең // магазиннан сатып алырга йук бит инде ул вакытта // әрбирләрең сындыкларың кала әле / сындык диләр сундук диләр // әниләр безгә сындык алып бирә инде сындыкка нинди йахшы әрбирләребез бар үзебезчә инде // мендәрләр бармы ниләрең бармы йаңараклары // кунакка йери торган күлмәкләрең бармы / наскиларынмы инде шунда // магазиннан сатып алырга йук бит инде // хә бит инде акцаң булса бетен нәстә бар инде // алдан хәстәрли килгән инде // анары суң инде шул кийәүгә киткәцтен инде / задатка[109] диләр инде килешү була // анда инде бер ец пар кунак килә кыз йагыннан // анда киләләр дә килешәләр инде туйны ницек йасарга ницә ылаw килергә / күпме акца бирергә // хә инде бирнәләр өчен акца бирелми // мени хә безнең замангыны сүлим инде // шул хә әт′әләр инде задаткада шул бер кунак була да теш алдыра идек инде менә фазилә апа минем апам булса инде / аларны кертә тагын кунак булалар инде анары // киц белән утыралар да китәләр // анары ец көнгә зегет белән кыз нигә барабыз / кыз үwенә барабыз // зегет инде бер дыругын апкилә //ул кийәү зегете була // кийәү зегете белән // ул вакытта инде тәүбә тәүбә монда йаздырып барасыз инде // хаджа[110] өч литырлы банка белән аракы түгел // хаджаны ни теге үзләре йасаган // чуwаш йасаган инде // татармы чуwашмы белмим // литрлы пасудалар бар иде шылай / ыстикл′анный пасудалар бар инде шындый ызын гына // аның белән инде зегет бер феләк[111] хаджа алып бара // феләк булмаган / бучкалар белә // агач бучкалар // кыз үзенең гастинцалары[112] белән килә инде // анда кыз белән йегет ец кен кунып йатасы инде / анда кыз йагыннан туганнары кунарга чакыралар кийәү белә киленне // анда көн дә иртә белән мунча кереп кат′асың инде // кийәү белән йәш килен инде // идәндә кад′а булса да анда кумнатлар булмаган // йыклыйсың инде шында бергә // анан суң мунча кереп цыгасың анан суң кунакка йерисең

[108] балчык – пычрак
[109] задатка – туй алдыннан кыз өенә егет ягыннан китерелә торган бүләк һәм күчтәнәчләр
[110] хаджа – үзләре ясаган аракы
[111] феләк – фляга
[112] гастинца – күчтәнәч

кене буйы // анан киц белән тагы туганнар җыйыла // анда менә картырак парлылар җыйыла инде // кийәүнең хадҗаларын эцеп // кунаклар бик каты зырлап зырлап утыралар инде // анда бик каты кыршау иде инде // катыннар бер йакта / ирләр бер йакта инде // аннары катыннар әт′ә инде шул абзый йырлый // карале / ацып та карарга йарамый // берсәк[113] кенә менә шылай ацасың да инде / катыннар йук инде анда катыннар йук // анда йырлаw бик кызык булган инде / артис булмаган бит инде // кыз катыннарга йук // ирләр йырлыйлар инде // и аллам без аларга кызыгып торган инде // ии аллам матур йырлады инде // шылай сүли идек // анан суң икенце кенне тагын парлылар зыйыла инде // бөгенге килгәннәр килми / икенцеләр килә // икенце кенне кызлар йегетләр кийәwне ызатырга киләләр // сындыкны апкитәләр шыл сындыкны // шул кызның инде бирнәсен инде // ике мендәр / йурган / адийал нәстә булса да // сындыкны бер дүрт биш ылау була инде// ат / зиккән ат // анары инде сындыкны арттагы ылауга цыгарып куйалар // кийәw белә килен инде ылауда утыра // анан суң кайсы wакытта шылай // сындык естендә безнең wакытта туганнар утырып бара иде// хадер нидә шылай утыралар да инде// гармун ун′ап җырлап // арттан озатучылар йылап калалар // кыз белән айырылыша алмыйлар / зылыйлар // йырлыйлар инде тегендәге йәшләр йырлыйлар бик каты // йәшләр йырлыйлар бииләр //
килдек алып китәргә дип җырлыйлар инде //
без килмәдек буш китергә /
килдек алып китергә // алай итикме болай итикме // әллә сындык белә кызыгызны алып китикме // кызлар йырлыйлар // аннан кызлар аларга җаwап бирәләр инде// кызлар инде кара каршы // анары инде гармун мыңы уйнагач йырлыйлар инде барсы да // йылашабыз инде // анары суң шул сындык естенә килен белә кийәw утыра да // иң беренче без килдек сындык белән // и бал′ниста берәү сүли / и алла сындык белән бергә киләсе инде дир // бетен аwыл халкы цыгып карап тора инде дир // ей аллам мөршидә апа дип әт′ә дир// мин әни мөршидә атлы иде инде// кара мөршидә дзыйган икән акцаны дип әйтә дә дир // шуның хатле туй уздырды да кара әле// ницек зурлап дип әт′ә ди / сындыгы да зур инде // шыл сындык белән апкайттык инде // мында каршы алалар инде бик каты // туй анда инде // бетен урам цыгып баса иде инде // и аллам// и аллам / кемнең туйы килә шылар туйы килә // ха халыкның исе китми / кызыгы бетте // кызыгы йук нәрсәгәдер // айырылу турында йырлыйлар инде // менә алып китү дигәч тә / алай алып китикме дип йырлагачтын / искә төшә ул үзең генә тик торганда // мений инде әнәләр йырламый бит инде // кызлар йегетләр кара

[113] берсәк – бераз

каршы йырлый // аннары шылай утыралар да // ат белән әкрен генә гармуннар белән йырлап // йырлый йырлый кызлар атларга утыра // гармунда гарманистлар ун′ап җырлап / йегет ейенә кат′ып керәләр // аннары ни сындыкны килен белән йегет күтәреп керәләр / кайадыр түргәрәк инде // кайа урын бар инде / анда бит инде елек икеле генә ызба[114] // кецерәк кенә ызбалар йортлар // икелесе дә сирәк булган әле аның // ецкәрәк кертеп куйасың инде шылай // аннары кас′ыбер шындый бер малайлар була бит инде // шутниклар була // аннары ахирәтемә сындык этешергә хазер фазиләттәй теге әйберләрне күрделәр дә / шыларга тытканнар да тугыз ун кирпич куйганнар / ецкә тыгып // күтәреп куйа торган төгел / аwыр и алла аwыр // и аwыр килен белән кийәw күтәреп куйган // ацсалар/ киц белән ацып карасалар / кирпичләр // шындый шутниклар келдергәннәр //]

*Информант: Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[кийәү йуллыгы[115] мыни пример мыни син кийәүгә киттең / тырмышка цыктың // син тырмышка цыктың да / шында бер ике атна тырганнан сың инде // хазыр мында кийәү йулы дигән мәзлес була// кийәү йуллыгы дигән мәзлес // кызлар җигетләр // җигетләр тышкы йакта / кызлар ызбада бииләр / җырлыйлар / аннан сың урам буйлап бетен туганнарына // беген бер кешегә / икенце кенне тагын бер туганнарына / күршеләренә // аулак ей йасап кунып йериләр иде // бер ике атна йериләр иде / кийәү жуллыгы дип атала иде // кийәү йуллыгы // кызлар шылай матур гына кийенеп / гармуннар белән җигетләр бетен аwылны герләтеп матур гына утыралар иде // шылай утыралар да киц була хазер // зур айгыр дибез инде // тлар / атларга утырып урам ал′аналар иде кругом // безнең авыл зур бит / ницә ницә рәт ал′ана ала шуның хатлек ал′аналар иде // гарманист утыра атка // трантаска утырып тыралар // кыш кене булса цана белән / җәй кене трантаска утырып шылай герләтәләр иде аwылны // бик зур безнең аwыл / бик күркәм / бик матур // элек электән безнең авыл күркәм авыл булган // халык белән бергә бергә йәшәгән / берсенә берсе булышканнар // безнең аwылда шындый халык дружный халык булган / безнең аwыл барын бергә сүләшкән //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[шыгырдан авылында кызны орлау адәте кулланыла инде // кас'ы берсе ата-аналар белән киңәшеп эш итәләр / мында кыз орлау үзара килешеп эшләнә / кыз

---

[114] ызба – өй
[115] кийәү йуллыгы – өйләнешүнең бер этабы

белән йегет берләшкәц / никах мәзлесе үткәрелә һәм туй белән тәмамлана // килен төшкән көннән үк туган-тумачалар / күршеләр / дуслар килен күрергә килә башлый / аларны йәш килен цәй / белен белән сыйлый // иртәнге сәгәт тугызлар тирәсендә кыз йагына / кызыгыз бездә дип / барып әт'үцеләр китә // бу йегетнең йакын кешеләре була / йырттагы абый белән килен йәки йакын туганы / соңгы вакытта парлап баралар / машина белән киләләр// кызыгыз бездә / дип керәләр / аларны инде кетеп торалар / туганнар зыйылган була // хәбәр китерүцене кимак-белен белән сыйлыйлар / бу кунаклар икешәр чашка цәй эчәргә тиеш / йәшләр үмер буйы парлы йәшәсен ецен // ике йак та риза булгац / кыз йыртыннан йәш киленгә әбер[116] илтәсе бар / зур ак эскәтергә ике метр естәл зәймәсе / ике мунца селгесе / ике зур селге / ике тастымал / бер урын зәймәсе / кызга кирәк бетен кийемнәр куйыла / әб'ерләр иткәндә / танышырга йәшеп калдыралар // танышу кицәсенә кыз йыртына үз йагындагы йакын туганнар йәшелә / йегет йагыннан кыда кыдагый / иң йакын туганнар килә / кыда кыдагый ец баш алып килә / каз / торт / зур / матур итеп пешерелгән ипи // барлык туганнарга да бүләкләр тапшыралар // кунакларга алып килгән ашларыннан күцтәнәц җибәрелә / берәр кисәк торт / ипи / каз/ киц белән йәш кийәү белән йәш килен килә // шул вакытта гына ата ана балаларын күреп сүләшә ала / бу кенгә кадәр ана белән балага күрешергә йарамый дип саныйлар / бездә икенце кенне шындый ук кичә[117] йегет йагында була // бер атнадан кыда белән кыдагый икәү генә кыз йыртына туй сүләшергә баралар / кунак естәле әзерләнә / тик бик аз кеше белән генә үтә / бу кенне кач'ан ак туй / кач'ан кызыл туй / ничә кен һәм нинди тәртиптә булганы сүләшелә /задатка кене / сандык алу кене билгеләнә // туйлар башланганцы йәш киленнең сындыгын кийәү йыртына итәләр / бу адәт / сындык алу дип атала // аның да үз адәтләре бар инде / сындыкны алыр алдыннан задатка була әле / кийәү йагы кыз йыртына йакын туганнарын алып бара / кыз йагыннан туй алдыруцылар килә / шында туй качан булганны / кем артыннан кем алдырганны сүләшәләр / задатка салалар / бал / шәкәр / цәй / акца /бер лау башына мең тәңкә / ницә лау ак туйга килүцеләр исәбеннән // элеке йез тәңкә генә булган инде / задаткасы петкәц / киц белән / кызлар егетләр сындык алырга киләләр // сындыкны кийәү сатып алырга тиеш // сындык эстенә кызлар менеп утыралар да сатулашалар / шылай ук инде мендәрләрне дә сатып бирәләр / сындыкны алып киткәндә кыз йагыннан да кийәү йыртына кызлар йегетләр бара / анда да аларны кунак итеп / сийлап җибәрәләр / сындык китерүцеләргә кийәүнең әнәсе подаркалар бирә // беренце

[116] әбер – әйбер
[117] кичә – бәйрәм

кыз үендә ак туй[118] була / кыз йагыннан туганнар берсәк иртәрәк киләләр инде / алар кийәү йагыннан килгән кунакларны хөрмәтләп каршы алалар / кийәү йагындагы кыдацалар зур подаркалар белән киләләр / һәр лау айрым бер машинага утырып килә / элеке атлар белән килгәннәр / беренце машинада кыда белән кыдагый була / аннары кыз йагыннан билгеләнгән кешеләр кыда белән кыдагыйны күтәреп тешерәләр / кыш кенне цанада утыртып ал'эндырып киләләр һәм ызбага күтәреп кертәләр / җәй кенне тарантаста ал'әндыралар / кыдаларны алып килгән һәр шоферга килен подарка бирә / шылай петен машинадан кыдаларны каршы алалар һәм зыйылышып үгә керәләр / петенесе саwымнар[119] белән киләләр / петенесенең саwымнарын йазып йазып айрып куйалар / шыннан никах укыла / никах мәзлесен мулла алып бара / свидител'ләр алнында мулла йегет һәм кызның аннары ата аналарыннан ризалык ала // мулла никах укып петергәц / никахны теркәү таныклыгын бирә / эстәлгә банка белән су куйылган була / шул суны кийәү белән киленгә иң беренце эцертәләр / аннары калган кунаклар да эцә / кийәү киленгә мәхәр бирә // мәхәрне алтын белән бирәләр / никах мәзлесеннән соң кыз йагыннан булган туганнар туй мәзлесен алдыралар / бу мәзлестә мулла катнашмый // кицкә хатле йериләр дә инде / киц белән туй зату була / мында парлылар килә // икенце кенне кыз үендә ступай[120] була / бу мәзлескә катыннар гына килә // шылай кыз үендә туй тәмамлана инде // никахтан соң бер атнадан соң кызыл туй[121] башлана бит инде // туй кийәү үендә уза// кызыл туй кас'е берсендә ике кен / кас'е кешедә эц көн үк тә була // беренце кенне иртә белән сый[122] үткәрәләр / бу катыннар мәзлесе була // анда килен йагыннан кыдалар савымнар белән киләләр // киц белән картрак парлылар уза / икенце кенне йәш парлылар уза / эценце кенне йәшләр йазылышалар һәм киц белән йәшләр утыра // шының белән туйлар петә / бәбәй кетеп / бәбәй цәйе уздырырга зыйына башлыйлар //]

*Информант: Багаутдинова Фәрүзә Зариф кызы, 1942 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[безнең вакытта инде // безнең вакытта нәстә апкиләләр иде инде // туйларга инде // казы / әпәй / ну инде шул минем үз туйымда да казы / әпәй/ катлама йасыйлар иде // хазергы кебек чәкчәк мәкчәк / туртлар/ цәцәкләр нининдидер кирәк тигел инде / нәстә булган инде // җиде башлык апкиләләр иде инде // нәфизәптәй йасый иде инде // нәфизәптәй пешереп бирә иде инде аны // анарга

[118]ак туй – туйның бер этабы
[119]саwым – туйга алып киленә торган бүләк, күчтәнәч
[120]ступай – туйның бер этабы
[121]кызыл туй – туйның бер этабы
[122]сый – туйның бер этабы, хатыннар мәҗлесе

аның ецен йә йаулык инде йә бер ике ец митыр ситса бирә идек инде // ике катлама / ике күмәц йасыйлар иде инде // катламасы мыни тиге йымыркага ни камырны басалар да/ башай тиге тасма кебек// да// тасма кебек ызын // тасма/ машай / калынныгы ни калынныкта // ширинасы мышның кадәр йасап / тасма кебек йасыйлар // аннары/ шул тасманы машай майга тешерә баралар / пешереп / бахшай иттереп ал′андырып кыруг йасап ал′андыра / ал′андыра / ал′андыра шул бахшай кыруг килеп цыга // ул аны да алып киләләр хазыр мыни / нигә / кунакларга // ну алар машай машай кецкене кецкене гене йасыйлар // тиге чәкчәк кебек// шай йасыйлар да инде аны // аны кат кат йасыйлар да инде дә / моның зурлыкта була иде инде // зур була инде // аны инде циге тузмасын[123] дип / машай кырыйларына шырпылар кыстырып цыгалар иде // тузып китмәсен//]

*Информант: Апанаева Минҗиһан Халиулла кызы,1945 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы*

[кырцакны [124] цупрәктән йасый идек // анан суң тагын нәрсә кырцакны цупрәктән йасый идек кәгәздән йасый идек // үзебез белгәнчә инде кәгәзне бетәрләп куйа идек тә инде шунда // нәстәдер йаwлыклар бәл′эткән булып // алары да кирәк буламы / сийлимме суң инде// аwлак өйләр инде безнең wакытта // кылуб йук / кина йук // тиливизорлар йук // радиулар йук канишна // күпмедер канишна калхуз радиусы дийеп кенә елгәрәк радиулар чыкты // шул радио аша инде кемдер кайадыр нәстәдер сүләгән // кем ишетә кем ишетми // шылай итеп тыңлый идек / бу безнең чырлардангы wакытлар // безнең аwлак ейләр була иде инде күбрәк // сезнең кебек кызлар инде без ул wакытта // хәзер менә бездә ызба йуабыз // вис кыругом стинасын вич // ә систартып цыгарганнан соң без монда кунарга тийешле булган кызлар // систартып цыгаргач тузанлатабыз гына бит инде // аwлак кебек инде хәзер // җегетләр бер йакка кереп утыра // кызлар бүлмә кебек бер ызбада // кацып күренмицә тырабыз инде / йарамый // аннары бийергә цакырып цыгаралар да инде / гармун ун′ап тыра мында бийергә // менә шылай кулйаwлыклар тытып бии идек инде ул wакытта // башта шылайрак капланып бии идек инде без // кызлар ойалганбыздыр инде // шылай капланып бии идек астан // күз күреп барган инде // бии барган // аннан соң инде тыра тыргач / кас′ы берләребез инде / былайрак тыта башладык / аннарысың тагын тыра бара инде йыллар узгач // кен сайын инде / болай болай менә кара каршы килеп бии башладык // анда инде без зурайдык инде / хәзер былар китте бит инде / хәзер качыш йук бит инде / шылай // ницек әт′им инде / кылупларга

[123]тузу – таралу
[124]кырцак – курчак

сирәгрәк кенә бара идек / буласы ирем белән үзем дә белмицә калдым ницек танышканны да // айдә диделәр дә киттем дә бардым // йук ырламадылар // оцрашкалый идек инде шунда // йук / бездә сыраw йук бит // кыз белән генә сүләшәләр // кыз белән сүләшәләр // эти әни белән сыраw йук// әл дә йук // йәнәсе булды кыз белән килеште // ейенә кат′абызмы / башка кешегә алып керәме // ейенә үк алып китми инде / ни дисәң / монда хәзер кызның эти әниләре бара да бит // җегетне белә кайда тырганын да / анда булсаң апкитәләр кире // бу апкитмәсен дип күршесенә туганына апкат′алар инде // аны кунак итеп җибәрәләр инде монда эти әни // эт′ергә килү ецен // или ейләрендәге симйасы туганы килә инде // аларны хермәтләп җибәрәләр эти әниләр // шулай иттереп сый эләктереп алалар // эти әниләр дәшә әле башта // аннары гына без барырга // йук әле йук әле анда ничек базможност′ була // ничек ийәләндерәсең тырмыш бит // мужет минем әни йагында җитәрлек түгел мужет ейләндерүчеләр йагында бардыр инде // ейләнергә җыйынган кеше әзерләнгәндер // бит инде кызлар бездә хәзерләнеп тырмыйбыз // ну барыбер ницектер йалгышып куйасың инде әйе дип // кирәк була ахрысы // бер генә киц тырабыз инде // без дә бер генә тырмыйлар бупше // цәй эцәбез ашыйбыз эцәбез дә китәбез инде // булды / тегендә тырасың инде хәзер // шунда аннары җайлангач инде // җайлангач түгел әле // бездә инде зина дибез инде // зина булмасын ецен // изат кабул итү[125] / шундый ни укытып алалар // мулланы дәшәләр дә инде / син ризамы мин ризамы дип / никахка хәтлүк / изат кабул итү була инде бу// анда ул wакытта халык туганнар / туган тумачалар күрше күләмнәр туган тумачалар белән эш ителә инде // никах wакытында // никахка хәзер монда кыз йагына киләләр инде // кыз йагына ничә олау килә ничә парлы килә // олау дийәбез инде // хәзер машина белән киләләр бит инде // эле′ олау дип атала иде // олаулар белән киләләр иде // тагын бер олы олау булган // шулай тугыз ун пар киләләр иде // аларны хермәтләп / ашатып ецереп инде // җибәрәләр иде // ецәр көн иде/ кешләр алдыралар иде әле// мений эти әнигә киләләр җит инде // кунакка киләләр // туганым апам / сеңлем алдыра / абый энем алдыра // шундыйрак хәләттә // биш алты кеше кенә генә алдыра ец көн кеше генә алдыра // өц кенгә кадәр кунмый / но ец кен торалар иде инде // аннары хәзер кызыл туй дийәбез бит инде // елек кызыл туй дийелми иде// нәстә дийелә иде әле/ кийәү йуллыгы дийелә иде // хәзер кызыл туй дибез бит инде аңарга // алар ул wакытта ецәр көн кунып китәләр иде // ец кен кунак итәләр идеәти әниләр // кыз йагында// йук йук кийәүләр кийәүләр// кийәү йуллыгы кийәү йегете була инде// есбидетилләр йук йук алар түгел алар кат′ып кат′ып

[125]изат кабул итү – мулла килеп, дога кылып, кияү белән киленгә бергә яшәргә ризалык бирү

киләләр иде // никах укыткан wакытта әле мунца йагып тыра идек / үләренә килгәч // мунца керергә дип / мунца әзерләп торган // мунцаны эти әни йага инде// кем йаксын инде // хет кем йаксын инде/ хет син кереп йак // алар убаженийәсендә инде // ул wакытта кийәү йуллыгы[126] wакытта апкитә инде кийәү йуллыгы // менә кийәүләр куна бит инде шул кийәүләр кунганнан соң апкитә инде // никахлар белән бергә түгел кийәүләр белән бергә апкитәләр // нәрсәләр тутырган инде анда // хәзерге wакыттагы кебек матур әрбирләр булмады // чаршау ничек әт′им // елек бит инде монда комат комат бүленмәгән бер ызбада ницә кеше тырган // чаршау йегет белән кызга инде // капланып йатыр ецен комат // комат йасаган кебек бер чаршау бер караwатка комат йасаган кебек кенә инде // бер чаршау гына шылай кырылып куйылган // монда хет әллә кемнәр йата // кас′ы идәнгә йата // кас′ы нәстәгә йата // бер ызбада бетенесе кем кымныт булган инде // хәзер генә тиңигәргә бер комныт// бетенесенә бер комныт бүләбез бит // селгеләр еленгеләр апкитә идек / мажит[127] инде мацага элеп куйырга // мацага эленеп куйылган / нәрсәгә эленеп куйылган инде ул // элмәсәң дә бик каты йахшы бит инде // шылай йурган / ескә йабынырга // кызның үзенә нәрсә кирәк инде кийем салым // бар инде бар алары да бар // мендәр тышлары әзерләп // цигеп цигеп бардык // бетенесе бар // кулйаwлык инде анда денйа чиккән // циккән кулйаwлык мындыйлар тегел // нәрцә ецен инде // менә бүләк бирергә инде // әле дә бирәләр бит // әлеге кебек бирелгән кебек бирелгәндер инде // кац′ан ницек әт′им инде // кунак wакытында никах wакытында eләшенгән инде // киләләр иде киләләр иде // алар элеп калдыралар инде вич // әйбер алырга барган кызларны сыйлап җибәрәләр инде // естәл хәзерлиләр // теге никахныкы түгел ну ул ызба кийендерергә // еленгеләр ниләр бетенесе // чаршаулары еленгеләре барысы да // ике чәшкә цәй ецәргә инде парлы тырсыннар ецен // бар иде инде // сорасагыз искә тешерәбез инде // әбизәтелнә алар килен кереп килү белән күрешәләр // алар бүләк тотып керәләр киленгә // кас′ы йаwлык кас′ына ал′апкыч // кас′ына наски // канфит шәкәр тотып кермиләр инде // киленне кийендерергә киләләр инде бупше // хет тапычки хет наски хет нәрсә // шуларны тытып керә инде// хет алка хет брушки нәрсә бар инде // ул кадәр хазерләнеп тормаган инде килене кийендерәм дип // арчи[128] шул кийәү йулында арчи була инде // кийәү йулы килгәч шул арчи була инде / мин бетенесен дә әт′ә алмыйм бит // кийәү белән кыз килгән wакытта шул кийәү йуллыгы шул арчи була инде // шунда бииләр әле // кызыл туйда да бииләр // анда да биетәләр шул кызыл туй кебек инде // арчи була инде // арчи

---

[126]кийәү йуллыгы – туйның бер этабы
[127]мажит – кашага
[128]арчи – туйның бер этабы

шул ул // да да / кыз йагында булган //хәзер йегет йагында // килгәндә торган шул кунулары булгандыр инде / кайан белим // шул арчи кебек була инде шул көндә // хәзер кызыл туй дибез инде // элек кыз йагында иде / хәзер җегет йагында / минем белгәнемцә // җыр инде җыр да бийү// кызны мактап җегет йагыннан җырлыйлар // кыз йагыннан җегетне шулай мактап йырылыйлар // бийегендә бапше озатканда түгел // бийү җырлау wакытында инде// җырлап бийеп инде ууу // бетен урам герләп кала // ызатып калалар каршы алалар // йук йук шатландырып кына җибәрләр // йылаткац нәстә була инде// и алла нинди йырлар // кирәк булганда булгандыр барсы да // хәзер кирәкмәгәц ынтылган инде җитмешкә җиткәц // урам кейе белән күбрәк җырлана инде //
куфта йупканны кигезмә //
кийә белмәгәннәргә //
зифа буйынны әрәм итмә
сөйә белмәгәннәргә //
сарафанынны кигезмә /
кийә белмәгәннәргә /
зифа буйынны әрәм итмә
сөйә белмәгәннәргә //
аклы йаwлык бәйлә дустым
аклы йаwлык килешә //
аклы йаwлык бәйләгән кыз
мырадына иреша // йук шул белгәннәр әллә кайа киткәндер // әбизәтелнә йарыктан йарыктан инде// тагы аларга сөйләшеп битеңне күрсәтеп торасыңмы // тишәләр иде малайлар пәке белә // елгәре бит таш тегел // елгәре бит ишек алды бит анда // аны күрмисең дә әле/ кем икәнен дә танымыйсың // сүләшәсең сүләшәсең имеш имеш күрмисең аны кем икәнен дә бемисең // чакыра шуны чыгарыгыз әле ди хуҗадан // шылайрак булы инде терлечә булды инде // белә идек белә идек // берсәк бар иде инде бер ике урам аша //]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## КАЗ ӨМӘСЕ ТУРЫНДА

[каз емәләре туганнарың белгәннәрең йәшәсең дә сиңа мин барам // аннары мин сине йәшәм кул алмаш кебек була инде // берберебезгә барышкан инде шылай // уу аннары цәй эцәбез // деңгелдәтәбез генә җегетләр йанда утыра // да алар килә кас′ы гармун белә килә анда // кайсын кырымга буйыйбыз // битенә сертәбез кырым мунцасы белә // кызык ецен // ун′ап серткән инде кызык ецен җегетләргә

// келгән инде нәстә / кызык булган // күрсә күрә шалт итеп сертеп аласың // тешәләр иде // анда бәкеләрдә казлар йуалар идек хәзер бәкедә йук // шул кайтканцы хәзерләнгән инде // эш бетереп кайткан төшкә// башта йолкып бетергәнце бер кат цәй ецеп цыга идек // аннан соң инде эш беткәннән соң каз итләре пешереп инде// ейдә нәстә тәмле бар ашаган // хәзерге кебек киймак та пешкән анда / белен дә пешкән анда // әллә нәрсәләр пешереп петерәләр иде // каз беленен белен инде абычный белен // майны инде шул майлаган wакытта табаны майлыйсың // ипи салган инде // пич алдында табаны менә былайтып тәгәрәтеп кенә торасың // хәзерге кебек газда түгел // газ йук // эш аwыр иде аwыр булса да кызык булган // киләләр иде бии идек аннан сың // тагын әт′әм бит теге ызба йуганда биигән кебек // ашап эцкәннән сың үгә кат′а идек // ун′ибыз айзар гөлзәйем гөлгәр гөлзәйем җыйрлый идек // кыругом тытынабыз да / менә син җегет мин кыз / бу җегет бу кызга алмаш тилмәш тытына // тытынышып йериләр менә шылай // аннан уртада берсе тыра // уртада бер тыра инде кызмы малаймы берсе тыра да // мин кемне телим шуны алам да // тытынышып биибез // атлап йергәндә җырлыйлар / айзар гөлзәйем wайзар гөлзәйем дип бийеп йерибез инде // айзар гөлзәйем wайзар гөлзәйем айзар гөлзәйем wайзар гөлзәйем //

алда булганда гына
гөлдә булганда гына //
күтәрелә күңелләрем
дуслар булганда гына // шул куплетны йырлаганда бииләр иде // айзар гөлзәйем тытынып атлаганда // шундый куплетларны йырлаганда инде бииләр әл′әнеп // йегет беләп кыз / а то кыз белән кыз // кем тели // су агышлы ун′илар иде // хәзер икәү без кара тытынабыз // сездә кара каршы тытыныгыз әле кызлар су агышлы ун′ибыз // хәзер кулны күтәрегез дә безнең арадан берегез цыгыгыз // хәзер без цыгабыз сезнең аша // йезек салыш бар иде инде// кемгә ницек биргәннәрдер белмим // кайсына йырларга биргәннәрдер инде кайсына бийергә // булган инде сабантуйлар цыга идек инде // фирмада эшләгәндә / сине олан цакта цыгарган // аннары эштә булган эштә wакытта калхуз машинасы белә цыккан инде // туры килгәндә шылай // йә атлар белә цыккан инде без // күбрәк урман йанындарак эшли идек // сабантуйына йырак тегел урман кырыйына барырга // баралар иде // ну мин андыйларга бик йермәгән // тийеш инде сезгә барабыз да кунарга цигәбез // барабыз инде бәл′ибез // ну мин андыйларга йермәгән // үзем йермәгәч интересоват′ тә итмәгән // бар иде тәртибе // ну мин андыйларга йермәгән // анда рәхәтләнеп тәгәрәгән инде // без йылга кырыйында йәшәдек // анда йылга таwлар кырыйында бийеккә // йарый инде//]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы,*

[каз емәләре булган // мени кез булды инде // хазер кез булды / халык инде зыйына / кийенә / хастәрләнә[129] каз емәләренә // анда кызлар килә // казны җылкып бетерәләр дә / йуып бетерәләр дә анда җигетләр кетеп торалар мында // таки җигетләр хәрберсе күрешеп выт шылай иттереп каз емәләрендә биген мыни  мында учыртка[130] салганнар // шылай иттереп / каз емәләре кез кене тытынып карлар йавып суыткынца / каз емәләре күп // казлар елгәре инде каждый йыртта казлар булып бетмәгән /но күп булган күп // бездә инде зур терлек асраганнар / сырʹлар / атлар шындый безнең аwыл шындый күмәк бер аwыл булып саналган // элгәредән[131] шыгырдан икегә бүленгән // пирвый шыгырдан булган // арйактагы шыгырдан / бире йактагы шыгырдан / дүрткә бүленгән безнең шыгырдан // убы йагы дип әтʹәләр // барына да исем кушканнар шылай бүлеп // шындый әби бабайлар шындый алар йылга буйларына тешеп буткалар пешергәннәр / тәмне тәмне ризыклар пешергәннәр / нәстә халләреннән килә шылай йаңгыр теләге йасый тырган булганнар // шул җаңгыр теләге утыралар җыйылышып /анда илле кеше буламы /җигерме биш буламы ашыйлар / ецәләр // хазер корәннәр укыйлар / йасиннар укыйлар / мында хазер карап тыралар / ехе / кибла йагыннан былыт цыкты // хазер бу абидтан сың йаңгыр булырга тийеш // тамберсе әтʹә / карап тыра тыра да/ хазер былыт цыкты /быз йавырга тийеш / быз була// быз йава шылай иттереп // быз йавырга булса бар да шул первай азыкларны зәйәләр / ашыйлар / ецәләр быз йавырга булса карап тыруцы бер белдекце кеше була // бер сагатʹтән быз йавырга тийеш давай ашагыз ецегез пака аннарысың зыйылышып китәбез / йаумаса утырабыз тагын // җаңгыр булмаган җылларны бар да циләкләр күтәреп берсенә берсе кыйынып / шындый бик матур үткәрә тырган булганнар // безнең аwыл әгәр дә инде шул быз йаwа тырган кен булса былыт кара цыкты быз йаwа/ ниләрне каплагыз / мыни памидурларны инде капларга кушалар // әгәр ни булса ацык калсын тимәгез / шындый опытный халыклар булган безнең аwылда елгәре //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## КҮМҮ ЙОЛАСЫ

---

[129]хәстәрләнү – әзерләнү
[130]учырт – чират
[131]элгәредән– электән

[хәзер менә әт′ик мәрлә белән бәл′әп куйгацтан инде/ бәй баwы бар // бил баwыннан бәл′әп куйарга кирәк / аннары аның йаwлыгы да була // йаwлыгы да була // шылай аннары бер каты аның ни и алла нәстә йазабыз әле җаwаплык аны мулла йазып бирә // катын үлсә / ире карамый // ире үлсә / катын карамый / тәхәрәтләре бозыла аларның / шылай диләр инде бездә /да /аннары адийалга чырныйлар анда җиназага тагын бер йурган җәйеп куйалар / шуны каплап алып баралар кыш кене ешемәсен дип // йерләр[132] алып чыга / халык анда урамга да сыймый нигә дә сыймый / без дә шындый бик / ызбадан[133] чыккан wакытта мәйетне айагы белән куйалар // аннары куйалар җиназа җирдә тора мулла укый тәлил тарталар җиназа намазы укыйлар инде аннары мәйетне алып китәләр // цыгабыз инде цыгабыз // анда инде китүчесе тарала // бер ишисе керләр йуырга кала / бер ишисе мөлек сүрәсен укый // тоз куйалар / аннары шуннан мөлек сүрәсен укып шуны укыйбыз // таwык та бар // гүр сәдәкәсе диләр инде / аның ецен таwык тотмыйлар енде / хә сәдәкә генә бирәләр // елгәре таwыкны муллага биреш иде // елгәре таwыкны тоталар да сыйпыйлар // укый да мулла / аннары шул таwыкны сыйпап куйа // йә җидесенә суйалар инде / йә еценә / шул мәзлескә суйалар // ечесе / җидесе / кырыгы / иллебере бар тагын // или мулла илтеп бирәләр иде // йә таwыкны тоттырып җибәрәләр иде муллага // идәнне бер хутка гына җуалар / бер буйга гына / естән аска таба / бер буй гына инде шунда / кат кат сыпымыйлар // шылай бездә калган инде // әт′әләр гадәт / гадәтләр // аны инде менәй йакыннары бик тотып кына енде / ире үлсә катыны айагын бик инде тотып кала / катыны үлсә ире айагыннан тытып калырга кушалар инде // күңелләр суыныр ечен / шылай // аннары инде ул үлгәннең керләрен йуалар йәшләр / өц кат // аннары аны машина белә дә йуалар / бис // безнең үлүгә бөтөн әб′ер бар / мәцеттә // кийемнәрен инде үтүләп / шул мишукка тутырып кире мәчеткә илтәләр // үз кийемнәрен үзләре инде / хаз′айын инде / нәстә эшли ала инде / кирәк кешеләренә бирәләр озаталар / кирәкмәсә йандыралар// хәзер алмыйлар кийем күп бит//]

Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы,<br>Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Сыгыт авылы

## ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШ ТУРЫНДА

[ат белән кул белән элек бит инде // сука булган үзләре тартып биш алты катын җыйылганда инде үзләре тартып ниткәннәр // ат кебек җигелгәннәр инде // алар үзләре шылай тартканнар инде // кемдер арттан тотып бара инде // аннан соң

---
[132] йер – ир
[133] ызба – өй

алышыналар шылай // шылай булалар инде // ну менә ат белән инде безнең заманада // хәзер трактыр // бер ике биш бәрәңге салалар да инде үзенекен үзенә саласың инде// калса алмыйбыз да инде шылай йарты чиләкне алып тормыйсың / китәсең инде// алма диләр инде бездә // бәрәңге йахшы була инде// тырактыр сыза / тырактыр чыгара // аннары чүплибез // хәзер аwылда җиңеллек инде // йук кызыбыз / улйанда // бер кызым камышта бер кызым мәдрәсәдә укыта // йук монда / монда төшәләр // өч кызым өч йолдызым шөкер аллага // йаздылар инде шунда кызым университетта укый //]

*Информант: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы, Чуwашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[монда без тырдык инде берничә йыл // аннары минем кан′ана әни бик йахшы акыллы кеше мәрхүм урны оҗмахта булсын йәшли wафат булды алтмыш җиде йәшендә // ул әт′ә иде инде // чыгып китик димәгән / ирем анда эшләгән / мин монда эшләгән // монда килен бар оланнар бар симйа китереп килде шылай // китә дә белмәгән // ницектер үзгә төрле булган тырмыш // заманасы шулай булган тырмыш булган эшлим дигән тырыйм дигән // йәшим дигән түзим дигән // терлекләр асраган каз үрдәк үстергән нужаланган эшкә елгергән кешегә булышкан // бакчада эшләгән кырда эшләгән үзе ничә гиктар чегендер дә эшләгән // эшләдек инде шөкер // хәзер менә аллаһ тәгәлә йулында // йырларга бик каты йарата идек канциртларда да йырлап йергән // беркайа да йугалып калмадык тырмыш өйрәткән / нужа // алла исәнлек бирсен //]

*Информант: Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы, Чуwашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[уразабыз җитә хәзер // аллах теләсә ураза тытырга йазсын //
сәхәр тырып айак бассак//
адымнары сайын саwап //
иртән тырып намаз кылсак //
насыйп булыр безгә саwап //
салаwатны күп әт′ә идек /
сәхәр цәйләр эчкәндә /
фәрештәләр сыйрат күперен кичкәндә //
сәхәргә тыручыларга /гыйбадәт кылучыларга дөнйа ахирәт саwабы ирештерсен иншалаһ //
сәхәр торып намаз кылсак /
җиңел кылыр сәгәләңне//
сәхәр торып тәһәрәт ал //

укы сәхәр намазынны //
салаватларны күп әт′сәгез сәхәрләргә тырсагыз / тәмуг утларын күрмәссез / уразаларны тотсагыз // фәрештәләр сәхәрләргә тырыгыз дип // үлгәч каршы алыр алар / оҗмахларга урныгыз дип // безнең әнинең әнәләре / шәмче баба белән мәрҗән әби иде бик каты диниләр иде // бик каты силиләр иде // ул әби үзебездән йырак түгел каршы йыртта тора иде// фазилә апа бик каты йахшы белә аны // гел кунарга керә иде безгә // әнинең әнәсе инде ул // ул безгә мени бабай да бик каты дини иде// алдан сөйләп тора иде/ бетен нәрсәләрне белә иде // алар шуның хәтле безгә әт′әләр иде// и балакаларым / әле сез каты гилемле дә булырсыз // сез әле шуны күрерсез / ул wакытта инде бит безнең заманда // хәзер мин үзем дә алтмышны тутырдым // ул wакытта булганмын инде бер унике унец йәшләрдә // ул әт′ә иде / әбинең бабайның // әле сез күктә тимерләр ыцканны күрерсез // күктә тимер ницә тонналары тимерләр // самалутлар булган инде ул // монда инде бер кац′андыр узып китәдерийе // без аны күргәндә күргән / күрмәгәндә күрмәгән // шылай бит / аннан суң ул әт′ә иде инде// ий әле сез белерсез / бөтөн карап тырырсыз үзегезне үзегез // әле анда бит инде безнең бабай шахтада эшләгән // шахтада ударник булганга күрә аңа радиа биргәннәр // ул радиа таш белә эшли торган радиа // әбиләргә утыргыц йасап куйды да менә шулай бабай // утыргыц диләр инде ызын эскәмийә // шул экамийәләргә халык бетен дөнйа дзыйыла иде дә / бабай менә шулай йүшкәгә куйа иде дә шул радианы / менә нәстәләр әле ул каситалар / алар әле тора ул / аларда үзләрендә / цыгарып куйганнар сарайда / малайларның малайларына калган инде ул // анда инде бетен халык шуны тыңларга килә инде// эте бете бар да кереп утыра // бабай җибәрә иде пластинка // тыңлый идек / и алла шул артис җырлый // шул артис йырлый и алла // и алла клупка артислар йырактан килгәнне / шыны әл′әндереп әл′әндереп безгә йырлата инде// анан суң тыңлый идек // аннан ул әт′ә иде/ и бәпкәләрем / сез беләсезме / әле сез күрерсез / берегез белән берегез сүләшерсез// берегезне берегез карап торорсоз // бер бүлмәдә кунакта булырсыз да / икенче бүлмәгә чыккач үзегезне күрерсез // кит әле келә идек // нәстә белә инде бу бабай дересмени / сез күрәсез дип әт′ә иде // мени хә күрәм дерестән дә // кецерәк кызы бар инде алты йәшләрдә // әби ди кил кил әле ди мин сине хә[134] ди үлән апа белән сүләштерәм ди кара каршы ди // кампийутирдан / кит әле димен / йук йук әби мин сине үлән апа белән сүләштерәм хәзер ди // килдем дә тилибызыр йанына зиңги нихәл зиңги нихәл дим // әстәгәфирулла әстәфулла тәүбә тәүбә // мине күрәсенме мин күрәм ди // менә шылай тора менә шылай // алдан белеп торганнар // ыланнар белгәннәр

[134] хә – хәзер

алар // мәрхүмнәр // әт′ә иде әби әт′ә иде// и балам дийә иде// ул wакытта безне искечә ейрәтмәк кели иде // мәктәптә укыйбыз / анда искечә укуны ул′амыйбыз да // и аллам мин кач′ан үрәнермен әле // кит әле дийә идем // алладан бәхет җитте дә // үзебез дә киттек тә мәдрәсәгә // сөбханалла ерәндек тә / укып чыктык та / укыйбыз да // корән укый торган буласыз әле дийә торган иде миңа // ышанмый идем шыларга / келә идем // әбинең иске китаплары бар миндә // үзе йазганнары ецендә бар // үзенең йазганнары берсенең ецендә калган // миңа кәдәр аның башка кызлары алып киткән шул // әле мина аны шылардан җыйып алдым // әбинең элеккеге иске китабы үзебездән йугары саклаган / хәзер мин аны ышкафка йугары куйдым да шылай карап карап укып алам да // анда башка дыгалар да күп // анда корәннең ниләре инде// суккан ул суккан суктырганнар аны // кайан алгандыр белмим // әби ул безнең искецә йаза ийе // йук шул / мин апаларга барам әнинең сеңелләренә күршесендә бер әби сындыгын ацты да әнә ди шыл хатларны укып кара ди // армийәдә wакытта ди сугышка китте инде бабаң ди // хатлар йаза иде бит // бик каты тырышып укыдык // искечә йазышканнар // сындыгында тора // әле ул үдә булмагандыр // китә ул кызларына анда монда // аны белешергә кирәк наилә ападан // әт′әм бит анда бекләнгән // аннары кас′ыбер битендә йахшы укыла инде // кас′ыбер битләрендә хәрефләр үзгәргән беткән // хадер аларга ничә йыл бит инде // и балам дийәләр иде кешегә аwырлык эшли күрмәгез чувашмы урысмы татармы алар алла бәндәләре бетен аллабыз бер // кешегә нацарлык эшләмәгез // кешегә аwыр сүз әт′ә күрмәгес // анары әби шындый хабәр бар иде// кешегә сили күрмә / кешегә цыга күрмәсен / шылай әт′әләр иде безгә // зинахар ецен кешегә әт′ә күрмә / хазер гайбәт булса / андый мындый хабәр таралса харәп булдык // сине дә ырышырлар / мине дә ырышырлар гөнаһ була дип ерәттеләр үлгәннәр / урыннары ыҗмахта булсын // бик каты әзер саwаплары барсын инде // менә шылай сагнам // әби белән бергә кара каршы гына / мин әби белән идем // әбине карадык инде без // әбине карадык // шул менә //]

*Информант: Рәҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[бу беренче шыгырдан мин беренче шыгырданда торган инде // чыкаловада хәзер инде шыгырдан ул // чыкалова йук инде бетте// бу ни беренцедән икецегә килгән // бу чыкалова дийеп атала иде инде// элгәре монда район булган безнең // батыр районы кебек // район булган бетен нәстә монда булган // элгәре заманалар без ул wакытта булмаган // чыкалова дигән нәстә килде инде шылай // аннары шыгырданга әйләнде инде шылай // мин ун кылас бетердем // аннары соң тагы укыдым дөрестән дә // ул wакытта ул заманада бит инде аwыр замана

// ни әтәйләр ызба йасыйлар ийе инде/ растыраталар күп була дип мине // мин укып бетердем // аннары практикасында да йердем // элгәре бит халык шундый курка торган булган / естипендийәне үгә китереп бирәләр // шул естипендийәне мин алмадым // укыгачтын да үгә китереп бирәләр // хә укып бетердем практикасында да йөрдем // әти әтте инде мәрхүм // растырата йасатырлар дийер // актык сыйр′ымны сатып түли алмыйм дийер // мин шылай эшкә кермәдем // аларга андый разрешенийә булмаган // аннары пучтага кердем // пучтал′онка булып йегерме йыл эшләдем / анан соң шул кецерәк малайымны тапкац // пучтадан цыктым // утызалты йәшемдә / анан соң батыр районына барып эшкә кердем // санитарка булып анда унбиш йыл эшләдем // анан пинсийәгә цыктым // дүрт ылан эшләдек // шекер йахшы гына эшләдек //]

*Информант: Әйбәтова Гөлфисә Миннулла кызы, 1948 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[без ирем белән шылай дуслаштык// ике йыл сүләп йердек // да да аwлакларда ну мин пучтада эшләгән // пучтадан йә кат′канда йә барганда // йә ул эштән кат′канда шылай оцраша идек // сүләшкән ийе сүләшкән / әниләр заманасында гына булган инде нийерәк // аннары бит азрак булды инде // сүләшү булды // мин инде үзем дә киткән булыр идем дерестән // шулкадәр сүләшеп йергәц инде ызатып йергәц инде бик каты акыллы инде ул // җиде кызга бер малай иде // тептән[135] икенцесе иде инде ул // хә ни бер кызны ызата бардым да мин // ник алай ызата барганмын инде // үзем генә кат′ырга куркам әйдә мине ызатыгыз диде дә // ызата бардык та ул билисапид белән // ызата бардык та шылай // аның нийәте булгандыр инде // ул кыз белмәгән инде йук йук ул кыз белмәгән // иптәш кыз иде инде // аның үwенә керттек тә без кайта киләбез // шыннан мине урлады // бермәбер дерестән дә ну барыбер мин тытып кала алмадым инде алып китте// аха мында алып кайтты // без ун йыл тырдык аннан айырылып цыктык мында // анда әпкәй[136] бар иде инде әнкәй әткәй бар иде // ризалашып цыктык инде // аннары әни үлеп китте / кан′ам[137] / әткәм йалгыз гына калды // әткәйгә минем малайым белән киленем ыланнарым айырылып цыкты // хә малайым тора инде шул нигездә // ул wакытта таң ата иде инде җәйге кен // ийуннең уны // бик каты каршы алдылар дерестән дә // бик каты йарата иде кан′ам да кан′атамда // ну малайлары йарата йергәч инде сүләшеп йергәч // йахшы каршы алдылар / йахшы тырдык // мин килеп берәр йыл тыргач / әтәй үлде// әтәй

[135]теп – ас
[136]әпкәй – әби
[137]кан′м – кайнанам

ашагац эшкәц естәләрне себерә[138] идек тә // әткәй ит ашамады / итен уцына тотоп кала иде дә кызым мә каwып йебәр дийеп миңа бирә иде// мин естәл себерәм дә инде мә кызым кабып җибәр // сүләшмәгән йук йук // кан′ата белә сүләшмәгән // ул үзе генә әт′әдер иде/ мин каршы дәшмәгән / йук // әнәләр инде ашап таралышканнар естәл артыннан // мин естәлне җыйыштырган инде // мә кызым кабып җибәр // анда туйны кезгә таба йасадык инде ул wакытта иң беренце киләләр иде шылай каршы // ике йаклап та каршы киләләр // аннары соң залугка[139] салалар // и нәстә җегет йагыннан ец пары бара җегет йагына // аның кыз йагындагы ец йырт алдыралар // кертеп цыгаралар инде шул кешеләрне // ул залуг дип атала инде// ул мондагы җегет йагындагы баллар цәйләр шәкәрләр шул кенне алып баралар кыз үwенә// аннары киц кырын инде шул // кыз үwендә инде кийәwләр ул wакытта инде кийәүләр бармый кыз бармый // картлар гына бара // аннары ул беткәц //]

*Информант: Әйбәтова Гөлфисә Миннулла кызы, 1948 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ул wакытта җиденче класларда идек // анда әле йегетләр белән ишек аша суләшәләр иде// болай йәнәшә утырып сүләшү йук иде// аннан инде wакытлар үткәц инде/ унсигез унтугыз йәшләр җиткәц инде// олыгайа барган дийәргәме инде үсә төшкән дигән дийәргәме инде// анда клупка йегетләр кызлар бергә // без бергә барып бал′слар бии идек // аннан танцылар цыга башлады инде ул wакытта // шылай матур җырлар җырлап урамда утыра идек // җиңел җырлар бар инде анда // кайберләрен белмим дә инде// ынытылган да // ул җыр ынытыла бит // йомшак кына җемелдиләр //
йолдызлар җәйге кичтә //
туган йакнын тын кицләре//
истә хаман да истә //
шул җырларыны җырлый идек бит // тагын нинди җырлар икән инде // бийене шул татар кейенә бийи идек // гармунчы ун′и иде // кулйаwлык шылай бийи идек // алзар гөлзәйем ун′и идек // алзар гөлзәйем инде ул // ул армийәдә иде солдатта иде // башкаwыл йегете иде// хатлары аша таныштык // безнең күрше җегете аңарга адрис биргән // ул ни хатлар аша танышып // үзем киттем // унсигез йәшемдә идем // килен каршы алдылар // үдә каршы алдылар әлеге кебектер инде// әле менә йәшләр ничек / шылай / каршы алалар инде // аннан никах мәҗлесләр үткәреп // кызыл туй да үткәрдек / ак туй да үткәрдек // ул wакытта wакыты да булмаган бит // заманасы үзгә // әниләрдә никах укыттылар

[138]себерү – сөртү
[139]залуг – туй кунакларын алдыру

// монда аwылда безнең ызын куакта // анда инде парлыларны җыйып // аннан кызыл туй инде шылай була // уу анда ул wакытта кара каршы җырлашу йук инде // безнең мишәр халкында дини ни бит // алай туйда җырлап утырмыйлар иде // бездә элек электән дин куәтле бит инде // ул wакытта әллә ни булмаган инде анда // бездә челтәрләр / шул урын җир инде // шул караwатка булмаган // йурган мендәр шындый әйберләр генә // анда инде чаршау / мажит / мажиты чаршау инде беләсез / әйберләр белән чиккәне апбара идек //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[бизәү әйберләре элек базилин // базилинга кызыл бизәү диләр иде // кыраска салган бәзилин диләр иде / кыраска салып аны кызарталар иде дә / битне түгәрәк иде / кашны буйыйлар иде // кашны карандаш белән // кара карандаш белән буйыйлар иде // муйыннарга муйынсалар // йезекләр / йезекне рәхимулла бабай дигән // хәзер инде ул мулла бабай // алар бик матур йезекләр // каш итә иде шылай // элек бит анда матур кашлар иде // йезек йасап бирә иде // муйыннарга муйынсалар тага идек // ере ере гәрәбә // сары гәрәбәләр // анда ул wакытта нинди ташлы / алар чын булган инде// хәзер бит андыйлар йук // түшкә бырушкалар куйа идек // матур матур бырушкалар сатыла иде // айакка тапычкалар кийә идек // зәңгәр тапычкалар ул wакытта // казанда сатыла иде ул // зәңгәр аллы ышнур белән // аннан бутый дийәләр иде // мыннан кыска бутыйлар // алдыннан каптыртып куйдыра тырган // бийек табанлы итекләр иде // резиновый итекләр //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[ак күк кирәк уйыннар уйный идек // кара каршы унар унар кеше барасын // и ак кирәк күк кирәк сездән безгә кем кирәк // безгә менә шул кирәк дип әтә идек инде // анда краскалар инд ешылай йәшә идек тә // анан шылай тагын кара каршы уйный идек // ынтылып та беткән инде / анда күп уйный идек // шул бер җыр җырлый идек //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[кизләүләр изге урыннар бар инде // кыйылар бар // күке кыцкырца шатлык була диләр // карга кыцкырца йуктыр инде ул әб′ер булмый тыргандыр // йук бер әбер сүләмим // чишмәләре бар йылгалары бар аwылыбызның // ии аллам исемнәрен белмим исемнәре йук // күлмәкләр кигән // мин ыныттып // бар иде

бар // запун[140] буалар иде алҗапма[141] // запунлы алҗатма[142] / җиңле алҗапма[143] // җиңнеләре дә була иде салынып тыра тырганнары да // җиң кебек шылай салынып тыра иде // без кумибыз әнәйләр куйа[144] иде // без түмә[145] куйабыз // безнең инде изүләр ачык // кан′атам йук кан′агам бар иде// кан′агай белән йахшы йәшәдек // кан′атайның абыйларын белмим мин // үземнең әти украинда плиндә калып шында үлде// ул сугышка киткәндә мин шул беренче кыласка керә идемме инде // берсәк[146] хәтерлим // мин аңардан ике йәшемдә генә калган // ул кайтмаган анан соң // украинда плиндә кала // украинда марҗага үләнә // анар соң дүрт ыланы була аның // анан кат′ып китте // кат′ып күреп китте // мында син бер генә дир // анда дүртәw дир // барыбыр бала бит инде дир // шылай кат′а алмады ул анан // анан соң үлде ахры инде хабәре дә килмәде // балалары кайтмады / күрсәтмәде дә ахры инде ул аны // үзенең сугышта бик каты булып рана күп булган иде инде // безнең заманаңы сүләмә инде кызым // ул wакытта ашарга булмаган // ечергә булмаган // кийергә ерәтле кеймең булмаган // аулакка да җерелгән инде// йәш wакытта җерегән // үләнен дә ашадык инде // кырахмалын да ашадык // кырахмал булса ашыйсың инде // кырахмалы булмаган әле аның // кецеркән[147] ашый идек // какы / газниц[148] таwык айагы[149] дигән / шыларны ашаган // ул wакытта булган хәзер аларны күрергә дә йук // бик каты йахшы иде алар ул wакытта // хәзер жук // шылай йәшәгән инде // чигүләр цигә идем шылай йаwлыклар кийерге белән // аны сатмыйлар инде үзен шылай нитәсен дә шылай йасап куйасың // җепләре базарда булган инде // батыр базарына йери идек // базар йахшы була иде йәмле була иде // зур була иде базар // кийем татымнар[150] саталар иде // кирәк әберләр бар иде инде бар да бар иде // тул′кы акца гына кирәк // без колхузда эшләдек инде // урак урган урак белән // цалгы белән цапкан пецәннәрне // бырцакларны барысын да руцной булган // саламнан зур ескерт куйа идек // аның башына ызын йаплы сәнәк белән тытып баралар иде // башына менеп катыннар шылай нитеп // безгә инде уракны урган кул белән ул wакытта // аwырың булса да бу корсаклы димәгән // бүлеп бирәләр иде эшләргә // дикрет тә булмаган бернәрсә

---

[140]запун – алъяпкыч
[141]алҗапма – алъяпкыч
[142]запунлы алҗапма – алъяпкычның төре
[143]җиңне алҗапма – алъяпкычның төре
[144]куйу – тагу
[145]түмә – муенса
[146]берсәк – бераз
[147]кецеркән – кычыткан
[148]газниц – кәҗә сакалы
[149]таwык айгы– үлән атамасы
[150]кийем-татым – кием-салым

дә булмаган // бер икесен бал′ниста таптып // бер икесен үдә таптым // да әби белән тапкан әби белән // әби килеп таптыра иде инде // йуындыра кыйындыра // чырный да үзеңә бирә // шының белән аның эше бетә инде // малай булса кистерәсең // җиде малай // бик каты бәхетле мин // бар да таза // анан соң теге йезек салыш уйныйлар иде // түгәрәк уйный идек // менә шылай тытынасың да кызлар шылай түгәрәк уйныйсың // анан җырлап аласың инде// кара каршы да җырлыйлар идеинде// бар да булган инде// безнең заманада булган инде булган // сугыш заманасындагылар без // килә йылыйсыларым // тешләремә кермәдең былай йылыйсыларым / дип йырлый идек // бысы йараса //
уйларымны утырып уйлыйм сәке йезлекләренә[151] /
үземнең дә исем китә бәхетсезлекләремә //
аклы йаwлыклар бәйләргә/
аклы йаwлыкларым бар //
аклы йаwлык бәйләгәнсең /
нинди шатлыкларың бар //
ынтыла бит инде ынтыла // башка уйыннар инде шыл йезек салышлы уйный идек // түгәрәк уйыны уйный идек индле// уртага кереп бии идек инде // такмаклап такмаклап // шыл // менәҗәт йук мин әтәлмим // йук йук бысын да әтә алмыйм // әкийәттә бик белмим // җырлары шыл инде җараса шыл гына // башка килми бит бетте//]

*Информант: Фәизова Сания Шәйдулла кызы, 1934 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[тиге пудрылар // иннек / кершән дийәләр инде // иннек бизәү // кершән шул ниләргә пудрыларга // күзгә сертә тырган сермә // сермә тарта идек // күз буйау // тушларны сермә тартабыз дигәннәр // туш // ну булган инде анда нәстәләрдер // аннан тиге безнең әнәй әт′ә иде // мыни кызлар йанында // битне мыни // акшарны / пицне бак шылай ышкыйбыз да // акшарны ышкыйбыз дийә иде // минем әнәйләр шылай сүли иде // үземнеке // элеке булган бит инде// вот шылай дийәләр иде//]

*Информант: Даутова Рузалия Алимҗан кызы, 1961 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

[бездә исем кушу шул инде ни // мине әни үдә тапмаган // кырыга кала башлагац бүлнискә апбарганнар // әни шында тапкан // мин мартта туган // бик каты ди су баскан иде ди // элек бит инде канаулар ниләр казылмаган // су

---

[151] түмә – муенса

тешкән инде асларына // бәрәңге сулар белән тулган инде // шылай килеп әйттеләр ди // аннары инде бер бабай цакыртып исем куштырганнар // азан эттергәннәр // бер бабай апкилеп // мулламы мәзинме // шул биш wакыт намаз укуцы дип әт′ик инде // анан шылай исем куштырганнар // анан шыннан бәбәйне күрергә туганнар килә инде // берәр азык / күлмәкме / селгеме // нәстә булса да / бәбәй күрергә дип киләләр // да инде// элек бит инде магазинда бер нәстә дә булмаган // пешергән инде нәстә дә булса // баwырцакмы анда күмәцме// wагымы кецерәгеме// ницек булган шылай пешереп караган инде// безнең заманда идәнгә утырыш булган инде//]

*Информант: Раҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*
*Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[әллә бәлли бәw итә кызым йыкыга китә // әгәр кызым йыклап китсә әбисе дә йал итә // әлли бәлли бәпкәсе дә кайа киткән әңкәсе// кайынлыкка җиләккә / бәпкәйемә бүләккә //

*Информант: Раҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Шыгырдан авылы*

[йырт башы бу бар икән дә ну хуҗа булган инде // мужет хуҗа булгандыр мужет былай болгандыр // и абый үгез булмагайы чурт булсын // балаларга эчергә сет булсын дип әйткәнен ишеткәнем бар //]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[туй барган wакытта йырлыйлар инде бетенесе // кыда да йырлый кыдагый да йырлый // кыда кыдагыйлар да йырлый // алар инде нинди мәхәбәт йырлары бар нинди мактау йырлары бар шундыйракларны йырлыйлар иде инде // ницек әйтим кызлар минем ул wакытта аңа ерәтем дә булмаган // күршең сиңа йомышка керсә беркайцан бүлеп цыгарма // үзеңә булмаган халдә дә күршеңә биреп цыгарырга // анансың ызгышырга тегел // талашырга тегел // күршедә нәстә кайтты икән мында дип кешедән кенләшергә тегел // дин тарафыннан да гупшем халыкка да шындый менәсәбәт инде // ни иминна дин буйынча гына // күрше хакы булгач бетен тешкә керә инде ул // иминна син дин белән булган ецен генә түгел //]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[еленге дип атала иде // елек бездә еленге дийәләр иде// сездә пәрдә инде ул // целтәр дә була башка тесле матириалдан // клинкурдан нидән йасаганнар // аларның инде кайсын ниткән кайсын үзе целтәрләгән // кул белән магазиннан алган түгел //]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Шыгырдан авылы*

[иремнең әтисе йук / ирем әтисез үскән // әбзәләргә тел йәшердем // сыңыннан тел йәшерсәм дә сыңыннан инде ацтым телемне сүләштек // кан′агаларым йараталар иде мине шындый // кан′ага белән кан′ата булган йыртта инде киленнәрне пич алдында гына ашаталар иде элекке// кеше йанына утырмый инде ул // менә ул пич алдына утыра да аңа чашкасында салып кертәләр // ашын да шында салып бирәләр // шул хутта ул пич алдында гына ашый иде сүләшми ул // кан′атасы белән сүләми //]

*Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Сыгыт авылы*

[сез кадерле кунаклар бит / утырыгыз// мин кувакалова камәрия // мин тептә райдә дә былай /паспортларда тептә райдә // әйдәгез // зийатдиновна // мин мең тугыз йез утыз икенце йылны сигезенце мартта туган // выт шыннан санап белегез // туксанга таба киттем ахры инде / дамы // кач′ан килдегез// эшем табылды / шекер икән // алма[152] матикларга цыкма келим дә бит / апцыкмый галийә / үзе ил батыры[153] / петен[154] нәстәне үзе ишә дә ыргыта // алла саулыкларын бирсен инде / ризыклары киң булсын / н′ан′агым[155] / балалар бәхетле булсыннар // йарар / синең әтәң әнәңнәр бармы // йарар / әтәле әнәле кеше бәхетле кеше ул // киц була да инде хазер / безнең халык вәт шылай күмәк җери тырган халык булган элек электән // киц була / пирвый урамга зыйылып утыралар / йырлыйлар / бииләр бетен авылны герләтеп // аннан сың кицләр була /ул кеннәрдә элгерәбезме / икенце кеннеме// аулак ейләре дигән кебек инде // мени җыртка зыйдык / мында килеп бийеп / җырлап бик аwылны күтәрә тырган безнең аwыл // бик күркәм / бик / ницектер кешегә / халыкка йарый тырган / халыкны күтәрә тырган // әлхәмделилләһи шекер //]

---

[152] алма – бәрәңге
[153] ил батыры – уңган, яхшы
[154] петен – бөтен
[155] н′ан′агым – иркәләп эндәшү сүзе

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[кызлар безнең җигет белән сүләп йергән инде ул //хазер йегет әт′ә мин шул кенне үләнергә тийеш / син гатаумы // гатау булсаң кас′е кенне цыга аласың миңа кийәүгә// кыз әт′ә мин шул кенне цыгам // шылай иттереп кызны алалар да алып цыгып китәләр/ аннары сың шыннан китә инде / аннары сың кийәү йуллыклары // гармуннар белән урамда кыз киленне утырталар / ул утыра / гарманист утыра / актыктан йерүце алтау җидәү утыралар да кене буйы ике кенме/ ец кенме урам ал′аналар гармуннар белән // кендез урам ал′аналар /кицен уже кунак мәзлеце була / киц кырын // шындый мында ец кен /дүрт кен әгәр ни булса инде күбрәк вакыт уза шындый бишәр кенгә кадәр шылай аwылны герләтеп / шылай җырлап бийеп гармуннар белән бетен матур матур уйыннар ун′ап/ матур матур җырлар җырлап йериләр иде шылай//]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[безнең аwыл күркәм аwыл / шындый халык белән бергә эшли тырган / халык белән матур гына йери тырган бергә // аwылыбыз зур безнең // ницә ике мең йырт иде безнең аwылда // без үскән вакытларда // ике мең йырт шул кендә шул аулак ейе киц була халык үwендә йәшләрне кетә // биген мында / тагын берсендә рәттән кемнең чираты җитә шында аулак ейе була иде // киц буйы тен ката [156] шул җегетләр кызлар // ну җегетләр кереп кенә цыгалар / бергә утырмыйлар // кереп кенә цыгып йериләр // аннары сың кемнең күзе тешә сиңа примир хәзер шының берсе тәрәзәне циртә дә тәрәзәгә // кас′ы кем кирәк // мени миңа шул кыз кирәк // шул кыз да аннары сың да мени цыланга цыгаралар / анда шындый йарык була инде / берсәк[157] йарык //җигет тышкы йакта йарыктан шылай сүләшәләр иде // җигет белән кыз // шындый нәстә сүзләре бар бетенесен бетенесен аңлашалар иде берсенә берсе //вәт шылай иттереп икенце кенне тагын бер җыртта рәттән шылай очиридлап бара иде // кызлар зыйып // җигетләр тышта тырып // кызлар ызбада булып аннар бийегән вакытта гына зегетләрне кертәләр дә анда инде йезек салыш ун′илар тегеләр белән тен ката ун′илар / бииләр / зырлыйлар //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[156] тен ката – төн буе
[157] берсәк – бераз

[безнеӊ аwыл хәзер әзрәк күренә / әле ул хә ике меӊнән ец меӊгә әз генә бер сүwәмгә[158] җитмәгән булган безнеӊ аwылныӊ зурлыгы // бәйрәмнәрдә туйлар вакытындагы бергә зыйылып шылай җырлашып бийешеп шылай кенне матур үткәргәннәр // елгәреге иске йырлар күп булган инде / алар хазер бар да истә калмаган шул / кызым /
бийе бийе ыстарак
бер айагы кыскарак
айагы ызын булса
бийер иде ыстарак //
шай иттереп кискән цабуны шылай зырлаганнар да аннан берсе цыккан да минем айагым кыска булса синеӊ телеӊ ызынрак /шай[159] иттереп берсенә берсе такмаклар әт′ешеп ун′ап утырган // алар берсен берсе күтәргәннәр матур җырлар җырлап // бик начеку бии торган егетләр булган безнеӊ аwылда // бетенләй чүгеп чүгеп чүгеп чүгеп күккә хатле сикерә тырган җигетләр бар иде // әл дә бардыр алар //но хазер андыйга җәшләр бик йермиләр //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[анда ырлаулар ырлап китүләр бик күп булды // мине дә ырлап киттеләр / кабак[160] тебеннән кызымны да ырлап киттеләр мында / мени бак[161] шул җыртта/ хазер мында бер кызым керде и әнәй әби килделәр // кемнәр килделәр // җигетләр апаны элделәр[162] дә киттеләр / ырлаулар бик бик күп булган ырлаулар / кыз урлаулар кызны ырлап китәләр // мәзлец йасыйлар инде / кемгә нинди кирәк нинди кызны сайларга кемгә кем килешә шындый берсенә берсе матур иттереп кенә сүзләр табып сүләшә торган булганнар// элгәре безнеӊ халык бик сүләмцәк[163] әрсез халык булган бар да // бергә эшләгәннәр / тату йәшәгәннәр // выт шылай бер кисәк икмәкне бүлеп бер кешенеӊ азыгы булмаса тату йәшәгәннәр// безнеӊ авыл эшцән булган // кайа барсалар да тирә йактагы аwылларга цыгып эшләп эшләп кат′а тырган булганнар //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

---

[158] сүwәм – сөям
[159] шай – шулай
[160] кабак – капка
[161] багу – карау
[162] элү – эләктерү
[163] сүләмцәк – сөйләмчәк

[без инде илле бишенце йылны армийәгә киттек // армийәдә служит′ иттем // ул вакытта германийәдә ец йыл йарым служит′ иттем // балтыйк кырыйында висмурт дигән шәхәрдә // шындый службаны шында ец йыл йарым служит′ итеп кат′тык // шекер / исән сау // армийәгә киткәндә бик кызык була иде безнең // атны җигеп йахшы гына ат җигә идек // аны инде мәнә селгеләр белән бизәкли идек // бер йакка кызлар да утыра иде / менә шундый аwыл кызлары инде җигетләр гармун белән урамны әл′әнеп йырлап китә идек инде // аннары кызлар /матур кызлар инде / безне йахшы исән сау кайт дип йаулыклар биреп җибәрәләр иде цигеп // шылай иттереп аннары кулйаулыкларны инде саклап йергән йараткан кызыңның инде истәлеге дип / киткәндә аwыл җыры җырлый идек инде //

китәм инде /китәм инде/
китәм инде каласыз /
без киткечтән кемнәр багар
сез сандугач баласын //

мәнә шылай инде армийадан кат′кац шул кыз инде мине кетеп тырды // шының белән хазер илле биш йылмы алтмышка йакын йәшибез инде // алтмыш дүртенце йылны сим′йалашкан[164] идек / шылай итеп әл дә мени шул карцык белән исән сау йәшәп тырабыз // шындый халләр//]

*Информант: Юсупов Равил Сәләхетдин улы, 1938 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[сугыш йылларында әнәйгә алланың рахмате аусын / без бер малай да бер кыз үстек / йәшәдек / бер сыр′ асрады / казлар асрады / ашатып ецереп безне шылай үстерде // аннары сың әтәй сугышка киткән // мин ец айлык лан булып калган // әтәй сугышка киткәндә шылай әнәй белән йәшәдек // шылай китеп бардым // үзебез шыгырданнан клайыц мәцете бар бит шының йанынннан мин // анда хазер энемнең катны тыра ланнары белән / әнәй үлде инде // мында килдем / кан′ам белән ирем генә идек // кан′ам белән унҗиде йыл тырдык / аннары ул китте[165] // аwлактагы җырлар инде безнең аwлактагы җырларны хазер белмим дә инде // ынтылган да алар хазер // нәстә инде айзар wайзар ун′и идек /шул айзар гелзәем дә wайзар гелзәем // шылай урталыкларга керәсең гел кебек бегеләсең / кем ецен езеләсең дип ал′анып ал′анып шында кызлар тытыныша // җигетләр кергәц кызлар бүлмәгә кереп кацалар иде / җигетләр кереп утыра гармун ун′атып бийетәләр иде // без битләрне каплап цыгып цыгып бии идек инде //бик каты

[164]симйалашу – өйләнешү
[165]китү – үлү

берзаман мында петенебез пары күлмәкләр җүләттек[166] сабантуйына // урам кызлары белән бер бер цыгып биибез хазер // мында берсе сүли инде / күренми / без ишетәбез генә // былар ди кас′арада күлмәк алыштырып елгерәләр дир / былар безнең барыбызның да пар күлмәк кигәнне белмиләр инде / былар һаман бер күлмәк белән бер кеше // цыккац ай аннары түгәрәк ун′арга тытындык та барыбыз да бер тесле күлмәктән / ай дир былар бар да бертесле күлмәк кигән булганнар икән дир / без йаңылыш[167] карап тырабыз икән дир / качан гына кийенеп елгерәләр икән дип карап тырабыз дир // бер кыз кереп кенә китә / икенцесе килеп цыга бит инде шул арада // тигендә инде бик каты матур / йараткан кызлары цыкса музыканы үзгә теслене ун′илар иде // йә аллам / гармунны тартып җибәрәләр иде бийергә тытынгац / айакны да катырак тибәләр иде йараткан кызлары цыкса // йаратмаган кызлары булса әле йурый малый[168] гына бийетәләр иде // аннарысың бер җигет белән бер кыз сүли[169] бит инде / аннары бу кыз аны ташлый // ай шында бийегән тештә кызлар йанына барып атамстит′ итеп кат′алар иде // мыни бийеп тырган тештән гармунны туктаталар да күтенә тибәләр иде кызның // хазер тибеп кара әле кызларның күтләренә / бәбәгеңне[170] казып ала // тиге инде аннары хурланып кереп йылый // әбисенә берсе әт′кән дә күтемә типтеләр дип / йә аллам бик каты авырттымы дип сыраган дир // тиге хурланып җылый инде мескен / әби сырый дир каты авырттымы дип // үзем дә бер җигет сүләмә келәп йери иде дә / мәтәм кирәкми димен // ул карт җигет инде / сүләшмим димен // мәтәм мин синең кебек җигетләр белән сүләшмим // тагын инде бийергә гарманист инде бу // хазер цыгарга бит инде // биим ха[171] биим дә бер ике кыруг кына ал′андым туктаттылар да куйдылар // бийедем бийедем дә/ тешеп тешеп бийедем рахатләнеп туйгынца // и аллам дип кереп китмәдем // келделәр шында инде кул цабып цабып // йугалып калмадым //ай бийедем шылай // шындый кызыклар // каз йылку ул әл дә бар инде// ызба ышку[172] // ызба ышкып йери идек урамда рәттән / бетен кешенең ызбасын йуган / бетен кешенең казын йылккан // бүлмәгә җиткәцтән ызба йуып барасың да / авыл йыртлары бит пумаласы бетен нәстәсе // бар да без киттек мунцага / без киттек мунцага // кунаклар бар да мунцага китә // минзада гына кала мында бүлмә җуарга // йарар йарар калсын /

[166]җүләү – тегү
[167]йаңылыш – ялгыш
[168]йурыймалый – юри
[169]сүләү – сөйләшү
[170]бәбәк – күз
[171]ха – хәзер
[172]ышку – юу

калсын минзада калсын дийәләр иде // анда кучарканы[173] да кымлап кымлап ышкыган // бүлмәнең петен пакыс′ы[174] миңа кала иде йуарга // петен кеше мунца кереп кат′а / мин әле йуып петмәгән // аннары китә идем мунцага // шылай эшләтәләр иде / рахмат йаусын / эшләгән дә бер тештә биртелмәгән[175] дә / эшләгәннән кеше үлми / алла саулыкны бирсен // шылай әле мени пецән цабам // шылай безнең халләр // сугыш вакытында да әнәй ац үтермәде / ашатты/ кийендерде/ шылай ацка аптырамадык // ике лан үстерде / нужа[176] цигеп терлек асрады // ит ашадык / май ашадык // мина җитмеш дүрт була/ герләп тыра йыртым / герләп тыра ланнарым //]

*Информант: Гафурова Минзада Сабирулла кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[миңа кеңелгә // мында мине ыланшакка[177] саныйлар // мыни берсен казанга барган иде бер кызым апкат′ты / вынугым апкат′кан // бусын килнем апкат′ып биргән иде // бусын тагын кайадыр бардылар мыни усын нитеп тә петердем // мыни мында да мәтәм кецерәк йасадым // кунакка барам ник бармыйм // бусын мәскәүдән кызым алып кат′кан иде // мин тиле карцык кебек петенесен сүлим // кешегә сүләмәгез // мин мактандым инде сезгә да бит да // кеңел күрмәге инде//]

*Информант: Хамбикова Минкадирә Зәйдулла кызы, 1925 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[безгә аны ырлаган да / мыны ырлаган димәделәр // тегеләй дә былай / шекер хыдайга// кызлар мыннан су ташыйлар иде елеке // кецерәк кызлар мының кебек / әгәр бармагыгызны гына тыгыгыз дийә идем / алай әйбер әтмиләр иде / шекер хыдайга / җиде ланнан миңа жалу килмәде // эшләп ашасыннар / эшләп ашыйлар әл дә / кайа гына бак шул / берсәк кенә гембец итә / бәрәм / кулым карала бу инде ни каны йук ай ите йук берсәк каны бар ахры да // хазер терлек кирәкми // итебез бар / таwыкларыбыз бар/ әле кач′ан гына асрамый башладык // бик каты күп асрадык / җигерме бишәр каз җылның җылында // әбийең зерә картаймаган инде / н′ан′агым[178] / терлексез тырмадык без / ац үликме / мин бер кила ит итәгемә салып кат′мадым сумкага салып // йасадык[179] та ашадык / терлек асрадык та суйдык / сыр′ / тана // теш куйдырырмын дидем дә бер ике ец

[173]кучарка – кисәү агачы
[174]пакыс′ – пычрак, шакшы
[175]биртелү – имгәнү
[176]нужа – җәфа
[177]ыланшак – бала-чага
[178]н′ан′агым – иркәләп эндәшү сүзе
[179]йасау – эшләү

йыл алыннан инде / мин әт′әм үлеп китсәң тешең калыр // таки куйдырмыйца калдым шылай //]

*Информант: Хамбикова Минкадирә Зәйдулла кызы, 1925 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[безнең кизләвебез бар // кизләү җасадык // петен кеше су ала// үзебез җасадык кем җасый // тәмне // ад′а ецегез// выт шылай н′ан′ак // умер буйынца терлек асрадым / каз асрадык // җиде ланга мунца булган / сыр′ булган / үзебез терлек булган / суйып ашаган // ланнар цирләмәгән безнең / җиде лан выт бер лан үлде безнең / ну авыр күтәреп кан тамыры езелә дә үлә //]

*Информант: Хамбикова Минкадирә Зәйдулла кызы, 1925 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[пирвай калхузда эшләдек / н′ан′агым// кыш кене цабаталар кийеп малатил′када эшли идек // аннарысың ырлык ташырга бара идек / ырлыкка // аннарысың нигә нәстә диим инде / аннары урман кисергә безне алып баралар иде // бездән киләме килмиме // выт шылай ац без // әтәйдән бишәү калган без // әл дә әле дүртәү тырабыз без // хазер туксан йәшемдә арлы бирле сүли дә башлаганмындыр инде // шылай дәртләнә дәртләнә инде нигә бардык / торфка киттек // әй йук нидә чабаксарда ваинный завудта эшләдем әле // бу минем малайым // берсәк утырып тырыйм әле мин// ад′агыз залга // аннарысың мәскәүгә бардым инде / торфка бардым // аннарысың бу бабаң белән ике йыл җередем җередем дә инде / ницектер шылай итте // аннары шыгырданга күцеп килдем / үзем ызын куакныкы // син ызын куак мәллә/ кем кызы син / ай ницек белмим туган илемдә / минем быратым[180] бар анда тукайыв рахимулла // кем сәрбийе диләр сың анарга // әй бардыр инде йарар/ ад′а мин киткәнгә алтмыш ике йыл /аннан мин киткәцтән туган кеше дә үлгән уже / минем тиңнәрем дә үлеп бетте инде // хазер мин шыгырданныкы // мин мында килдем дә хазер / кеше үwенә килдем инде // аннарысың бер ызба йасадык / аннарысың җиде ыланыбыз // җиде ылан аларның барсы  дүрт малай / дүрт малайны да салдатка җибәрдем/ кат′ардым // выт шылай аннарысың инде хазер бер малайым үземә дигәнем мени мында калды / бер малайым үлде / аwыр күтәрә дә ике кендә үлә// миңа малай бар әле мыни / җилдерә // җигерме вынучкам бар тагы / җигерме тегеләйе/ ехе / мында шыгырданда бер кызым бар / аныкы да җиде ыланы / берсенеке алты / берсенеке җиде // шылай мында күп мин // бер әби кырык

[180]бырат – ир туган

кешегә йарар инде / аллага шекер / шылай / шылай / н′ан′аклар/ шылай умерем үтте минем //]

*Информант: Хамбикова Минкадирә Зәйдулла кызы, 1925 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы.*

[ацлык безгә тиде инде / н′ан′агым/ ницек тимәсен // ац тырдык та / кецеркән[181] дә ашадык // аннарысың айагыбызга цабата да йук иде // атасыз кешегә анда бернәстә дә йук // шылай алай да әле ацка йалангацка үлмәдек әле // ницек тырганыбызны белмим // әл дә алла бар шылай // ни карлы су ецә идек / мин әл дә тырам әле мыни// әле аwылда рахат′ йәшиләр / айаклары былай була/ бар да йамбалит [182] / эшләмиләр// батыр бездән бит батыр җырак тигел / алар астанувкага цыгалар да басып тыралар // мин атлап бара идем / канашка да атлап бара идек без / бәбкәм/ канашка да // син кас′ы аwыл кызы сың // гелшатның кызының кызымы // ай гелсириннекеме син // әй нигә бан′у әптәй минем белән бергә эшләдек инде // ул былай карасам әл дә минем күз алдымда бан′у әби //]

*Информант: Хамбикова Минкадирә Зәйдулла кызы, 1925 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы.*

[әтийемне сугыш вакытында минем термәдә атып үтерәләр // авыл байы булган минем әтәй // мин ул байлыкны күрмәдем / алты йәшемдә генә күрдем // мыни шындый йыртларны сүтеп китәләр // йазмыйсыңмы кызым шыларны // шул урамда тырдым инде аннары сың мышында әби бар иде аның дүрт кызы иде / алар да шылай йугалып беттеләр инде // бу урында аның йамали атлы малайы бар иде / ул тыра иде / ул да шылай авырлык белән үлде инде // минем йәштәге бер малайы бар иде / шылай ул да үлде // әтәй кырык икенце йылда термәдә алатыр′да үлә / аннары миннән сыңгы бер кыз бар иде / ул кызны шул инде безнең әйберләрне зыйарга киләләр дә ул кыз нидә була // ул ызбаны безгә чуаш бирә / шигали чуашы диләр // мыни мында сигез киламетр бездән ары әтәйнең дуслары / әтәйнең җигерме алашасы була // йанашада[183] этийем белән бертуган абый була / абыйныкы да унбер була / бик күп кырлар цәцә / сату белән эш итә // аның исеме лениградта ул′йанда анарга пугачев дип кушканнар исемне // безнеке булырга ницек сың әле минем аңым да нацар инде хазер // шындый хәлләр булды инде // бик күп миннән сыңгы бәндәләр күрмәсен / мин шыны сырыйм алладан // кийәүгә цыктык инде илле икенце йылны // йук

---

[181]кецеркән– кычыткан
[182]йамбалит – инвалид
[183]йанаша – янәшә

ырламаган / танышып кына киттек // минем әнийем мыннан ец киламетр бикшик бар / кыр бикшиге диләр// казанда сез белә тыргансыздыр анда газит суккан[184] тештә редакцийәдә эшли минем апамның малайы // эшли дә бит / мин белмим шул нинди газит икәнен / ул үзе врач та // аның әбисе белән минем әнәй бертуган булган бишетнеке // мин мында туып үскән / аннан ар′ылып кат′тым инде // шылай анда әнийемнең туганы бар иде // алар йахшы әпәйле[185] кешләр[186] иде / мине димли дә и мин шылай барам инде // аннарысың тырырга туры килмәде дә бала белән кат′тым шул инде / бер бала белән кат′тым //]

*Информант: Пукачева Сәгадәтбану Мәвлет кызы, 1929 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы.*

[аулак ейләр бик матур була иде/ йәмне була иде / җигетләр күп иде / гармун күп иде // шылай бар кийемебезне кийеп бара идек инде / анда кийем йук инде йахшы // бездә денйасы белән йук инде // бездә генә тигел / расийәдә туклыклы ацлыклы вакытлар күп булды //]

*Информант: Пукачева Сәгадәтбану Мәвлет кызы, 1929 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[йәш вакытымда калхузда эшләдем // калхуздан киткәцтән үзем загат кантурга эшкә кердем // аннан анда җигерме йыл эшләдем батырда / аннан сың нидә укып цыктым ец йыллык курсны // чабаксарга күцерделәр аннары үземне // нигә / чабаксарга бер райунга чабаксар аликувский райунда эшләдем утыз биш йыл // аннан сың инде мыни шылай эшләп киттем // балаларыбыз күп булды / барысы да зур белем белән // унау иделәр/ ецесе үлде / тагын җидесе тыралар / дүртесе вырач булып эшли / берсе палкувник пракарур / казанда эшли / берсе генеральный директыр казанда эшли / тагын кызым әлмәттә эшли / нәфисә // хатыным бишет авылыннан / историй шылай / алыннан[187] үләнгән идем // үләнгән идем дә хатын кийәүгә китте // кийәүгә киткәцтән анда ире кинашырга килде // аннарысың аның белән ниттем дә алты ай термәдә утырып цыктым // аннан сың кытылып цыктым термәдән аправдат′ иттем инде // аннарысың ни эшкә бардым / эшкә бардым да уңгәне үләнеп кат′тым // аннарысың алтмыш биш йыл бергә тырдык / ун бала үстердек / ецесе үлде / җидесе тыралар //сугыш йылларында кырык дүртенце йылны армийәгә киттем / аннан резервыда тырдым /җиде йыл служит′ иттем // шылай гымерем узып китте // шыгырданга

[184]сугу – бастыру
[185]әпәйле – тук
[186]кешләр – кешеләр
[187]алыннан – алдан

илле беренце йылны // илле беренце йылдан тытындым мин эшкә /эшләп йердем шылай / бер дә туктамадым / эшләдем / картайганымны беләм / картайгацтан эшли алмаганны // выт шылай иттереп иллебиш йыл эшләдем / аннан сың инде иптәшләр белән мәцеткә йерим / аллага шекер / алла кабул гына итсен намазларыбызны // шул балаларым тәүфиклылар булдылар /аллага шекер / аракы эцмиләр / тәмәке тартмыйлар / шындый матур тырмышта йәшибез //]

*Информант: Купкенов Әнвәрбәк Зарифулла улы, 1927 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[гармуннар күп килә иде инде // свит [188] жук / лампы иде / лампының пузырларын[189] бик каты җуып җуып аца идек /бик каты естенә кырым куйа идек / кырым тигел ни күмер куйа идек / сикермәсен дип инде // аннан җигетләр кереп тулалар иде дә гармун белән бик каты безне бийетәләр иде инде // аннары цыгып китеп тагын үзгә[190] терле җигетләр керә иде // ызбалар[191] кецкенә иде ул вакытта // без бүлмәгә кацып тыра идек инде // җигетләребез килә иде дә / җигетләребез күрсен дип шылай әз генә урын калган сайын цыгып күренеп керә идек инде / тиге мин мында дийеп инде // аннары сың инде кемнең кызы бар шул җигетләр генә калып безнең йанда утыралар иде // утырмыйлар иде / мәнә йарыктан сүли идек // чү әле / безнең йанда башта артта калып үзебез генә ун′и идек инде / уйыннар ун′и идек инде / йезек салышлар ун′и идек инде // шылай әз генә калып инде // аннарысың җигетләр цыга иде дә мышылай ишекләрдә йарык инде шыннан йарыктан сейләшә идек инде // әгәр сүләргә цыкмасаң тагын бер кенне бийергә цыккац җигетләр күткә тибә иде // кунакта күткә тибәләр иде // гармун ун′ауцы җигетне кетеп тырганда бийергә тешсәң гармун туктата иде дә син келкегә кала идең инде // ни басып кала идең бийеп // безнең вакытта бик каты шындый була иде //]

*Информант: Купкенова Рокыя Низаметдин кызы, 1944 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[елекеге киленнәр йаман иде ул / н′ан′ак / ул хазер генә ул / и аллам/ әгәр ни анда бит җуыну да нитү булмаган // кымган белән әгәр кымган белән кыйынмасаң беттең / үтерәләр инде кан′алар[192] пакыс′[193] җери дийәләр иде //

[188]свит – ут
[189]пузыр′ – лампа пыяласы
[190]үзгә – башка
[191]ызба – өй
[192]кан′а – каенана
[193]пакыс′ – шакшы

кыш суыгында пайтастына[194] цыгып / анда урын булмаган әле // анда кайвакыт кымганны селкеп[195] тә кергән инде / ату кан′а тикшерә / кымган тулы керсә кыйынмаган дийә иде шылай // хазерге заман ул кайа // елекегеләр бит алар цын бәхетсезлектә йәшәгән кешләр // ашарга булмаган / кийәргә булмаган н′ан′аклар / хазерге заман ул // киленнәр тешкәц бетен кеше куркып каца иде бит / / калдыралар да кацалар иде наса[196] // шының кебек кан′алар бар да китә бит инде // ай әле дә шылай наса инде / киленнән куркып кацалар/ килен килә башласа //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[елек кешедән барып кийем сырый идек кунакка барырга // аннары анда кат′ып йереми идек / куна идек // без аның хәтле нужа күрмәдек // безнең әнәй уңган кеше иде / алты ылан үстереп кан′адан калган // безнең әнәй җүли[197] иде / чуашка да җүли иде күлмәк/ мукшыга да җүли иде күлмәк / кас′ы ын китерә иде / кас′ы тыз китерә иде / кас′ы әпәй китерә иде / шылай җүли идек // хазыр куна идек инде кат′ып йереми идек // курка идек җегетләрдән // ха җигетләрдән куркмыйлар // елек салам кертеп түши идек мышылай/ салам / аның естенә мышындый кавер зәйә иде хазяин / анда бер башта мында башка баш куйып йыклый идек шул сәләмә[198] ызбада // ескә йабынып кат′а идек / бик каты курка идек // замана аwыр вакытта үстек без бик каты // аwыр иде замана / аwыр иде // тагын нәстә // мени сүләп бирдем бит күлмәк кешедән барып сырый ала идек // күлмәк анда сәләмә күлмәк // күлмәк жук/ анда елгәре итәкле күлмәк кийәләр иде/ итәк салган күлмәк елгәре үк цыкты анда / безнең вакыттук цыкмады әле/ анда итәк сала идек // мин үзем җүли идем //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[бизәнәләр иде // мин үземә сертмәдем / биткә дә сертмәдем // алар йук / йук / берсәк кызлар мышылай сертеп ала иде бизәү[199] / кызлар мышында гына // сертә тырганнар жук / кызлар исен дә белмәгән аларның / йук//]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

---

[194] пайытасты – лапас
[195] селкү – кагу
[196] наса – бит
[197] җүләү – тегү
[198] сәләмә – начар
[199] бизәү – бизәнү әйберләре

[елгәре ни булган // бернәстә дә йук иде // килеп укытканнардыр да / ат белән килгәннәр // безгә хатле елгәреге заманда ат белән // аннарысың анда ат белән килә дә инде / йат аwылныкы синдә ец кен / дүрт кен тырган / сиңа бер лау керткәннәр / тигенәргә тагын бер // минем заманада йук иде ул туй //]

*Информант: Янтыкова Зәйтүнә Шәфигулла кызы, 1930 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы Шыгырдан авылы*

[без татар тигел /мишәр/ без каты сүлибез// цәй цәй инде// җырда бит чәчәк дигән / цәцәк димәгән // адʼа йаздырасызмы // мин кийәүгә киткән идем дә хазер шул җырны җырлыйм //
сызлып алсу таң атты / кышлар канатын какты/
сау бул бәгрем диdeң бит алсу бер таңда /
йалгыз сандугач шунда безнең каушуны теләп
эзлеп эзлеп сайрап басып йәш түкте//
хатерлә син / иркәм / айрылган таңнарны /
хич бервакыт сеймәм диdeң башка йарларны //
бик сагынырмын диdeң / хатлар йазармын диdeң /
истәлегем булсын дип бер йаулык бирдең //
йарымның бүләге дип йерәгемнең йалкыны //
армийә сафларында мин саклап йердем //
хатерлә син / иркәм / айрылган таңнарны /
хич бервакыт сеймәм диdeң башка йарларны //
катʼтым илгә талпынып / күремен дип ашкынып /
йарым кетә мине дип йарсынып //
ә син миңа суынып куйгансың /
башка йарларны сейгәнсең мине ынытып //
хатерлә син / иркәм / айрылган таңнарны /
хич бервакыт сеймәм диdeң башка йарларны//
килде ул // минем ике ланым / кырсакта бер / бер малайым цабып йери // мин бәлеш йасыйм // килде / йылады / ырштым / шул җырны җырладым // кадирә апа мышылай тетрәп тырам дир нургали катʼмаса йарый /нургали катʼмаса йарый дип әтʼәм дир кадирә әптәй цыгып бастым дир мени // айыртам сезне дир ике ланны да үземә йаздырам дир // выт шындый историйә булды безнең // йарар инде / бәхиләсеннәр генә инде мине // тешемә керде нургали хазер / әле күптән тигел тигендә басып тыра ташладың дип // кил мында дир / кил дир мында дир кенләп инде / кил дир // килдем йанына да аннарысың исемә теште уйанып киттем дә туктале мәтәм / җендер бу /аннары уйандым инде шылай //

ницектер хыдай тәгаләә уйатты инде шылай // йанына бардым мышылай / җендер дидем инде // аннары шылай тешемә керде шул шылай кенләп //]

*Информант: Шәрәфетдинова Сания Әбделвәли кызы, 1935 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

[идәнгә җәелгән үзебез суккан каwир кемдә палас инде // үзебезнеке // үзебез тукыган // сәләмәләрне җыртып җыртып шылай чүпрәкләрне искергән әйберләрне җыртып // мыннан ызатып инде бер айак белән басасың / берсе белән басасың мыннан цукыйсың / бәрәсең дә бер цүпрәкне тартасың да // аның айрым ыстаногы бар // аның шүресе бар // шул ыстанок инде караwат кебек мыннан былай бастырып куйган // аннары аның ике тересе бар / ике тере кылыцы бар тарта тырган // усы кылыц атала // ул урнаштырып куйа иде синең әйбереңне / бик матур була иде ул // тартасың мышылай // әле безнең бар ул // киндер суккан заманага ләкмәдем // табын салфиткаларыбыз мыни шул ул // мана ул / мана / бу цүпрәк тигел бу кулга бирә тырган тукыган ул // мыни җептән ызын ызын җепләрне цырнап ызатып // аның ызата тырган нийе бар ызын гына шылай / шыннан ызатып йериләр // аннан тукыйсың мыннан // цүпләгән селгеләребезне без мәйет естенә йабабыз / йырт сайын бар ул безнең / һәр йыртыбызда бар //]

*Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

[тел йәшерүме// ирем әтисез үскән/ йәшли калды // ә әбзәләре[200] белән тел йәшердем // бергә йәшәсәк тә инде// сыңыннан ацтым телемне // сүләштек // йараталар иде мине шылай // кан′а белән кан′ата булган җыртта инде киленнәрне пиц алдында гына да ашаталар иде элеке // кеше йанына утырмый инде ул // мыни естәл йанына // аннары ул пиц алдына утыра да/ анарга мыни чашкысын[201] да салып кертәләр / ашын да салып бирәләр // шул хутта[202] ул пиц алдында гына ашый иде// сүләми ул// кан′атасы белән сүләми // да/ сүләми //]

*Информант: Кувакалова Камария Зиатдин кызы, 1932 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[мин кувакалова камәрия / кыстук зиәтдиненең кызы / ад′а язасыңмы син // мин умбер унике йәшеннән калхуз хезмәтендә алибатыр булып эшләдем/ шылай / беренце урында булып эшләдем / алибатыр димә йарар / шылай // мин

---

[200]әбзә – абый
[201]чашка – чокыр
[202]шул хутта – шул рәвештә

кувакалова камәрия зиәтдин кызы / гымер буйы ланшак бахытта минем әтәй үлгән / мин әтәмнән ике йәшендә калган // мин ике йәшендә булган әтәй үлгәндә // ец йәшенә цыккацтан анама йәреп мин калхуз кырына утауга цыккан аналарыма йәреп // әнәм/ әнәйнедә әтимме // минем әнәм бик ыста мастерскойда эшли тырган булган / вәлимехәммәт кызы анам зәйнәпбану / мастерскойда аwыл халкына йаулык / нәстә кирәкләрен барын да нитеп тырган / йасап җүләп тырган барына да // аwыл хезмәтендә әнәйнең хәрбер эше / хәрбер йергән урыннар исемдә тыра / мыни беген дә цыгып эшләмә келәп тырам // мин үзем хазер / ницә йәшендә әле мин / сиксән дүрт йәшендә // сиксән дүрт йәшендә булсам да / мыни беген цыгып калхузның йарты хезмәтен итәләм / әлхәмделилләхи шекер // саулыгым бар // ланнарым әлхәмделилләхи шекер / улым бар / килнем бар // икесе дә бик каты йакшылар / мине күккә генә күтәреп тыралар әлхәмделилләхи шекер // ланнарымның тәрбийәсендә тырам / ланнарым мине бик каты тәрбийәлиләр / аллахы тәгалә үзләренә дә саулыклы / тыныцлы тырмыш биреп тырсын // аллахы тәгаләнең ирке зур // минем үземнең ике кыз балам бар / икесе дә институтта укыдылар / эшлиләр // эшне әй дип тырмадылар / алибатырлар булдылар / эшне бик сүеп эшләделәр диң // килнем бар / малайым бар // аларның / ницәү әле сез // килнем белән малайымның ике баласы бар // берсе зефәр / кызы зелфийә / малайым зефәр // тәртиплеләр / шкулда укыйлар / институтта укыйлар / бишле билгеләренә укыйлар / тәртиплеләр // аллахы тәгалә саулыкларын бирсен / ризыклары киң булсын / әтәсе белән әнәсенә хаерлы саулыклы умер бирсен // тәртипле балалар үстерделәр / аллага шекер // үзем дә тәртипле балалар үстердем / килнем белән малайым да тәртипле балалар үстерделәр // әлхамделилләхи рабил галәмин // бәхетле булсыннар / саулыклы булсыннар/ укуларында гел йакшы укып тыралар ланнарыбыз / аллага шекер //]

*Информант: Кувакалова Камәрия Зиатдин кызы, 1932 елгы,*
*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[башладыңмы // мин шакурова гелинә зарифулловна // мин сугыш бахытында[203] туган бала // без сугыш бахытында / ацлык бахытында бик аптырап / кецеркәннәр[204] ашадык / алма[205] йафраклары // тагы нәстә // сыр′ җигеп / сыр′га азыкка бара идек камел′га // цабаталар кийеп ышкулда укыдык // анарга калутка йасап бирәләр иде / цабата тебенә // аннары сың тагы нindиләрне сүлим // безгә

[203]бахыт – вакыт
[204]кецеркән – кычыткан
[205]алма – бәрәңге

әнәйләр материал алалар иде / бәз // аны безгә манып / күлмәк йасап[206] бирәләр иде // без бик күп йаланайак цапкан // безнең әтәй сугышка китте // без җиде бала калдык // самый зур бала иде безнең унбиш йәшендә / әптәй / трактыр белән эшләде калхузда// аннары трактырдан сың камбайда эшләде // усы ылы апабыз була // дүрт абый кырахмал казып / кырахмал апкат′а иде дә / аларны без пешерә идек / кыртларын арчи[207] идек // выт шылай / бәбкәм // безнең тырмышлар шындый булды // тайакка калхузда эшләдек // хазер безнең әтәйләр вайнада[208] булса да / вайнадан кат′каннарны шындый хуплыйлар[209] / вайнада үлүцеләрне берсен дә хупламыйлар // алар йатып калган шында // тул′ке вайнадан кат′каннарны гына күтәрәләр / безгә бернинди пумыш та бирмиләр // безнең әтәйләр ранный булып кат′телар туже // булдымы / кызым // мин җиденце классны петердем дә / җиде класс петергәцтән пуштал′онга эшкә кердем / пуштал′онда унбиш йыл эшләп цыктым // аннары пуштыда телефонистка булып эшләдем // аннан да цыккац / пырдависка[210] кердем / пырдависта эшләдем // мин үзем батыр районы шыгырдан авылында туып үскән // хазергы бахытта кызыл камыш аwылында тырам // аннары тагы / әтәй сугышка киткәцтән әнәй пуштал′онка иде / әнәй картайа тешкәцтән бер абыйым / абыйымнан сың мин булдым // уналты йәш иде мин турыфка киттем / дүрт ай турыфта эшләдем // кийем кирәк бит // әтәй войнадан кат′кац җиде баланы карарга кирәк // аннары тагы нәстә / тагы нәстәләр сүлим икән инде // урманга бара идек/ ни/ сыр′ җигеп утынга бардык // пытаклар зыйа идек / циклаwык[211] цыбыгы кисә идек / пецәннәр ташый идек / уракка бара идек // анда җигерме бишәр сутый бүлеп бирәләр иде // быруцак цаба идек // выт шыларны барын да искә алдык // хазер күбесен ыныткан инде // хазер мин дә җитмеш сигез йәшендә  җитмеш тугыз белән барам // шылай // зелфийә минем кызым диим мәллә // үзем дә биш бала үстердем / бишесе дә урнашкан / шекер / әлхамделилләхи шекер// алла саулыкларын / тәуфикларны бирсен // аларның изгелекләрен күрергә миңа насыйп булсын // булды //]

*Информант: Шакурова Гөлинә Зиннәтулла кызы, 1938 елгы,*
*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Кызыл-Камыш авылы*

[резинка итек белән кыш уртасында барабыз // утыз гырадус салкын // ник резин итек белән барабыз // тиз тиз барырга тиз кайтырга // үгә кат′кац та

[206]йасау – тегү
[207]арчу– чистарту
[208]вайна – сугыш
[209]хуплау – күңелләрен күрү
[210]пырдавис– сатучы
[211]циклавык – чикләвек

эшлисе бар // бәлки шына күрә дә айакларым беткәндер инде // хәзер йәшләрнең дә айаклары йук // нәстә сәбәпледер аңламыйм //]

*Информант: Билалова Зөлкидә Шарифҗан кызы, 1944 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Шыгырдан авылы*

[аwыл халенә кат′икмы инде хазер // сугышны петердектер инде // аwыл халыгына хазер ашарга бер нәстә дә калмагац / ник калмады инде ул / күбрәк фронтка бирдек / калхуз ашаткалады дийәргә кирәк инде / ул бит ланнарга барына да җитәрлек бирмәде // кырда нинди үләм[212] бар / барын да зыйдык/ әремнән башкасын / петенесен / ул үләмнәрнең исемнәрен сез белсәгез генә / мин белмим // патамушты аларны киптердек / җуды әнәй / киптерде / шул кул тирмәне[213] белән мышылай ал′андырды// әлеге дүрт килаграм ын дигән идем бит инде / шул дүрт килаграм ынны иләп / петен нийе калдырган/ тыра ул/ аны терлеккә салырга тигел / шул үләмгә салып / аннары сың инде кырахмал[214] да кушарга бит әле мында / ул кырахмаллар / мыни быйыл калган церек алма[215] / цереми иде / мышылай л′ачырдамый[216] иде / табер җәйгә / беләсеңме // мыни ницек әт′им инде / пешер пешмәс буалма[217] кебек иде // шыны да тагы туздырып[218] киптерәләр дә / прашук була инде ул настайашый / крахмал дисез наса[219] / мыни кырахмал / шыларны барын да бергә салып / тарттыралар и бер дигән пәрәмәч инде // ул ацы инде бик каты / мин аның ацылыгын бик каты йакшы беләм // ә ашар ецен инде/ күп кешедә сыр′ асырады / асырамады димим/ сыр′ асырамаса да / кәзә[220] // кәзәгә сталин сыр′ы дийәләр иде инде / сталин сыр′ы // безнең сыр′ бик каты күп бирә иде // әле нурттыйн мыны недавны гына сүләп китте / сез дир йакшы йәшәдегез / тере[221] калдыгыз дир // шул пажалуйны / күмәцне инде пажалуйны / шул сыр′ сете белән ашый идек // калганы беләнрәк инде / аны сата да идек шул / аның усы да бар // район бездә иде / әнәй кен дә мине кулымнан тыта да / шул ниләргә / бал′ницка тешә инде / шул кайа интилигенцийә эшли инде // бал′ницта эшлиләр иде / хазер/ ыныттым бит / аптиктамы ниме / ни катны / брайылка / нидә ваенкаматта брайылка ире иде /

---

[212] үләм – үлән
[213] кул тирмәне – кул тегермәне
[214] кырахмал – көздән җирдә калып өшегән бәрәңге
[215] алма – бәрәңге
[216] л′ачырдау – сыеклану
[217] буалма – алма
[218] туздыру – тарату
[219] наса – бит
[220] кәзә – кәҗә
[221] тере – исән

аптикта катны иде / хахуллар // шул инде мине туйгыйнца ашатып йибәрә иде / әнәй сет сата / шул сетләр белән / йымыркалар белән / әнәй йымырка да апбара инде / безгә йәшәр ецен / ул акца бирә иде / акца бар / былай үзгә акца йук // әнәй ул акцага инде / кайа барып алгандыр / мышының хатле пукыл′ләре[222] алалар иде // аларны пиц[223] башына куйалар иде инде / кызып йатамы инде / нитеп йатамы // әгәр ут ни алырга булса / кем йаңгызы йергән / анардан күмер кереп алалар / уф уф ереп инде уцагын кабызасың / башка нәстәләр эшлисең // анарга аннары сың цакма ташы бар иде мышындый / ташлар бар иде инде / мунца ташы инде ату булса / ну былар тигел тул′кы / казып алган йалтыраwыклы бар бит инде / шынарга тимер иде / цак цак цакылдатасың да / анарга пилтә куйалар / мамык инде ул / шелтә тигел инде ул / шының белән кабызалар // аннары сың бер бахытны шырпы цыкты инде / ул тарак шырпы дийәләр иде инде / ул мыни шындый иде / бер ни / шында ун ни / ун шырпы башы / аны кирәк цакны сындырып алалар / карубкысы йук / аның ецен идән / идәнне мышылай ышкып тыралар да / нәстә беләдер / бер агац диик инде / берсәк йалтырый тешә / шында былай иттереп ала да / кабына / ут кабына // әгәр ул шырпы куйган турыннан / бәл′әп куйалар инде кыры тырсын дип / җыгылып тешсә / бер йагы шпырр итә иде дә йана да китә иде // шырпысыз каласың // ул нәстәләр биреләләр иде талун белән // нәстәләр икәнне барын да белмим / әпәй талуны дийәләр иде / значит әпәй булгандыр инде мужыт // ну мин магазиннан анда тешеп әпәй алганны белмим / усын калхуз ашата // ул булгандыр служащийларга димә келим инде / ә шырпы белән шәкәргә[224] булгандыр ул пажалый // ну шында да сахарин бар иде / әнәй мышул тәмнесен апкат′әле дийә идек тә / улым / бәрәкәтсез бит ул / мыни бу бер пукыл′е белән бер атна тырабыз/ ә тигене бит бер ецәргә генә дийә иде // ул шәкәрне wатма keләсәң / нәстә белән дә wатып булмый иде / балта белән сугалар иде дә / зәп зәңгәр ут ыца иде йанга // зәңгәр ут ыца иде //]

*Информант: Шәрәфетдинов Рафаел Шәйхелислам улы, 1938 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[ул бахытта без сугыштан сың балалар булдык / айакка кийәргә калуш иде / естебездә куфайкы иде// кылайцында бер йырт бар иде / ышкулыбыз шул иде/ шында ышкулга йери идек куфайкыларыбызны кийеп // аннары сың шылай укыдык / сигезне укып цыктым да / аннары мында килеп укый алмадым / әтәй

[222] пукыл′ – кисәк
[223] пиц – мич
[224] шәкәр – шикәр

җыгышта йыгылып / билләрен ẅатып[225] кат′ты да/ аның урнына киттем салам зыйарга / кырга убуркыга // анда ец дүрт йыл салам зыйдым // анда эшләп йередем // аннан бик каты берсәк акца эшләп кат′тым инде / иген эшләп кат′тым/ айбагарлар[226] алып кат′а идем // шул куцат[227] минегали әбзи[228] бик каты безне алып бара иде / әлмирә белән икебезне / мәнә мама минтайыр катны / айбагарлар суга идек эштән сың / мышылай кицкырын // ай йактысында әйбер зәйә идек тә / айбагарларның башын езеп езеп сала идек тә / мыни шылай айбагар сабы белән кин′ата идек / анда ецәр мишук[229] шылай айбагар зыйып кат′а идек // акца да бирәләр иде эшләгән ецен / салам да бирәләр иде / иген дә бирәләр иде шул бахытта // шылай иттереп берсендә байып кат′тым да / әнәй мәрхум казанга йебәрде үземе / аннан җәмне[230] пал′та кийеп катт′ым инде / кызыл пал′та шул эшләгән акцаларыма / аннары сың мамык шәл алып бирделәр инде // шылай иттереп кийенеп катт′ым / плүш ескәтерләр алып катт′ым инде анда нигә бирнәгә / ул әле дә тыра әле // и аллатакайым[231] шылай// аннары сың мисәйет әбзәң[232] ышкулда җәүдәтне укытты // хазер ул безнең этәйнең туганы иде инде // хазер мында җәүдәт артыннан йери йери миңа күзе тешеп киткән // мында миңа күзе тешеп китте дә инде / бу миңа эт′ә инде // мында кемдер сизеп кат′кан / әнәй сизеп кат′кан / кызың шылай шылай / ай минтайыр әбзи эт′кән кыдагый дип / тирмәндә[233] дириктыр иде карама минтайыр әбзи // кыдагый нәстә дип эт′кән // әнәй катт′ы да/ син дир минҗамал эптәй мисәйете белән сүлисең икән цукынцык кыз дир / ырша // ул мин тигел мәтәм / укытуцы гелфийаз димен / сиңа йаңылыш эт′кәннәр димен / әнәй шылай дигәц ышанды инде аннары / аннары сың шылай мисәйет килә китә / зеңи[234] әбзәй дип инде // хазер мында / без ул бахытта цәцүгә йерибез / машиналар белән иген ташыйбыз // туктан[235] алабыз / кырга цәцүгә итәбез / шылай бер ец дүрт кыз // бара да безгә хазер/ зеңи гелфийаз кайа дип сырый // әнәй турысын эт′еп җибәрә инде мәрхум / туган кешегә / шында инде кырга эшкә дә бара иде йаныбызга // аннары сың шылай кани кани/ батырга эшкә кердем дә / батырдан эштән алды да катт′ы // мыни бак / шул асфал′т йул үәләр иде / асфал′ты салмаган әле /

[225] ẅату – авырттыру
[226] айбагар – көнбагыш
[227] куцат – этәч
[228] әбзи – абый
[229] мишук - капчык
[230] җәмне – матур
[231] аллатакайым – шаккату сүзе
[232] әбзи – абый
[233] тирмән – тегермән
[234] зеңи – җиңги
[235] тук – ындыр табагы

туфрак кына / шыннан тытты да катт′ы / мәтәм барыбер тырмыйм / китәм димен инде // шылай иттереп аннары сың киленнәре булып куйдым // аңыйнца бик каты эшкә килә идем мында / ызба йуарга / казлар йылкарга килә идем / алма[236] цыгарырга килә идем // минҗамал әнәй йаңгыз иде бит инде / әтәй белән туганнар алар // әнәй мәрхум мының белән сүләмә[237] / тигенең белән сүләмә дийә иде / ырша иде үземе / шул җигет йарый / бу җигет йарый дийә иде инде // шылай иттереп быларга килен булып тештем // әнәй мәрхум бик асыл булды / аллага шекер// бергә йәшәдек// килен булып тештем дә инде / аннары килештеләр / шылай бер ике ец пар барып килештеләр // аннары сың туйны сүләштеләр дә / туй булды// унец лау туй барды / атлар белән бардылар / биккаты йәмне урам ал′әнып бардылар // аннары сың ул инде ак туй диләр/ усы ак туй булды инде // ец кен ак туй булды / ец кендә бер биш алты тешкә алдыралар ул туйны // аннары сың дүртенце кенне ступай була/ ступайга киләләр тагы катыннар// аннары сың ул бахытта кийәү жуллыгы була иде / без кийәү жуллыгы йасамадык // ул кийәү йуллыгы нәстәмә // мыни кийәүләр бара да тигендә / ец кен тыра әнәйләр йыртында / кыз йыртында // анда инде кийәү тырган тешкә мунца йагып / белен пешереп тыралар / аннары сың кенезен кунакка йериләр алар ец кен // аннары сың инде мында кат′лар/ атлар белән / сындыкны куйып / ул кенне инде җигет йыртында бииләр / җырлыйлар / теңнә була усы шылай // аннары без инде алай йасамадык / кийәү жуллыгына бармадык / мында мисәйет абыйың үдә үткәрде // үдә шылай үткәрде // бер кенне безнең йак туганнары булды / кыдалар / табер кенне ышкуллар килде / аннары кызлар җигетләр килде // биккаты зур зур кытладылар // касс′ы караwат/ мәнә ышкулдан караwат / түгәрәк естәл / кезге мәнә // шылай иттереп кытладыар безне // аннары сың шылай кунак булгацтан петте инде/ аннары беренцене малай апкатт′ык / икенцене кыз апкатт′ык // шылай иттереп җитмеш йәшенә җиткәнне белмицә дә калдык // кас′ы арада килеп җитте //]

*Информант: Абдрахманова Гөлфияз Алләметдин кызы, 1946 елгы,*
*Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[бак / шул бал′ницка эшкә тытындым да / башта мастерскуйда эшләдем / анда ыркачалар [238] жүләдек [239] / куфайкылар йүләдек [240] // аннары сың бакшул бал′ницны эшләргә тытындым // нигезеннән тытынып естенә хатле эшләдек //

[236] алма – бәрәңге
[237] сүләмә – сөйләшмә
[238] ыркача – зур күн бияләй
[239] жүләү – тегү
[240] йүләү – тегү

шында эшләдем // шыннан пинсегә цыгып киттем // җитмеш йәшемә җиткәнне сизмицә дә калдым / шылай / бәбкәм // урамга цыгулар ул бахытта безгә бик йук иде / әнәйдән сырый идек тә / этәңнән сыра дийә иде// этәң цыгарса/ цыгасың дийә иде / этәйдән сырый алмый идем / сырасаң / цыгара иде инде / этәй мине бик каты йарата иде мәрхум / мин самый йараткан кызы идем // этәйдән сырый алмый идем / курка идем// кешләр урамда утырганны тәрәзәләрне ацып куйа идем дә / мышылай тәрәздән тыңнап тыра идем // тиге бик каты үткен кызлар кыцкырып кыцкырып / сүләп сүләп келешәләр иде / мышылай тыңнап тыра идем // шылай / аннары сың ыwак[241] кызлар/ ере кызлар бар иде ул бахытта // уwак кызлар йанына бара идек // нәстә белән айырыла сың инде алар // ай ере кызлар йанына безне кертмиләр иде бит кецерәкләрне / ыwак кызлар зыйалар иде / ыwак кызлар йанына бара идек / мышылай[242] түwен кыстырып / батинкабыз белән күлмәгебезне кыстырып // аны ник кийеп бармаганбыз инде / шылай иттереп уwак кызлар йанына йери идек // аннары сың ере кызлар зыйа башладылар // ере кызлар йанына йәшә башладылар // шылай// тезелеп утыра идек мышылай // җигетләр килгәц / бүлмәгә кереп каца идек / рәттән җигетләр утыра иде // аннары сың гармун унʹилар да инде / бер бер[243] цыгып бии идек / шылай // ул бахытта убшы[244] бийү йук / убшы мыни[245] айзар унʹи идек / айзар гелзәйем / байзар гелзәйем дип // мыни бакшылай тытынып алʹанасың / аннары сың шул алʹаңан бахытта бер кеше уртада кала / аннары ул кеше / шул айзар гелзәйемне җырлап петергәцтән / бер кешене алып / уртада алʹанып алʹанып бииләр икәү/ аннары җырның куплиты петкәцтән / берсе цыгып баса йанга / алыннан тыргань/ берсе тагы уртада кала / тагы айзар гелзәйем дип җырлап алʹанабыз да инде / тагы туктыйбыз да / такмак җырлагыйнца тагы бер кыз тагы берсен алып бии инде // аннары сың инде петкәцтән тагы бүлмәгә кереп тийәләбез // мында инде җигетләр утыралар // анда инде йезек салыш унʹи идек / тагы римин белән сугыш та бар иде анда / кулларга шылай римин белән сугып унʹилар иде инде // шындый уйыннар унʹи идек //]

*Информант: Абдрахманова Гөлфияз Алләметдин кызы, 1946 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

---

[241] ыwак – кечкенә
[242] мышылай – менә шулай
[243] бер бер – берәм-берәм
[244] убшы – бергә
[245] мыни – менә

[аннары сың шылай кецерәк бахытта акца йасап сүәк зыйып йери идек тагы бакцадан / шылай // сүәк зыйып / цүпрәк зыйып сабан туйына акца йасый идек // аннары сың берсәк нитә башлагац питумникка эшкә йери башладык // шыннан / тигеннән мында хатле килеп питумникта эшләдек // шылай айрадрум йанда // мында айрадрум иде наса / бакца башында айрадрум иде безнең нидә / йугарырак / мәнә питумникның тиге зур куаклары бар бит / шының тийагында айрадрум// анда кул′асалар да тезгәннәр бит хазер / машиналар йеретәләр иде бер бахыт // шул тештә айрадрум иде / шында самалүт тешә иде // тиге кецерәк самалютлар инде мыни / кырга дару сибәләр алар/ эшләп җериләр иде //]

*Информант: Абдрахманова Гөлфияз Алләметдин кызы, 1946 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[фәнис черкис дигән нидә служить′ итте / бик каты йәмне дир инде / йәшеп[246] йата инде / әнәй[247] дир әтәй[248] дир / мында килегез әле дир / мында урам буйы барда җимеш үсә дир / урам буйы барда арбуз дир / каwым[249] дир / килеп күреп китегез дир // баралмадык / үдә кеше йук / йаңгыз әнәйне калдырып баралмадык / шылай иттереп ике йыл служит′ итеп кат′те ул // шылай // фәнис салдатта бахытта / и алла / минсәйет шабашта / ец үгез үстерәм/ бал′ницта эшлим // цаwып барам / цаwып кат′ам / ецтә кат′ам да сыр′ саwам / сетне итеп здаwат′ итәргә иде ул бахытта // күәндә[250] белән китәм сет сдаwат′ итәргә / аннары җиде тулгыйнца кире эшне тешеп сдаwат′ итәргә бит әле / эшләгән тештә // аннары сың анда тешәм // цаба цаба цаба эшләп йери идек безнең бахытта // аннары сың фәнийә апаң казанга китте укырга // әтәңнәр белән бергә китте бугай әле ул / шул тирәләрдә укыды ахырсы // ул анда укыды // ец йыл укыдымы сың / дүртме / белмим дә инде хазер // шылай иттереп ланнарны үстердек / урнаштырдык / аллага шекер //]

*Информант: Абдрахманова Гөлфияз  Алләметдин кызы, 1946 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[аннары умбиш минут бахыт булса кат′кац / бакца башына эләккә[251] китәбез // питумник дириктырына да рахмәт йаусын / бер тытмады да / рахат′ләндерде // бер галийә белән баргац кына самый дириктырына ләккән идек // шылай //

---

[246] йәшү – чакыру
[247] әнәй – әни
[248] әтәй – әти
[249] каwым – кавын
[250] күәндә – көянтә
[251] эләк – җиләк

аннары сыӊ бал′ницта эшләдем/ ницә йыл бал′ницта эшләдем // шыннан пинсегә цыктым инде бал′ницта эшләп // бал′ницны башта строит′ иттем / нигезеннән тытынып / естенә хатле // башта кердем страител′ булып / аннары сыӊ мәскәүдән килде каменщикка укытырга / бер нык кына урыс / хазер каменщиклар куйа да инде / кызынып[252] киттек тә хәлбәрийә белән / без дә куйып карыйк әле дибез // хазер без куйабыз да инде / сез ыстарак куйасыз дир / давай эрәнегез дир / аннары безне дә укытты / каменщик булып еценце рәзрәт[253] / дүртенце рәзрәт дыкумент алдык // аннары сыӊ зур краннар килә плиталар бушатырга // аннары сыӊ страпул′щикка укыттылар / аны сүтәбез / зыйабыз кранның айакларын / былукларны бушатабыз / сүтеп зыйабыз да кран китеп бара // ирләр эше эшләдек / сыбханалла / ант// ун′ап келеп эшләгән // мескен мәрхум минҗамал әнәй тәрәздән карап тыра иде / гелфийаз кат′а / гелфийаз китә дип / цәйен кан′атып тыра иде // абитка кат′алмасам / култык астына түwенен[254] кыстырып/ ашарга итә иде // аннары аны елгерттем дә / елгертеп петмәгән / бал′ниц күцә башлады / хазер инде мин эшкә керәм димен // ницек тә булса эш // аннары сыӊ эшебез петмәгән әле / мине эшкә алдылар / эшкә алдылар да хазер / ике тештә эшлим / кендез струйкыда эшлим / теӊге симндә бал′ницта эшлим / шул эшемдә // кендез струйкыда эшлим / теӊнә бал′ницта эшлим// шылай итеп бал′ницта калдым тепләнеп / шыннан пинсегә цыктым // булды / петердем //]

*Информант: Абдрахманова Гөлфияз, Алләметдин кызы, 1946 елгы, Чувашия Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

---

252 кызыну – кызыгу
253 рәзрәт – разряд
254 түwен – төен

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕ ҮРНӘКЛӘРЕ

### ӘКИЯТЛӘР

[бер кызы бар дийә иде әни // анарны быларның ашарларына беткән дә кәрзинкә алып урманга киткәннәр // җиләк җыйарга киткәннәр // бабай үдә калган әби кызы белән малайын алып киткән урманга // анары кәрзинкәләрен тутырганнар да кайтырга цыкканнар // адашканнар / бара бара бер кецкенә генә ү күргәннәр // шыл үгә кергәннәр дә // айу белән бүре утыра икән // анан соң барганнар барганнар да // бер мужик оцраган аларга // әби инде аларга әт′кән // шыл ике баламны инде шыл аwылдан шыл нидән дигән // шыл безнең аwылга барам дигән инде // шыл әбигә ийәреп киткән инде // ир әт′кән инде // җиләкләрегезне бирсәгез дигән // сезне кертеп куйдырам дигән // әби әйткән җиләкләремне бирәм // ашатыгыз / йыртыма гына исән саw кат′арып җиткерегез дигән // җиләкләрен биргәннәр инде нужаланып җыйган җиләкләрен // анда кереп кунганнар // кунганнар да икенце кенне бу ир ийәртеп киткән инде // икенче кенне тагын бер аwылга баралар // шылай эзләп табалар инде аwылны // кайталар да инде мында кат′кацтында / тәмле тәмле инде бәрәңгеләр пешереп куйган // миц тирәсенә тезелеп утырдык та ди // бәрәңге ашыйбыз ди // бәрәңге ашаганнар кабыгын әрчеп // ызбага кергәчтен инде әпәй дә йук бернәрсә йук // су эчтек ди // шылай булган инде ул тырмыш // хәйерчелек // эләген[255] дә биреп җибәргән // тулке бала калсын живой // әкийәт булса да нәстәдер булган инде хикмәт //]

*Информант: Раҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[хәзер бер wакытта хуҗа насретдин атка атланган икән // аркага биштәрен аскан // хуҗа ник алай атланып барасың // атка аwыр бит // атыма аwыр булмасын дип артыма биштәр астым дийер икән // бер патша гаиләсе белән цыкканнар икән кырга // аның ец малайы булган // утыралар икән // җил даwыл күтәрелгән // мының хатынын дийү пәрие ырлап киткән // хәзер бу нишләргә // ылы малайы әт′ә / атка атлана да эти мин киттем әнине эзләргә ди // бу бара бара // йәм йәшел кырга җитәләр // йәшел кырга бу атны җибәрә дә ашарга тытына индебу ат // хәзер мында бер бабай акскалы килеп цыга // син ник дир минем кырыма дир атыңны җибәрдең дир // минем уҗымым йахшы үсә бит дир // әй карт бабай картлач дир // ашасын дир // сина мишәйт итәме дир // хәзер бу мыны ниндидер

---
255 эләк – җиләк

сүрә укый да ташка әйләндерә // хәзер бу кайтмый да кайтмый дир // икенче малайы китә әнисен эзләргә // бысын да шылай ук ташка әйләндерә // хәзер мының индееценцебаласы кецкенәсекитә // бу кецкенәсе бар да / атын шул ук кырга джибәрә инде// хәзер бабай тагын килеп цыга да улым дир / ник минем джиргә тагын җибәрдең индедир // и бабай дир / утыр әле йаныма дир // икәw ашыйк менә дир нәрсәләр бар дир // мин сиңа сүләрмен нинди кайгым бар дир // бу бабай утыра // менә дир оца тырган бүрегемне бирәм дир // син дир ыцып шында бар дир // син дир бу ат белән барып җитә алмыйсың дир // бу малай утыра да // кайадыр хәтле бара // син күпмедер баргац алыштырырсың дир // канатлы ат ул дир // тиз барып җитер ул дир // канатлы ат бирәләр кайадыр җиткәч // ул ыца ыца да хәзер канатлы ат дир / син миңа бик каты тытынып бар дир // анда дир // ташлар ишелер естебезгә дир // аннан анда утлар йандырырлар дир // син шыларга цыдам булсаң / әнийеңне табырсың дир // ул аның бары да үтә инде// куаклар тырнап бетерә бетен тәннәрен // бетен нине үтеп бу барып җитә // бер үгә керә бу // анда күп хатыннар нәстәләрдер анда пешереп / шылай йери тырган була // әнисен таный да бу әнисен килеп коцаклап ала // и улым дир / хәрәп булдың дир // хәзер дийү пәрие кайтып җитәр дир // мин сиңа дир менә ике гырафинада су дир // шул гырафинадагы су кец кертә тырган берсе кец бетерә тырган дир // син дир дийү пәрие кайткац дир // кец кертә тырган гырафинадан эцәрсең дир // хәзер дийү пәрие катʹып керә // фу дир / әдәм исе дир // кемдер бар ахры йат кеше дир // кайа дир эцеп алыйм әле дир // гырафинадан су эцә // аңарга инде кецен бетерә тырган суны бирәләр // ә бу малай цыга // бу мин әле дир // мин дир әнийемне алырга килдем дир // һәм кец кертә тырган суны ецә керәшергә // бер суга да бу тезгә хәтле дийү пәрие кереп китә // бу малай суга / билгә хәтле тешеп китә // бу дийү пәригә тагын суга да муйына да кадәр тешә // шылай муйынын кисеп бәрә дә // анан әниләре дийү пәриләренцә укый тырган булалар // кецкенә йымырка йымырка кебек ешкереп шылай / бондагы байлыкларны үзләренә җыйыштырып / җәймәгә утырышалар былар // анан былар хәзер кайтып җитәләр таң белән // әтигә әтʹмик әле дийеп монда әнисе катʹа да / мында алмагацлар үсеп утыра // басмаларны матур бизәп йасый // кышлар сайрый анда // күлләрдә үрдәкләр йезеп йери // әтисе иртән уйанып цыкса / мында карый бетен җир үзгәргән // кышлар сайрый // мында булмаган матур табигәт пәйдә була инде // анан бу хатыным кайткан икән малайым белән дип каршы ала инде // бик шатланышалар // бу бабай йанына барып // абыйларын да башка алай тәртипсез булмаслар/ акыллы булырлар // кеше белән зурлар белән ылылар белән грубитʹ итеп сүләшмәсләр дип алып кайта // шылай йәшәп китәләр // балаларны инде ерәткән шылай // утыртып шылай ерәтә идем // кеше килгәц балаларга әтʹә идем // кеше белән сүләшкән

wакытта сез цыгыгыз берwакытта да зурларга катышып сүләшмәгез дийә идек // шылай тәрбийәләп үстергән инде балаларны // бер аксакаллы бабай ыцрый // кызлар кайа барасыз дир // берсе әт′ә җан тынмас аwылына барабыз дир // уу бабайны инде мәсхәрә итәләр // ә йарар кызым дир // мәңге җанын тынмасын дир // тагы берсе әт′ә // син кайа барасың дир // ә икенцесе әт′ә бабай белән алай сүләшмәгез дир // ник алай сүләшәсез дир // карт бабай бит ул дир // ә еценцесе әт′ә // кит дир карт урыс дир // йермәле йукны сүләп дир // син дир гемерен буйы карт урыс белән гемер ит дир // шул кешеләр цыннап та дерес тә гемере буйы ленингыратта тырган карт урыста // тагы берсе безнең аwылда йәшәде куллары инбалид булды // бер малайы бар иде тәртипсез булды // ул малайын да үwендә тытмыйца тиленәр бал′ницына илтте // малайы әл дә тыра / әнисе үлде// гемере буйы җаны тынмады // еценцесе бик рәхәттә йәшәгәндер //]

*Информант: Хәсәнова Мәфрүзә Минегали кызы, 1950 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

## МӘЗӘК

[минзийә апа бикаты күп сүли беләсен бит син // йук // ай сүли инде ул // бер цәцәк бирәм // бирәсеңме // сиңа ләгә оранжевыйы // оранжевый тигел бит ул // жолтый // син бит тыташтырма әттен // аны инде син буташтырып бетергән // тыташтырма дир // тыташтырдым // петте // вазада бер цецек тә калмады // ни / сүләп алым әле // безнең халык ни инде / мында еч кыс катын утырганнар дир инде // берсе русски инде / берсе француженка инде / берсе ну там американка инде // хазырында // мында американка әт′ә дир инде // англичанка инде што дир инде // йук иремә ультиматум куйдым әле // әгәр миңа стиральный машина алып бирмәсә / керләрен дә умым дибәт′тем дир // ехе // карым бер кен күрмим // ике кен күрмим // еценче кенне минем стиральный машинам тыра дибәт′ә дир // и мында француженка әт′ә дир / мин дә куйам әле // ехе әт′тем // стиральный машна булмаса / керләр умим // посудомойочный булмаса / посуда йумым дибәтә дир // бер кен күрмим // ике кен күрмим // еценче кенне бар да бар // бар да урнында // и берер атна йугалганнар // күрешмиләр // урыс хатыны цыкмый икән инде мында // ха бер атнадан цыккан инде бу // ни дибәтә дир // уф // мин дә үземнекенә ул′тиматум куйдым әле дибәт′ә дир // посудомойычный булмаса / посуда йумым // стиральный булмаса / стирать итмим // әгәр ни булмаса / кухонный йахшы плита булмаса / ашарга пешермим дибәйтем // бер кен күрмим // ике кен күрмим // уң күзем ачылды дибәт′ә дир //]

Информант: Апанаева Минзиян Халиулла кызы, 1947 елгы, *Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Озын Куак авылы*

## ҖЫРЛАРДАН ҮРНӘКЛӘР

[әй алла нәстә йырлыйм икән //
утырдык түрегезгә // сезгә джырлыйм мыны //
алланың изге рәхмәте булсын үзегезгә //
килеп кердек өйегезгә
өстәлегез бик йәмле //
кулыгыз да алтын икән
аш суыгыз да тәмле //
бакчаларым йәмле була
берлегәннәрем белән //
ыцрашабыз дусларымның
бер дигәннәре белән //
күп теләкләр телим әле//
кабул булсын теләгем //
мәңге рәхәттә йәшәгез
җырым булсын йерәгем //
сандугачлар ыйалыйлар
ыйалары кыйада //
сандугач кебек сайрашып
йәшәгез сез дөнйада //
суда суда суда балыклар уйный //
сез китерсез дә йугалырсыз //
күңелләрем гел сезне генә уйлый //
китәрсез дә йугалырсыз
сезне хаман уйлармын //
сандугач була алмадым да
талыңа куна алмадым //
иртән кицен сайрый тырган
аккышым була алмадым //
быларны инде сейгәннәренә бара алмаган кызлар йырлый инде//
тырмыш бит ул тырмыш бит
тырмыш бит түгәрәк //
шыл түгәрәк эцләрендә
йәшик әле бергәләп //
хәзер искә тешми шыл // минем бик каты йазганнарым да күп иде//
сез утырткан мыйыл
йафрак йарды быйыл //
йәшел шәлен салып иңенә //

әллә сез булгангамы
әллә сез тугангамы //
 дөнйа тагы да матур күренә //
сездән башка йәм тапмам//
бергә йәшик дускайларым гемергә //
 тату булыйк бергә йәшик гемергә //
и алла беләм дә искә тешми шул //
җырлыйм әле / җырлыйм әле /
җырлыйм әле икене //
җырламас та идем икене /
 сез кызлар бик сейкемле //
җырласак та ун′асак та //
гармун кулларыбызда // алсу гелләр цәцәк атсын
джергән йулларыгызда //
җырлыйм әле җырлыйм әле
җырлыйм әле ун булсын //
ун да булсын биш тә булсын
сезнең кеңелләр булсын //
йырлыйк әле йырлыйк әле иптәшләр //
иптәшләр үзебезнеке
бәлки гайып итмәсләр //
йырласак та уйнасак та //
гармун кулларыбызда //
алсу гелләр цәцәк атсын
йегән йулларыгызга //
гармуныңны тартып ун′а
 үрләргә менгәндә дә //
ынтасым йук үлгәндә дә
гүрләргә кергәндә дә //
саwап булсын йырлаганым һәм сүләгән сүзләрем //
кыйаш кебек балкып тырсын синең кызыл йезләрең //
кыйаш кебек балкып тырсын синең балам йезләрең //
бәхет телим һәммәгезгә исәнлек һәм саwлыкны //
тигез тату йәшик / рәхәт тырмышта йәшәтүче бер хәйерле йулдашны // тырмышыгыз герләп барсын // укуыгызда уңышлар // киләчәктә ходайыбыз бирсен сиңа йахшылык // сезгә йахшы теләк теләп цын күңелдән мин калам //

*Информант: Раҗәпова Наилә Кашафетдин кызы, 1952 елгы, Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[йырлыйк әле йырлыйк әле
барыбез бергә чакта //
ызакламый таралырбыз
терлегез терле йакка //
әй алмалары
тарала да башлаган
йарым инде йатлар белән
чуала да башлаган //
урталыкларда тырасың
гел кебек бегеләсең //
гелләр кебек бегеләсең
кем ечен езеләсең //
әй алмалары тәрелкәләре зәңгәр //
кулларыма тытар идем чәчәк булсагыз әгәр //
сарафаны сарафаны элгәре //
афтаритлы кыз икәне
гәүдәсеннән билгеле //
әй алмалары тәрелкәләре зәңгәр //
кулларыма тытар идем /
чәчәк булсагыз әгәр //
урталыкларда тырасың
әл′әнмиме башларың //
сандугачка мисал килә
синең кара кашларың //
сездә аллы гелләр үсә
шау бакчалар еценд ә //
афтаритлы икәне
гәүдәсеннән күренә //
эх алмалары берлегәннәре белән //
тагын танышырсың әле
бер дигәннәре белән //
җырлыйк әле / җырлыйк әле
җырлыйк әле икене
җырламас идек икене
сез дусларым сейкемле//
уйна дустым гармуныңны /
син матур уйнасың шул //
уйнатасың / җырлатасың //

кайгымны йугалтасың //
урман буйы зәңгәр чәчәк
аны кем чәчкән икән шул //
йәш гемерне чәчәк диләр
чыннан да чәчәк икән //
урманнан барсам кайта алмыйм //
мыңлы кышлар таwышына шул //
йәш гемеремне ышатамын
чишмәләр агышына //]

*Информант: Шәрәфетдинова Сания Абделвәли кызы, 1935 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Татар Сыгыты авылы*

[йәшләр / йыр башлыймын /
күтәреп йебәрегез /
аwыр сүзләр ишетсәгез
үткәреп җибәрегез //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[синең баскан эзләреңә
мин дә китереп басам//
аннары тагын//
бас бас катырак бас/
сындыр идән тактасын/
сындырсаң идән тактасын
кийәү түли акцасын//
ад′а әт// бас әйдә бас/ сындыр идән тактасын/ бас әйдә бас/ сындыр идән тактасын// сындырсаң идән тактасын кан′аң түли акцасын //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[карыйм әле йезеңә /
карап карап күзеңә /
басыйм әле үзеңә /
карап карап күзеңә //
емет итеп басыйм әле
булмассыңмы үземә /
емет итеп басыйм әле

булмассыңмы үземә //]

*Информант: Даутова Солтания Ямалетдин кызы, 1941 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

килеп кердегез сез безгә //
тирән кара диңгезгә //
кадерле кунак сез безгә //
нинди күлмәк кийеп басым йе //
естәлләрегез тигезле //
айаклары тигез шул //
кара безнең кыдачага //
бар да матур бер тигез //
сезнең алмагачыгыз ла //
безнең сандугачыбыз ла //
сезнең алмагачыгызла //
кундыла сандугачыбыз //
быйыл йазын чәчү чәчтек //
үсәлә иген бодайым //
мәңгелеккә кыда булып //
йәшәргә йазсын хыдайым //
сез үстерсәгез улгызны //
без үстердек кызбызны //
гомерлеккә ташлашмаска //
бирешәйек кулыбызны //
гомерлеккә ташлашмаска //
бирешәйек кулыбызны /
самаwарны тиз кайната //
кайынагачның күмере //
кийәү белән йәш киленнең /
ызын ла булса гымыре //
кийәү белән йәш киленнең /
ызынла булса гымыре //
кыз баланы тапшырырга //
үзе кушкан рәсүлулла //
тыныч тырмыш / саф мәхәббәт //
теләгегез балаларга //
ир бала денйага килгәч //
сеннәт кылды рәсулулла //

йусыф белән зеләйханың
гыйшкын телик балаларга //
руза гелләре урнына
йаран геле утыртмагыз //
бирәбез сезгә руза гел /
су сипмиче кырытмагыз //

*Информант: Араева Сәкинә Хөснетдин кызы, 1937 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Озын Куак авылы*

[эчем пыша // чыгам тышка //
карим′ сайраган кышкайга //
сайраган кыш миңа карап /
сабыр итәргә куша //
сабыр ит дустым сабыр ит
сабырлык сары алтын
миндә сабыр итәм әле //
эчләрем тулы йалкын //
тамбер[256] куплеты бар да // усын[257] да җырлыйммы //
сабыр ит дустым / сабыр ит //
сабырлыкка ни җитәр //
сабыр итә белгән кешләр /
мырадына ирешә //
мырадына шул теләгенә дигән була инде ул сабыр итә белгән кешләр / мырадына ирешә // булды //]

*Информант: Араева Сәкинә Хөснетдин кызы, 1937 елгы, Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Озын Куак авылы*

[алга дибез / алга дибез //
алга таба барабыз //
алга барырга кушкан бит
безгә ленин бабабыз //
ха картайдым шул // таwыш йахшы цыкмый //
алга барырга кушкан бит
безгә ленин бабабыз //
ленин бабай васйәт әт′кән //
укырга һәм укырга //

[256] тамбер – тагын бер
[257] усын – анысын

тырыша тырыша без укыйбыз //
без алдынгы укуда //]

*Информант: Араева Сәкинә Хөснетдин кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Озын Куак авылы*

## МӨНӘҖӘТЛӘР

[бу үзе корбаннықы корбанның мөнәҗәте// корбан айында әт′әм инде шулай //
чалган корбаннарыгызны кабул булсын айа кабир//
барчабызны йахшы йакка // сал илаһым йа кадир //
корбаннарның каннарын // мизаннарга алар салырлар//
корбан чалган бәндәләрнең // каршына килеп алырлар //
туганкайым корбан чалган //
аңа да дыга кылсыннар //
кыйәмәткә шул корбаннар //
нурларга гариф булсыннар //
җиргә төшкән бер тамчы кан //
кабул булсын иман занда //
йәрдәм итсен мөэминнәргә //
цыйрат күперен узганда //
сезнең чалган корбаннарны //
бер ходайым әйләсен //
барцабызның кәлепләрен //
изге йулларга бәйләсен //
цыйратларның өсләрендә //
харап булсыннар корбаннар //
кылганыгыз кабул булсын //
тәкбир башлыйк ла туганнар //
фәрештәләр җыйылганнар //
барда тәкбир әтик дийеп //
аллаһы әкбәр аллаһы әкбәр //
wә лиллаһи әлһәмдиллиһә //
әй туганнар сыйладыгыз //
тәмлениғмәтләр белән //
ходайым цыйласын сезне//
җәннәт ниғмәтләрий белән //]

*Информант: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

кырбан мөнәҗәтләре бар инде //
корбаныгыз кабул булсын //
үле терек дога кылсын /
бу илаһи сәгәтләрдә /
иманыбыз тулы булсын //
кабул булсын күккә ашсын //
фәрештәләр каршы алсын //
чалучыбыз изге булсын //
рәсүлебез дә шатлансын //
кырбан чалып ашатасы рәсүлебез изге рәхмәткә ирешик
кертсен безне җәннәтенә //
шыгырданның урамында кырбаннарда эзләре бар //
кырбан чалган бәндәләрне йандырмам дигән сүзләре бар //]

*Информант: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Шыгырдан авылы*

[әй / туганнар беләсезме /
гымер үтә / сизәсезме //
ул гымерләр үткәннән сың
ни булганын беләсезме //
дәфтәр сызыклары буйлап
кеңлең таш булса да эрер
кыйәмәт кеннәрен уйлап //
җитәр безгә бу насихәт
аллах калебләргә салсын //
укыганнар / ишеткәннәр /
картлар/ йәшләр гыйбрәт алсын // амин //
кара җимешне ад′а әле// минем жук // ад′а бергә бергә цыга ул // мин санийә кебек тигел инде / ынытам// туксанга җитәм наса // минем күем жук / күем булса рахатләнеп җырлар идем// үләргә вакыт җиткән дип кенә тырам мин хазер //
килеп кердем ейегезгә /
кадер хермәт түрегездә //
безне хермәт иткән ецен
нур балкысын йезегездә //
диде муса бер хыдайым
җәннәт булыр микән миңа //

сиңа җәннәт булыр муса
кыз туганың риза булса //
диде муса бер хыдайым
җәннәт булыр микән миңа //
сиңа җәннәт булыр муса
кыз туганың разый булса //
диде муса бер хыдайым
җәннәт булыр микән миңа //
сиңа җәннәт булыр муса
әти әнийең риза булса //
диде муса бер хыдайым
җәннәт булыр микән миңа //
сиңа җәннәт булыр муса
тыл катынның кадрен белсәң //
диде муса бер хыдайым
җәннәт булыр микән миңа //
сиңа җәннәт булыр муса
эшләрең разый булса //
диде муса бер хыдайым
җәннәт булыр микән миңа//
сиңа җәннәт булыр муса
үз сүзләрең разый булса //]

*Информант: Айнетдинова Сания Закир кызы, 1930 елгы,*
*Чуваштан Республикасы, Батыр районы, Татар Согыты авылы*

[сабыр итик / сабыр итик // хыдай кушкан эшләргә //
кыйамәт кен җәннәт дилән //
сабырлар иткән кешләргә //
кыйамәт кен җәннәт дилән //
сабырлар иткән кешләргә //
рәсылулланың чалмасы /
җиргә тешкән дир аклыгы //
лә иләха иләллаху /
динебезнең вә паклыгы //
мехәммәде рәсулулла /
сигез җәннәтнең ачкычы //
айател керси зур айәт //
хәркем аны зурласын //

аны зурлаган бәндәләр //
аны зурлаган кешеләр
җәннәтләргә туры барсын //
бу канн′амнан эрәнеп калган шул ец йул//
аны зурлаган бәндәләр //
аны зурлаган кешеләр
җәннәтләргә туры барсын //]

*Информант: Араева Сәкинә Хөснетдин кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы,Озын Куак авылы*

## БӘЕТЛӘР
## ӘБДЕЛМӘН КУПИЧ

Әбделмән купичның тройка аты
Шыгырдан илләрендә җигәргә,
Унике пот ярым кәгазь акчам иде
Аллам насыйп итмәде биләргә.
Әбделмәк куписның аргамагы
Олы юллардан юргалый,
Әбделмәк купистан допрос алганда
Губернатор башын боргалый.
Таштан салдырдым мин ак мәчет
Шыгырдан иленә дан өчен,
Шыгырдан халкына әйтә узыгыз
Коткарсыннар Алла хак өчен.
Унике иде минем тирмәнем,
Акчам кая киткәнен белмәдем.
Әбделмәк куписны озаталар
Ике пар атлы олауда.
Әбделмән куписны сорасагыз,
Аяк-кул гынасы богауда.
Әбделмән купис таш мәчет салдырган
Сембер губернасына дан өчен,
Әбделмәк куписны Себер озаталар
Фальшивый сугылган мал өчен.

*Информант: Султеева Гөлшат Бәдретдин кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## Нуртдин бәете

1. Син утырткан алмагачтан
Өзеп алмалар алам.
Төннәр буе әллә ничә
Синең яныңа барам.
2. Нуретдин нигә болай
Бердә кайтып йөрмисең
Ник син болай итенәсең
Төшләремә кермисең.
3. Крыйлцадан төшкән чакта
Азраил каршы алдымы
Кыйблага таба яткырып
Җаннарыңны алдымы?
4. Син тышка чыккан чакта
Ник соң бергә чыкмадым
Сагынып еларлык итеп
Ник соң бер сүз әйтмәдең.
5. Базарларга барган идем
Аклы күлмәкләр алдым.
Сиңа да җиңел түгелдер
Мин бит ялгызым калдым.
6. Караваттан алдылар
Чыназага[258] салдылар.
Ике якта ике балаң
Өзелеп елап калдылар.
7. Базарларга барган чакта
Озатып кала идең
Сумкаң авыр түгелме дип
Каршы барып ала идең.
8. Син больницада ятканда
Ничә еладым икән.
Сиңа тагы яшәрлек
Көннәр булмады микән.
9. Алма ашама дидең
Мине ташлама дидең
Без үлсәк бергә үләбез
Бер дә каушама дидең.
10. Мәчетләргә бара идең
Аклы күлмәкләр киеп
Ник соң бер кат та әйтмәдең
Үләм бәхил бул диеп.
11. Комган тотып чыгып киттең
Таһәрәт алам диеп
Бер дә уйламаган идем
Ялгызым калам диеп.
12. Нуртдин барып җиттеңме
Минсәетеңне күрдеңме.
Хале ничек белдеңме
Яткан җирен күрдеңме.
13. Син бит әйтә идең
Үлем уйлама диеп.
Үзең өйдән чыгып киттең
Җиңсез күлмәгең киеп.
14. Белеп булмый җаннар чыгар
Сәфәр ниятләп тә
Бер ходаем насыйп итсен
Ирешергә җәннәттә.
15. Син утырткан алмагачлар
Бигерәк бөрелеләр
Энә күзләренә калгач
Булмады терелүләр.
16. Син бит өйдән чыгып киттең
Такталар җәям диеп
Такталар җәям дидең дә
Үләгә[259] барам диеп.
17. Син үләгә бара алмадың
Кыска булды гомерең
Сине алып киттеләр
Карап алдык тилмереп.
18. Урыны буш булгандыр

[258] Ченза – җеназа

[259] үлә – өйлә

Син үләгә бармагач
Пешкән ризыклар да калды
Сиңа ашарга язмагач.
19. Болыт астында йолдызлар
Калкалар да баталар
Алма кебек Нуретдинем
Җир астында ятадыр.
20. Мин дә хәзер барам инде
Барам артыңнан җитәм
Аерылганнар сабыр итә
Дип кенә сабыр итәм.
21. Алмалар алган идем
Чәйләргә салган идем
Хәзер мин керәм дидең
Ашап эчәрбез дидең
22. Һаваларда кошлар оча
Каурыйлары коела
Үлгәнеңә 10 көн генә
Бер ел кебек тоела
23. Зират яннан узган чакта
Мине күрми китмәгез
Мин китмәдем кайтыр хәзер
Кайтыр диеп көтмәгез.
24. Миңа бәет язарсың дип
Авторучка алдырдың.
Сагынганда карарсың дип
Карточкаңны калдырдың.
25. Җәен кояш кыздырганда
Алмалар кызыл була.
Син исемә төшәсең дә
Кыска төн озын була.
26. Ярамаган җирләргә
Костюмымны кимәгез.
Әниегез ятим калды
Ятим диеп тимәгез.
27. Җәйләр үтәр, кышлар җитәр
Озын төннәр башланыр.
Кайтып кергән чакларымда
Кемнәр мине каршы алыр.
28. Җәйләр җитте, көн җылытып
Чәчәк атты балан да.
Балаларыбыз бар диеп
Әйтә идең һаман да.
29. Чәчәк аткан гөлләремнең
Тамырын корытмагыз.
Дога кылган вакытта
Мине дә онытмагыз.
30. Башкөннәр[260] дә үттеләр
Атна кичләр җиттеләр.
Сез укыган догалар
Миңа килеп җиттеләр.
31. Агыйделдә ал кораб
Утырдым алга карап.
Бер генә сүз әйтер идем
Нурлы йөзеңә карап.
32. Аякларым өшидер
Киез итек кисәм дә.
Кошлар сайрый сагындыра
Сагынмыймын дисәм дә.
33. Син үлгәчтен бөреләнеп
Чәчәк атты балан да.
Карточкамны кулыма алып
Елап йөрим һаман да.
34. Әй чияләр, чияләр
Башмак аска ияләр.
Синнән калган киемнәрне
Хәзер кемнәр киярләр.
35. Миннән калган киемнәрне
Балаларым кисеннәр.
Кулларына тоткан саен
Бабайныкы дисеннәр.
36. Үләсеңне белгән булсам
Чыгармас идем тышка.
Туйганчы сөйләшә алмадык

[260] баш көн – дүшәмбе

Яшәдек икән бушка.
37. Айлар да үтте инде
Елларны җитәр инде.
Синең өчен генә елап
Гомерем үтәр инде.
38. Алмалар алам әле
Суыма салам әле.
Вертолет белән булса да
Күрергә барам әле.
39. Мәчетләрдән кайта идең
Канатларың җилкенеп.
Хәзер көтәр кешем дә юк
Елап яшим тилмереп.
40. Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әдилә
Азан әйткән вакытта
Синең тавышың килә
41. Кулыңдагы пирчәткәңне
Булган юасылары.
Телләремә дә кермәде
Болай буласылары.
42. Чәчемне тарыйм әле
Көзгедә карыйм әле.
Ике минутка да булса да
Яныңа барыйм әле.
43. Калган икән әле минем
Чәчләремне тарарга.
Икәү төшкән карточкаң бар
Сагынганда карарга.
44. Минем ничек яшәвемне
Ходаем үзе күрсен.
Адашмаска, саташмаска
Алла сабырмак бирсен.
45. Астым балчык, яным балчык
Чыгар идем җире юк
Өстеңдәге күлмәгеңнең
Җиңе белән якасы юк.
46. Йокларга идең син
Башларыңнан ябынып.
Мәчет юлларыннан көттем
Сине өзелеп сагынып.
47. Күпме генә көтсәм дә,
Юк кайтмыйсың, күренмисең.
Көне төне еласам да
Хәлләремне белмисең.
48. Кунакларга барган чакта
Костюмнарыңны кидең.
Соңгы кайтуларыңда
Сәхарым тугыз дидең.
49. Кисүчеләр каерсыннар
Каеннарның каерын[261].
Аерылгач кына белдем
Синнән башка авырын.
50. Мин хәзер китимме инде
Кайларга җитим инде.
Син үлдең дә китеп бардың
Мин нихәл итим инде.
51. Каз канатларын санадым
Күлләрдә коенганда.
Инде кемнәргә карармын
Мин сине сагынганда.
52. Әти үлеп китте диеп
Сез мине онытмагыз.
Сагынганда бер укырсыз
Бәетемне ертмагыз.
61. Ает[262] бәйрәмнәр җитәр
Балаларым җыелыр.
Өстәл янда син булмагач
Канны яшем коелыр.
62. Бергә яшәгән вакытта
Белмәдем лә кадерен.
Туып үскән якларыңда
Хазер синең каберең.
63. Рәшүткәләр[263] ясаттың

*261* каен каеры – каен кайрысы
*262* ает – гает

Икебезгә бер итеп.
Үзәкләремне өздең
Син мине ташлап киттең.
64. Рәшүткәләр ясатканда
Аерым ясатмыйм дидең.
Каберебез бергә булсын
Алай адашмыйк дидең.
65. Рәшүткәләр ясаттың
Ясаттың тимерләрдән.
Безнең кебек булмасын
Аерым тилмергәннәр.
66. Аланнардан өзеп кайттың
Чәчәкнең алсуларын.
Бозлы сулар да баса алмый
Йөрәгем ярсуларын.
67. Йөгереп чыктым бакчага
Өзеп алдым бер чия.
Эчем күмергә әйләнде
Йөрәгем янып көя.
68. Гөлләр үсә, гөлләр үсә
Гөлләр үсә бакчада.
Сине сатып алыр идем
Пинсе алган акчама.
69. Яшел чирәм өсләрендә
Калмаган бит эзләрең.
Каралгандыр, саргайгандыр
Синең нурлы йөзләрең.
70. Бу бәетне укыгач,
Тулдымы күңелегез.
Минеке кебек кыска
Улмасын гомерегез.
71. Син бит түбәтәйләреңнең
Төрлесен кия идең.
Әминә дия дия
Елмаеп көлә идең.
72. Саный бардым, саный кайтам
Нуртдиным каберләрен.
Бергә яшәгән вакытта
Белмәдек кадерләрен.
73. Еласам да, җырласам да
Тормыш үз кулларымда.
Фәрештәләр каршы алсын
Җәннәтнең юлларында.
74. Син бит бакчаларга чыгып
Утырттың алмагачлар.
Синең өстеңдә куакта
Сайрыйдыр сандугачлар.
75. Убый якларына карыйм
Нуртдин убый янында.
Җир асларында ятасың
Гөрләп яшәр чагыңда.
76. Нигә син үлдең икән
Кабергә кердең икән.
Анда тормыш авыр диләр
Син шуны белдең микән.
77. Зәңгәр юрганнарга чорнап
Чыназага салдылар.
Нужаланган нужаларың
Бар да төзелеп калдылар.
78. Бигрәк нужаландың инде
Йокламадың төннәрен.
Белмәдек шул бәгыремнең
Кайчак үләр көннәрен.
79. Урамнарда кайта идең
Атлап түгел йөгереп.
Үлем шулай килә икән
Килми икән сиздереп.
80. Мәчетләргә барыр идем
Кар яуган юлларыңа.
Җәннәт җимешләре булсын
Догалы кулларыңда.
81. Зиратларга барыр идем
Юлларыңда карлар бар.
Яннарыңа керер идем

---

[263] рәшүткә – рәшәткә

Яннарыңда урын тар.
82. Белми инде Нуртдинкаем
Яшьлек ничек узгандыр
Тар кабердә, салкын җирдә
Сүәкләрең[264] тузгандыр.
83. Синең белән яшәгәндә
Уйламадым барын да.
Син анда ялгыз түгел
Минсәет синең яныңда.
84. Зиратларга барыр идем
Юлларыңда алмагач.
Бер кемгә дә үпкәләмим
Үз бәхетем булмагач.
85. Кунакларга бармаганда
Барырга куша идең.
Баян көтә, ризык көтә
Бар диеп орша идең.
86. Әлениләр ясаганда
Орышып яткыра идең.
Ике җимешең булса
Берсен каптыра идең.
87. Син бу якты дөньядан
Мәңгегә киттең инде.
Дөнья хален белеп булмый
Бәхилләп киттең минде.
88. Мәңге бәхил бәгырькәем
Ашаттың да эчерттең.
Дөньялык тәмугына
Мине генә төшердең.
89. Җәйнең матур көннәрендә
Үлеп кенә киттең бит.
Ничә төшләремә кердең
Чәй эчәргә йәштең[265] бит.
90. Хәзер мин чәйләр эчәм
Ялгыз башым утырып.
Кайнар күз яшьләрем белән
Чашкаларны[266] тутырып.
91. Мунчаларны яга идең
Сулар тутыра идең.
Икәү бергә барыйк диеп
Көтеп утыра идең.
92. Күпме генә яшәсәк тә
Ялгыз мунча кермәдең.
Ялгыз мунча керәсемне
Әл дә алдан белмәдем.
93. Мунчаларга бара идек
Икәү бергә тотынып.
Кайткач чәйләр эчә идек
Кара-каршы утырып.
94. Эчең ташкан чакларда да
Бер кемгә байлыкмадың.
Үләсеңне белмәдем бит
Бәхил дип әйтә алмадым.
95. И туганнар, барыгыз да
Минем яныма килгән.
Бәхилләшеп китегез
Үлемем бер көн җиткән.
96. Аралар да ерак түгел
Сирәк килә хатыгыз.
Кичен яткан вакытта
Бәхилләшеп ятыгыз.
97. Минназыймнарга баргач
Син укыдың бит әле.
Озак тормам мин дә барам
Син дә мине көт әле.
98. Минназыймнарга барган идек
Кодаларны күрергә.
Сиңа ходай язмады
Туйларында йөрергә.
99. Алма чия виноград
Җимеш бирә көзләрен.
Нинди генә төстә икән

[264] сүәк – сөяк
[265] яшү – эндәшү
[266] чашка – чынаяк чокыры

Синең нурлы йөзләрең.
100. Сиңа язмаган булган
Калды бит пешкән ашың.
Синнән башка мин бер бөтен
Ходай булсын юлдашым.
101. Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Роза.
Ялгыз тору бигрәк авыр
Елап булса да уза.
102. Бакчадагы җиләкләрне
Чиләкләргә тутырам.
Хәзер инде бер эшем юк
Елап кына утырам.
103. Бер нәрсә дә түгел икән
Җил капка каеруы.
Бигрәк авыр булды инде
Бабамнан аерылу.
104. Без хәзер эшли алмыйбыз
Бакчаны сатыйк дидем.
Карап утырсам утырам
Мин туфрк сатмыйм дидең.
105. Бакчаларда эшли икән
Айбагар[267] ашап-ашап.
Карагатларны[268] калдырдың
Оялар ясап-ясап.
106. Җиләкләрнең араларын
Мин утадым, син бастың[269].
Җиләкләрне ашый алмадың
Җир асларына яттың.
107. Скамияләр бирә идең
 Утырып эшлә диеп.
Бар кайтып ял ит берсәк[270]
Кояшта пешмә дидең.
108. Базарларга икәү барып
Чашка алдык бит әле.
Күңелләремне юатып
Хуть бер кайтып кит әле.
109. Базарларга икәү барып
Чашка алдык бит әле.
Аннан кайтып каршы утырып
Чәйләр эчтек бит әле.
110. Нуртдин бәгырем синең гомерең
Җир җәннәтендә үтте.
Ахирәттә раббым сиңа
Җәннәтен насыйп итте.
111. Шундый яхшы көннәрне
Сиңа гына бирделәр.
Изге теләктә булганча
Канат җәеп килделәр.
112. Шундый яхшы айларда
Үлем сирәк кешегә эләгә
Азраил сине яшеп чыккан
Тәһарәт белән үләргә.
113. Агыйделдәге суларга
Каршы йөзеп булмый шул.
Синең гомерең беткән булган
Каршы көрәшеп булмый шул.
114. Иртәрәк үлеп киттең шул
Сине бик сагынабыз.
Сине Аллага ялварып,
Яхшылыгыңны Аллага саныйбыз.
115. Син үлгәчтен безгә дә
Бик авыр көннәр булды.
Мәчет юлларын таптадың
Үлемең пәйда булды.
116. Сират күперен кичәргә дип,
Корбаннар ала идең.
Аллаһыга шөкер кылып, авыз ачтырып,
Корбаннар чала идең.
117.Авырлыклар килгән чакта тормышта

[267] айбагар – көнбагыш
[268] карагат – карлыган
[269] басу – көрәк белән җир казу
[270] берсәк – бераз

Син бит Нуртдин элек киенгән.
Кайгыларны җыеп, шатлык килсә
Син бит Нуртдин элек сөенгән.
118. Дөньялары матур шундый чакта
Иртә ташлап киттең син безне.
Исән чакта кадерең алмаган булсаң
Бәхилләә инде, зинһар син безне.
119. Нуртдин туганым, нигә соң син
Бигерәк иртә киттең.
Балаларыңны һәм дә оныкларыңны
Безне дә ятим иттең.
120. Нуртдин сине яратып,
Кадерләп яшәтәсе иде.
Сау сәламәт сине күреп
Зур бәхет булыр иде.
121. Соңгы минутларга кадәр
Син яшәдең кадердә.
Инде хәзер ничек итеп
Барып йөрергә кабергә.
121. Китмәсеннәр иде бездән аерылып
Яшәсеннәр иде гел бергә.
Кайтам дигәч кайтмый калмагыз
Әнкәйләрдән рәнҗеш алмагыз.
122. Әнкәйләрнең изге теләкләрен
Мең баладан саклый алмасыз.
Әллә ниләр бирер идем
Сине бер күрер өчен.
Калганнарын әйтеп тормыйм
Үзең килгәч күрерсең.

Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылында яшәүче Султеева Гөлшат Бәдретдин кызы (1937 елгы) истәлекләр дәфтәре тапшырды. Анда урын алган бәетләрнең берничәсен урнаштырабыз.

Бәет
(Фидания һәм Минсәет Камалетдиновларның уллары фаҗигале рәвештә дөнья куя. Яшьтән үк шигырьләр язырга яраткан Камалетдинова Фидания, бердәнбер уллары суга батып үлгәннән соң, бәет яза.)

Вакыт су агымы кебек ага.
Үтә көннәр, атна, айлары.
Яшәдеңме соң син улым, әллә юкмы?
Исемең генә калды йөрәгемдә минем нибары.
Кайтмасыңны беләм, тик шулай да көтәм
Сине уйлап һаман моңланам.
Исән чакларыңны искә алып, балам,
Рәсемеңә карап юанам.
Килешә алмыйм һич тә, иртәләрен, кич тә
Бүлмәң дә буш, ятар урының да син юклыкка.
Быелгы ел сәхәр өстәле артында
Синең урыннарың бушлыкка.
Исләремнән һич тә чыкмыйсың да,
Кулларыма каләм аламын.
Шашып китмәс өчен уйлармны
Шигырь юлларына саламын.
Искә төшә, бигрәк сагындыра
Карашларың күзең тутырып.
Кара кием кигән кара кайгы
Гомерлеккә калды утырып.
Минем һәрчак күңлем моңсу хәзер,
Бик еш төшләр күрәм төннәрен.
Менә тагын, улым, сине күрдем
Һәм чыланды яшькә мендәрем.
Төшләремдә сине күрүләрем
Сагнуымны ничек басыйм соң?
Йөгереп кайтып, “Әнәй, кайттым!”- диеп,
Ник соң, улым, ишек ачмыйсың?

Ераклардан сиңа охшаш берәү күрсәм, балам
Ул кешене күзем белән каршы алам.
Һәм күземнән югалганчы
Карашларым белән озатып калам.
Дөнья нигә болай тигез түгел икән,
Кемнәр яши йөзгә җиткәнче?
Кемнәр туар-тумас борын үлә,
Кайсылары тормыш иткәнче.
Күпме яшьли өзелгән гомерләр,
Ничә Марат, Наил, Радик, Фәнис, Данияр.
Каберләрдә бала, йөрәкләрдә яра,
Һәрбер ата-ана, үзе исән чакта, баласына килеп баш ияр.
Зиратыңа, улым, кабат килдем
Дога кылыйм диеп утырып.
Кодрәтемнән килсә әгәр куяр идем
Кабереңне нурга тутырып.
Анда, салкын кабереңдә үткән,
Саныйм синең һәрбер көнең-төнеңне.
Инде синнән башка ничек үткәрербез
22 яшь тулган көнеңне.
Гомере булган кеше бер күрешә
Исәннәр бит җирдә ятмыйлар
Мәңгелеккә киткәннәрне генә күреп булмый
Үлгәннәр бит кире кайтмыйлар.
Дөнья һәрчак шулай шыксыз булыр микән?
Атмас инде безгә бүтән ал таңнар.
Бәлки теге дөньяларда гына
Очрашсалар инде бу җаннар.

*Информант: Камалетдинова Фидания, 1952 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

## МАРСЕЛЬ БӘЕТЕ

(Гимранов Марсель 2012 елда юл фаҗигасендә һәлак була.)
Быел бигрәк көтеп алдык
Уразаның гаетен,
Мин язамын, сез укырсыз
Марсель абый бәетен.

Аклы күлмәкләр эзләдем,
Эзләдем, табалмадым,
Бик яшисем килгән иде
Киттем шул, калалмадым.
Әнкәй, бәгърем, чәчләреңне
Көн дә иртән тарарсың,
Бик сагынган чакларыңда
Рәсемемә карарсың.
Әнкәй, бәгърем, нишлим инде?
Гомерем кыска булды.
Минем үлгәнне ишеткәч,
Авылга кайгы тулды.
Әнкәй, бәгърем, син елыйсың
Үкенечкә тудың дип.
Инде каршы алалмассың
Кайттың, бәгърем, улым, дип.
Әнкәй, бәгърем, ашларыңны
Чыланнарда суытма,
Балаларым янымда дип,
Мин,улыңны онытма.
Әтием, бәгърем, гаепләмә,
Төрле чаклар булгандыр.
Мин үлгәчтен күзләреңә
Кайнар яшьләр тулгандыр.
Айгел апам, Лүзиям,
Догаларны ятлагыз
Әти-әнине хөрмәтләп,
Гел янәшә атлагыз.
Авыр сезгә, дусларым,
Авыр шул, туганнарым.
Сагынып сөйләргә калды
Бу җирдә торганнарым.
Ринас дустым,берге үстек,
Уртак иде уебыз.
Бик бәхетле яшәгез сез
Матур булды туегыз.
Сезгә диеп алып кайттым
Ак күлмәкләр каладан.
Язмышны булмый үзгәртеп,

Киттем сезнең арадан.
Лүзияне, сеңлемне
Бик ярата идем лә,
Саубуллашмый чыгып киттем,
Ак күлмәкләр кидем дә.
Күңелем дә изге иде.
Нигә болай булдым мин?
Киләчәккә якты тормыш,
Зур планнар кордым мин.
Җәй көннәре җитәр әле,
Чияләр пешәр әле.
Минем исән чакларым
Исегезгә төшәр әле.
Сөйгән ярым калдың инде,
Без булдык гел янәшә.
Алдагы тормыш юлыңда
Минем өчен дә яшә.
Ник бәхетсез булдык икән,
Ник аерылды безнең юллар?
Кавышып тормыш итәргә
Сузылган иде куллар.
Сандугачлар сайрар өчен
Кирәк аларга тирәк,
Дамир белән Ильяс кебек
Дуслар дөньяда сирәк.
Зиннур дустым туегызда
Сезгә бәхет теләдем,
Сезнең туйлар үткәч кенә
Үләсемне белмәдем.
Әйтәсе сүзләр күп иде,
Әйтермен дигән идем.
Исән-сау әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.
Сау булыгыз, туганнарым
Исән-имин булыгыз.
Марсель дигән бала өчен
Гел догада торыгыз.

*Информант: Пазюкова Илүзә Ринат кызы, 1995 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

# ЗӨЛФИРӘ БӘЕТЕ

(Мәктәптә укучы Гәләутдинова Зөлфирә кизләүдән су алып кайтканда, баскычта егылып, дөнья куя.)

Бисмиллахи вә билләхи
Җитәр Корбан гаете.
Сагынганда сез укырсыз
Зөлфирәнең бәетен.
Шома яфрак, сары яфрак
Соры имәндә генә.
Минем газиз җаным чыкты
Уйнап йөргәндә генә.
Миннән калган киемнәрне
Бик чуалтып кимәгез.
Кайтыр җиргә китмәдем мин,
Кайтыр диеп көтмәгез.
Әни, җаным, бик җылама
Зинһар өчен сабыр ит.
Җәйләр җиткәч, җирләр кипкәч
Каберемне карап кит.
Иртән торып җырламадым,
Чәчемне тарамадым.
Минем сулган йөзләремне
Сеңелем карамадым.
Әнкәй, зинһар, Гөлфирәгә
Озын гомерләр телә.
Минем сылу гәүдәләрем
Вакытсыз гүргә керә.
Карлар киткәч, җирләр кипкәч
Каберемне карарсыз.
Сулар алып кайткан чакта
Үлде сезнең балагыз.
Яңа матур күлмәгемне
Сандыкларга салыгыз.
Җомга көннәрендә мине
Зинһар искә алыгыз.
Башымдагы яулыгымны
Магазиннан алдылар.
Минем сылу гәүдәмне

Җеназага салдылар.
Таеп егылып киткәндә
Бик авыртты башларым.
Унике яшьтән гүргә керде
Минем газиз башларым.
Әй, туганнар, нишләдегез
Минем җаннарым чыккач.
Берни эшләп булмый инде
Бер Ходай үзе кушкач.
Әнкәй мине сагынганда
Төрле көйләр көйләрсең.
Бик сагынган чакларда
Серең кемгә сөйләрсең.
Миннән калган киемнәрне
Сеңелем кияр, яраса.
Газиз әнкәй ничек түзәр
Карточкамны караса.
Менәр идем – тау биек,
Тешәр идем – тамырлык.
Барыгызга да авырлык
Ходай бирсен сабырлык.
Әнкәй, ашың пешеп җиткәч,
Бар да ашка җыелыр.
Алар булып, мин булмагач,
Канлы яшен коелыр.
Җомга көнне була диләр
Быел Корбан гаетен.
Сагынганда сез укырсыз
Зөлфирәнең бәетен.
Баскычлардан тешкән чакта
Егыласымны белмәдем.
Башым авыртып, хәлем беткәч,
Үләсемне белмәдем.

## ДАМИР БӘЕТЕ

(Рафиков Дамир 14 нче август көнне кичке сәгать дүрттә сугыла һәм бер ай больницада яткач, 8 нче сентябрь көнне иртән сәгать биштә үлә).
Бу бәетнең башларын
Бисмилла дип башладым.

21гә яшем җиткәч
Ашыйм больниц ашларын.
Кошлар кунган кибәнгә,
Тирбәләләр моңаеп.
Шул кошларга карап узып
Китеп бардым моңаеп.
Иртә белән иртә торып,
Чыгып киттем мин эшкә.
Арытылган кул руль томый,
Әллә ни керә төшкә.
Нәрсәдер шыгырдап яна,
Әллә көзге җил исә.
Сулыш юлларым кысыла
Яшьлегем искә төшә.
Күңел тула искә төшкән саен
Бергә булган кичләрем.
Ничек соң мин эләккәнмен монда,
Китә шуңа исләрем.
Әле кайчан гына машинамда
Кайта-китә йөредем.
Үләм диеп юлга чыктым,
Чөнки алдан төш күрдем.
Төшләремне сүли идем
Тик үземнең ярыма.
Тәнем әрни, өзелә үзәк,
Түзүләре авыр ла!
Дусларым, сау булыгыз,
Китәм инде мәңгегә.
Бу әрнүле үлемнәр
Язмасын беркемгә дә.
Хәзер инде көз җитте,
Күп кошлар очып китте.
Минем үлү давыл булып,
Авыл өстеннән үтте!
Армиядән кайтканыма
Минем әле күп түгел.
Әти-әни, бүген мине
Күрәсез соңгы тапкыр.
Энеләрем, сезгә әйтәм:

Онытмагыз мине дә.
Яшьли төшкән фотоларны
Сез саклагыз мәңгегә.
Аякка басам, дигәндә
Хәлләрем авырайды.
Ашыйм диеп, кашык тоткач,
Сулыш юлым тарайды.
Сөйгән ярым калды инде,
Калды инде ятларга.
Сагынганда искә алып
Кала фото карарга.
Кеше сүзеннән куркып,
Килмәдең син күрергә.
Барлык дуслар җыелалар
Мине бүген күмәргә.
Кәҗә урам кызларын
Күрер идем бер генә.
Никә икән больницага
Килмәделәр күрергә.
Нигә икән бу дөньядан
Бик вакытсыз китәләр?
Үлгәч кенә һәммәсе дә
Сине якын күрәләр.
Башым әрни,тәнем әрни,
Җәзаланып үләмен.
Алда булган көннәремне
Төштә генә күрәмен.

## АВТОРЛАР ИЖАТЫ

[әтийем wасыйәте //
 канлы сугыш өц баламның цугән атацын //
әй син дөнйа бу газапны күреп //
түзегес сез дип ничек әтерсез //
айырылышуларның ацы газабыннан //
йәшләр түгел күздән кан тамган //
и әнийем ике сабый / бер әбине тотып //
сабырлыкны кайдан син алган //
күз йәшләрен бер дә күрсәтмичә //

назлап назлап безне сөйгәнсең //
күрсәтмицә хәсрәт утларыңны //
һәр көн хатлар кетеп кейгәнсең //
эткәм йазган өцпочмаклы хатлар //
атна түгел айлап килгәндер //
хатын алгач чекер исән дийеп //
газиз әнкәм йылап келгәндер //
өчпочмаклы хатны йуллаганда //
балаларның хәлен сораган //
күргән тешен зур бәхеткә йурап //
джиңеп кайтуына йураган //
килгән хатларынның һәрберсендә //
безгә киңәш белем алырга //
изге күңел зур белемнәр аша //
бу дөнйада сукмак салырга //
сөйекслеләрем дийеп хатын башлап //
йәшәw көчен безгә биргәнсең //
әнийемә әбийемә балаларны укыт //
олы wасыйат сина дигәнсең //
эткәйем күңелең белән сизгән //
wасыйат булып калган сүзләрең //
канлы сугыш гумереңне езгән //
езгәләнә әле дә үзәгем //
этийем бәгрем нигә сон син //
канлы сугышка иртә киттең //
балаларыңны безне калдырып //
барыбызны да йәтим иттең //
сугыш петте ура җиңү дийеп //
бар исәннәр илгә кайттылар //
тол әниләр әбиләр күз йәшләрен түгеп //
битләренә йаwлык йаптылар //
тол әниләр бар көчләрен куйып //
тырыштылар wасыйат үтәргә //
йәтимлекне балам сизмәсен дийеп //
бар белемле кеше итәргә //
и әниләр нинди сабырлыр сез //
йөрәгегез тулы җылылык //
калган wасыйәтләрне үтәр өчен //
нитчек тапкансыз сез олылык //

и әтийем рухын бик шат булсын //
аwыр йылларда да wасыйәт үтәлде//
тол әнийем күп тырышлык белән //
зур тормошка безне әтәрде //
тыныч йыллар менә бу бәйрәмнең //
алтмыш йыллыгын китерде //
сугыш фаҗигасы тарихында //
мәңге онытылмаслык итерде //
мин шул алтмыш йыллыгына газитка йаздырган идем //
җиңү көне нинди олы бәйрәм //
без җыйылдык бәйрәм итергә //
ничек кенә аwыр йараларга //
тими генә сийләп үтәргә //
күкрәкләре орден медал белән //
күңелләре тулы изгелек //
тагын бер кат хатирәләр аша //
җиңү мәйданына килделәр //
барысының да күзләрендә сагыш һәм йәшләр //
алар чыланган күпме йакын дуслар туганнарын //
сугыш кырларында йугалган //
безгә алар өмет белән бага //
сүзсез генә карый күзләре //
саклармы дийеп без калдырган җиңү эзләрен //
гитлер кызы кара чәчен
икеләп үрер әле //
безгә күрсәткән аwырлыкны
үзедә күрер әле //
бик каты тырмыш аппардык / кирәк булса йырлаган / кирәк эшләгән / кирәк йылаган / кирәк булса җылаган да //]

*Информант: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[кайандыр йаздырып алган идем // әнинең кырык кененә багышлап йазган идем // сине бүген кырык кенең белән багышлыйм дип // мәүлед айында йахшы кендә үлдең // урның җәннәттә булсын дип телибез //

әнкәйнең аппак чәчләре агарган безнең хакка //
ул һаман матур тырды күңеле җаны акка //
бик килешә аклары да сагынам карасын да //
без агарткан чәч тә бардыр ул чәчләр арасында //

гөлләр чәчәк атсын ецен әни кирәк //
әни кирәк иң кирәкле кеше җирдә димәк //
иң кадерле кеше җирдә димәк //
өстәлләрдә җиз самаwар кан′ый //
кан′асын да кан′асын //
әткәй әнкәйне сагынып туган үгә кат′асын //
туган йортта җиз самаwар әткәй әнкәмнең тесе //
бер чынайак чәйен эчсәм арта кеңелемнең кече //
йәнәшәдә без булсак та йәши әңкәй моң зарлап //
йазмаган шул тәкдиренә гомер итәргә парлап //]

*Информант: Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

[менә салих бабай шигырен укып карыйм әле// шырт дигән аwылга баргач йазып ка′тканмидем //
салих бабай шигырләрен укыдык без барын да //
бераз эстәп йазыйм әб′әтләрен дә / зарын да //
әбиләр ей эцендә билләрендә запуны //
салып бирсә шыл запунны бетә аның законы //
әби мескен шәлперәйгән // аwызында йук тешләре
таwык чүпләп бетерә алмый аңа тигән эшләрне//
баш әл′әнеп йыгылса да аның хәлен белмиләр //
хәйләли ул карт шайтан дип // йүри кылана диләр //
йук кецеңне бар итәсең кылыну инде кайа //
бер кемдә кызганмагац кыланудан ни файда //
елгерим дип һәрберсенә абына да сертенә //
шул арада әллә кайдан кырым тийә битенә //
ашыкканда бүрекне дә артын алдына кийә //
шыңа шул килен аңа убырлы карцык дийә //
малай тапкац үстекләләп үстергән ул баласын //
ул′амаган карт кенендә килен булып каласын //
әби үзе бик шатлана кулыннан эш килгәндә /
баскан сайын шекер итә / ходай саwлык биргәнгә //
килен булу нацар тегел буыннарда кец булса //
әбиләргә уңай тегел / кул айак кылтыраса //
кайбер миһербансыз йәшләр әйдә келә белсеннәр //
шул кеннәрнең үзләренә киләсене белсеннәр //

*Информант:Ибәтова Фазилә Минегали кызы, 1937 елгы,*
*Чувашстан Республикасы, Батыр районы, Шыгырдан авылы*

Без өйрәнгән Шыгырдан, Озын Куак, Татар Согыты авылларында чүпрәле сөйләше вәкилләре яши. Әлеге сөйләшнең лингвистик үзенчәлекләре турында мәгълүмат китерелә.

## ЧҮПРӘЛЕ СӨЙЛӘШЕ[271]

Бу сөйләш хәзерге Татарстанның Буа һәм Чүпрәле, Чувашстанның Батыр һәм Канаш районнарында (элекке Сембер губернасы Сембер һәм Буа өязләре) яшәүче татар-мишәрләр сөйләшен үз эченә ала.

Фонетик үзенчәлекләр.

Чүпрәле сөйләше фонетик үзенчәлекләре ягыннан мишәр диалектының аеруча сергач һәм чистай сөйләшләре белән уртаклык күрсәтә. Шуның белән бергә, сөйләшне билгеле торган аерымлыклар да бар. Башка мишәр сөйләшләре өчен характерлы булган кайбер архаик (мәсәлән, ō, ө, э озын сузыклары, *°у, ᶿү* дифтонгоидлары, сергач сөйләшендә аерым сүзләрдәге ә ~ и тәңгәллеге һ. б. ш.) күренешләрнең бу сөйләштә күзәтелмәвен билгеләп үтми булмый.

Сөйләшнең фонетик үзенчәлекләре, башлыча, кайбер авазларның артикуляциясе үзгәрүдә, аваз тәңгәллекләрендә, аваз өстәлү һәм аваз төшүдә чагыла.

Сузыклар. Чүпрәле сөйләшендә сузык авазлар – гомумән мишәр диалектындагы кебек ук, алгырак позициядә ясала торган, әдәби телдәгедән таррак булган авазлар.

*а* сузыгы – әдәби телдән һәм урта диалекттан аермалы буларак, иренләшү төсмере булмаган аваз: *арба, балалар*.

*о – ө* ирен сузыклары, мишәр диалектындагы һәм урта диалектның аерым сөйләшләрендәге кебек иренсезләшеп, *ы–е* булып әйтеләләр: *быдай* – бодай, *телке* – төлке, *ын* – он, *сет* – сөт, *сылы* – солы һ. б.

Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле фонетик күренешләргә кайтып кала.

*Сузыклар тәңгәллеге.* ы ~ а, э (е)~ә күренеше аерым сүзләрдә табыла: *йаңы* – йаңа (яңа), *кагыз* – кәгазь, *мәктеп* – мәктәп, *күгерцен* – күгәрчен, *тырбы* – торба, *сындык* – сандык, *башты* – башта .

ы~а, э (е)~ә кушымчаларда да күзәтелә: а) хәл фигыль формаларында: *барганчы // баргынчы* – барганчы, *килгәнче // килгенче* – килгәнче; ә) *-ыр/-ер* кушымчалы фигыльләрдә: *табыр* – табар, *йаwыр* – йаwар (явар), *йазыр* – йазар (язар), *үлер* – үләр, *келер* – көләр, *үсер* – үсәр.

ә~и. Бер төркем сүзләрнең беренче иҗегендә әдәби телдәге тар *и*

---

[271] Татар халык сөйләшләре: ике китапта: икенче китап / Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, Т.Х.Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 195-207

сузыгына киң *ә* сузыгы тәңгәлләшә: *шәкәр* – шикәр, *мәләш* – миләш, *әпәй* – ипи, *әтәй* – эти, *әнәй* – әни, *бәбәй* – бәби, *песәй* – песи.

и / е / ө ~ ү бер төркем сүзләрдә сөйләшнең характерлы үзенчәлеге булып тора: *биген* / *беген / бөген* – бүген, *тигел / тегел / төгел* – түгел.

о/ы ~ у: *орлау / ырлау* – урлау, *осак / ысак* – усак, *шолай / шылай* – шулай, *шондый / шындый* – шундый.

у, ү~о, ө, ы: *бутка* – ботка, *куңгыз / куңгыр* – коңгыз, *гумер* – гомер, *карбуз* – карбыз, *йүгән* – йөгән, *йүткерә* – йөткерә.

Әдәби телдә алгы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә арткы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *йогору* – йөгерү, *котчык* – көчек, *корка* – күркә, *мачы* – мәче, *кукы* – күке, *чаука* – чәүкә, *капыста* – кәбестә, *шопшә* – шөпшә, *циклавык* – чикләвек, *шиша* – шешә, *йанаша* – йәнәшә (янәшә), *маскар* – мәсхәрә, *бар'ам* – бәйрәм.

Әдәби телдә арткы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә алгы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *кецеркән* – кычыткан, *бәлцек* – балчык, *кәрлегәч* – карлыгач.

*Сузыклар төшү.* Сүз башында сонор авазлар алдыннан килгән *о, у* сузыклары төшә: *йык* – ойык (оек), *лау* – олау, *йалу* – ойалу (оялу), *иләшү* – ийәләшү (иясләшү), *мурта* – умарта. Сузыклар төшү сүз уртасында һәм сүз ахырында да очрый: *баллый* – балалый, *кыркмыш* – кырыкмыш, *катны* – хатыны, *тәрәз* – тәрәзә, *кой* – койы (кое).

*Сузыклар өстәлү*. *ы – е* авазлары өстәлә: *ылаука* – ләүкә, *түweш* – түш, *кикерик* – кикрик, *элеке* – элек.

Дифтонглар. Чүпрәле сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, дифтонглар монофтонглаша.

*-өй* дифтонгы монофтонглашып, ү гә күчә: *ү* – өй, *сүлә* – сөйлә, *кү*– көй.

*-өй* дифтонгы, монофтонглашканда, күтәрелешләре төрле булган сузыклар арасында ирен-ирен w тартыгы барлыкка килә: *сүwәк* – сөйәк: (сөяк), *сүwәм* – сөйәм (сөям), *күwәндә* – көйәнтә (көянтә).

*-ай, -әй, -уй, -ый* дифтонглары монофтонглаша, бу очракта ике сузык арасындагы тартыклар палатальләшә: *кат'а* – кайта, *ад'а* – әйдә, *катчан* – кайчан, *ар'ан* – әйрән, *бар'ам* – бәйрәм, *кас'ы* – кайсы, *кар'ак* – кайрак, *ал'әнә* – әйләнә, *кур'ик* – койрык, *бун* –муен, *ун'и* – уйный.

*-ой, -ый* дифтонглары *-ий* дифтонгына күчә: *кийаш* – койаш (кояш), *киймак* – коймак, *кийар* – кыйар (кыяр), *сийыр* – сыйыр (сыер).

Тартыклар. Әдәби телдәгедән аермалы буларак, *к, г* авазлары сөйләштә тел арты тартыклары булып әйтеләләр*: кара* – кара, *кабак* – капка, *кагыз* – кәгазь, *йага* – йака (яка) һ. б.

х авазы, әдәби телдәге белән чагыштырганда, алгырак артикуляциядә

әйтелә: *хазер* – хәзер, *хал'* – хәл, *хабәр* – хәбәр.

Әдәби телдәге өрелмәле *ч* урынына *ц,* кайбер очракларда *тч* кушыклары да кулланыла: *цалгы* – чалгы, *пыцак – пычак, бырцак* – борчак, *цыгып* – чыгып; *катчан* – кайчан, *тчаука* – чәүкә, култча – божра, тчашкы – чынаяк, тчаршау – чаршау, тчыршы – чыршы.

Сүз башындагы һәм сүз уртасындагы әдәби *җ,* авазына *й, з, дз, дҗ* авазлары тәңгәл килә: *дзил/зил* – җил, *дзиде//зиде* – җиде, *дзыйылыш//зыйылыш* – җыелыш, *кәзә/кәдзә/кәдҗә* – кәҗә, *мерзә/ мердҗә* – мөрҗә, *эндзе/энзе/эндҗе* – энҗе, мәрдҗән – мәрҗән, баджа – бажа, джома – җомга, джәйәү // дзәйәү // зәйәү – җәйәү (җәяү), эрәнджү // эрәндзү // эрәнзү – рәнҗү, мәджлес // мәдзелес // мәзлес – мәҗлес, зил – җил.

Тартыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр авазлар тәңгәлләшүенә һәм төрле комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

б~w. Ике сузык арасында килгәндә, әдәби телдәге w авазына сөйләштә *б* тартыгы туры килә: *цыбар* – чуwар (чуар), *цыбан* – чуwан (чуан), *йыбату* – йуwату (юату), *цыбалу* – чуwалу (чуалу).

м~б: *малан* – балан, *мере* – бөре, *мәке/бәке* – бәке; б~м: *бун'ы* – муйыны (муены), *бучкы* – мичкә, *гарбун* – гармонь.

п~б. Составында саңгырау *т* авазы булган бер төркем сүзләрдә сүз башында яңгырау *б* авазы саңгыраулаша: *пыт* – бот, *пытак* – ботак, *петерү* – бетерү, *петеннәй* – бөтенләй, *пыт' пылдык* – бытбылдык (кош).

м~н берничә сүздә билгеле: *үләм* – үлән, *патмус* – поднос, *чырмау* – чорнау; н~м: *нүwеш* – диал. *мөгеш* – почмак, *неwек*– мүк, *нүгез* – мөгез, *түндәк* – түмгәк, *калын* – калым.

н~ң хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльләрдә, күрсәтү алмашлыкларында күзәтелә: *барасын* – барасың, *киләсен* – киләсең, *алырсын* – алырсың, *килерсен* – килерсең; *анарга* – аңарга, *шонарга* – шуңа, *тегенәргә* – тегеңә.

д~т. Бер төркем сүзләрдә сүз башында һәм сүз уртасында *т* авазы яңгыраулаша: *дахи* – тәки, *дустыган* – диал. *тустыган* – су чүмече, *селдәү* – селтәү, *күwәндә* – көйәнтә (көянтә), *абдырау* – аптырау, *ибдәш* – иптәш.

т~д: *тәwә* – дөйә (дөя), *тиспе* – дисбе.

з~р фигыльләрнең йөкләтү юнәлеше кушылмаларында күзәтелә: *менгез* – менгер, *кигез* – кидер, *үткәз* – үткәр, *йаткыз* – йаткыр (яткыр).

т~ч аерым сүзләрдә: *тишмә* – чишмә, *тишен* – чишен.

с~ч: *тыскан* – тычкан, *йәдәс* – йәдәч (ядәч).

й–ж. Чүпрәле сөйләше – нигездә й-ләштерүче сөйләш: *йир* – жир, *йибәр* – җибәр, *йыр* – җыр, *йәй* – җәй, *йил* – җил, *йыйылу – җ*ыелу, *йәйәү* – җәяү, *йан* – җан.

г~к. Бер төркем сүзләрдә ике сузык арасында саңгырау *к* авазы яңгыраулаша: *цигеркә* – чикерткә, *йага* – йака (яка), *тыгырык* – тыкрык, *цыгыр* – чокыр, *цугынган* – чукынган, *тугырга* –тукырга, *сигезән* – сиксән, *тугызан* – туксан. Соңгы ике мисал күбрәк өлкән буын телендә күзәтелә.

к~г. *сикез* (сигез), *тукыз* (тугыз).

к~х. Бер төркем татар сүзләрендә һәм кайбер алынмаларда да *х* авазына сөйләштә *к* авазы тәңгәл килә: *катын* – хатын, *каста* – хаста, *йакшы* – йахшы (яхшы), *джјымак* – оҗмах, *маскар* – мәсхәрә.

х~к – берничә сүздә: *wакыт//wахыт* – вакыт, *духтыр* – доктор, *тырахтыр* – трактор.

Бер сүздә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. w~г: *туwару* – тугару; г–w: *сугалчан* – суwалчан (суалчан); т~к: *кыртмыш* – кырыкмыш; н~д: *ишек алны* – ишегалды; р–л: *түр* – түл; р~й: *әрбир* – әйбер; ш~й: *шомран* – йомран; й~д: *йәшү*– дәшү; ч~т: *чөче* – төче.

*Тартыклар төшү: лт* тезмәсендәге *л* төшә: *йугату* – йугалту (югалту), *итү* – илтү, *кузгату* – кузгалту.

*г* авазы төшә: *айып* – гаеп, *аҗәп* – гаҗәп, *аләмәт* – галәмәт, *аза* – әгъза, *умер* – гомер, *сәәт* – сәгать, *асыр* – гасыр, *Атаулла* – Гатаулла, *Аптулла* – Габдулла, *джјыма/джјома* – җомга, *тирмән* – тегермән, *зеңи* – җиңги.

*т: кецеркән* – кычыткан, *цигеркә* – чикерткә, *тапау* – таптау:

*ш: алма-тилмә* – алмаш-тилмәш.

Традицион сөйләшкә хас булмаган, гарәп-фарсы алынмалары аша кергән *һ* авазы төшә: *аман* – һаман, *үнәр* – һөнәр, *Әдийә* – Һәдия, *Адий* – Һади, *йәт* – җәһәт.

Иҗек төшү очраклары: *кизитек* – кийез итек (киез итек), *астай* – абыстай, *албут* – алпавыт, *кынный* – колынлый, *куш* – куwыш.

Тартыклар өстәлү: сүз азагында *н* авазыннан соң *т* өстәлә: *фылант* – план, *крант* – кран.

Иҗек өстәлү: *алдалау* – алдау, *буwа буwалау* – буwа (буа) буу, *пыцыраwык* – пычрак, *кыстырымбый* – кыстыбый.

Ассимиляция (авазлар охшашлануы). Кире ассимиляциянең түбәндәге очраклары бар. Кайбер сүзләрдә тел очы *н* тартыгы, үзеннән соң килгән *б, л, г* авазларына өлешчә охшашлана: *умбиш* – унбиш, *умбер* – унбер, *гымбагар* – көнбагыш; *йаңгыз* – йалгыз (ялгыз), *йаңгал* – йалган (ялган), *йаңылыш/йаңгыш* – йалгыш (ялгыш).

Сүз ахырындагы *ч, ш* тартыклары тел уртасы *й* һәм яңгырау тартыклар алдында килгәндә яңгыраулашалар: *кижј булды* – кич булды, *эджј-дүрт* – өч-дүрт, *бижйыл – биш ел, алтмыж джиде – алтмыш җиде.*

Метатеза: *азбар* – абзар, *бачкыз* – баскыч, *бүрке* – бүрек, *күреш* – күрше,

*урныга* – урынга, *каулады* – куwалады (куалады), *коморычка/кымырыска* – кырмыска, *үрмәкцә* – үрмәкүч, *джцымак* – оҗмах, *сыгыз* – сызык, *элке* – элек.

Морфологик үзенчәлекләр

Исемнәр. 1 нче һәм 2 нче зат берлек сандагы тартымлы исемнәрнең төшем килеше угыз телләренә хас кушымча *(-ы/-е)* ярдәмендә дә формалаша: *китабымы* – китабымны, *битеңе* – битеңне. Мәсәлән: *Капчыгымы* (капчыгымны) *тишеп әпәйеме* (ипиемне) *бирдем. Ишег алны* (өйалды) *башымы* (башын) *йаптырыга кирәк. Кулыңы* (кулыңны) *йу да килеб утыр.*

*Алмашлыклар.* Күрсәтү алмашлыклары. *Әдәби телдәге* (менә, әнә, бу, ул, шул*)* күрсәтү алмашлыклары белән беррәттән, сөйләштә *мына, мыни, мени, муни, ана, выт, вата, вана (< рус.)* һәм зат кушымчалы *бусы, улсы, шулсы* алмашлыклары актив кулланыла. Мисаллар*: Мыни* (менә) кабак ацык, керергә була. *Вана* (әнә) шоннан апаңны йәшеп кил. *Бусы* (монысы) Бегелмәдә эшләгән. Дүрт йыл эшләде *улсы* (ансы) да. *Шулсын* (шунысын) нәстә белән кат′арырбыз. *Улсына* (анысын) ацылык кизләwе дибез.

Шул күрсәтү алмашлыгыннан ясалган *шолай, шылой, шондый, шындый, шонарга, шынарга* сүзләре чүпрәле сөйләшенә дә хас*:* Менә *шолай* (шулай) вит, Рушанийә тайым. *Шындый* (шундый) асыл кеше.

Сорау алмашлыклары. Әдәби телдәге *нәрсә* сорау алмашлыгы урынына *нәстә, нәмәрсә* алмашлыклары йөри: *Нәстә* (нәрсә) *син керми тырасын? Ашамаса, нәмәрсә* (нәрсә) *эшләтәсен аны. Караwатта йаттым, бернәстә ашамадым.*

*Нәстә* алмашлыгы ничек, нинди сорау алмашлыклары урынында да кулланыла: *Адий абыйның хале нәстә* (ничек) *сың? Пецән нәстә* (нинди), *пецән менә шоноң бийеклеге.*

Билгеләү алмашлыгы *үзебез,* гадәттә, иялек килеше кушымчасыннан башка кулланыла: *Үзебез* (үзебезнең) *иген бу, бергә эшлик. Үзебез* (үзебезнең) *капыста булмаса, Камсамулга (ав. ис.) барабыз.*

Сыйфатларның грамматик формалары, кулланылышы буенча сөйләш әдәби телдән аерылмый.

Саннарның ясалышы һәм кулланылышы сөйләштә әдәби телдәгечә.

Рәвешләр. Рәвешләрне куллану буенча сөйләш, нигездә, әдәби телгә якын тора. Шуның белән бергә, диалекталь характердагы лексик рәвешләр дә шактый: *ару* – саф; ачык, *атына* – үзенә башка; аерым, *батыр* – яхшы; нык, *бер буйли* – тоташтан, *йалан-йалан* – һаман саен, *насила* – көч-хәл белән, *нумай* – күптәнге, *маскар итеп* – кызык өчен; шаяртып, *токмаса* – бөтенләй, *тыптымат* – ныклап; җигелеп, *үзгә/үңгә* – башка төрле.

Мисаллар: *Бик ару сүләгәннәрен аңгарып була. Цаба тырганны атына үстерәләр тайны. Тенә цыктык, шулкадәр асыл кипте пецән. Беркет атына ул, тагы зур кыш, тилгән атына. Батыр йасаган бу ызбаны. Килене дә татарча белә берцәк. Бер буйли сүләүчеләр бар. Насила менәсен, тишмәбез йырак. Маскар итеп кенә әтәм. Токмаса сукыр. Тыптымат эшләргә кеше йук. Кучатлар урамы булган элеке.*

Ясалма рәвешләр, нигездә, әдәби теләдәге чаралар белән ясалалар, кайбер аерымлыклар да бар:

*-лата/-ләтә: Мурта ойадан буш күләтә* (буш көе) *чыгып китмиләр, бал белән чыгып китәләр. Цәйне кан'арлата* (кайнар көе) *эцәм. Былайлата* (болай) *булмаса бик аwыр булыр иде.*

*-лый/-лий, -чалый/-чәлий: Шушы, апама бардым кунаклый* (кунак булып). *Ирем вайнада үлде, башкалыйца* (башка) *иргә бармадым. Йәшлий* (яшь килеш) *агарды тчәтчем шоноң эцен. Гурыт дийә идек инде, бүтәнчәлий әтмибез.*

*Кышын, җәйен, кезен, йазын* вакыт рәвешләре белән беррәттән, сирәгрәк *кышны, джәйне* рәвешләре дә кулланыла: *Кицен цәй эцәрбез. Кыска саплы батинкалар киделәр кышын, йәйен цабаталар, сандаллар кийәләр иде. Кышын йылгада су туңа. Тенне суйалар иде терлекне, таң аткынчы эше бетә.*

*Кен (тен) буйы, кыш (җәй) буйы* тезмәләре белән беррәттән, *тен ката, кыш ката, кез ката, кен сәтә* кебек вакыт рәвешләре актив йөри: *Тен ката* (төн буе) *йыкламадык. Кара сыйыртчыклар йаз ката* (яз буе) *сайрилар. Куwыклы лампы тен ката* (төн буе) *йанып тора.Фигыльләр.* Затланышлы фигыль формалары.

*Фигыльләр.Затланышлы фигыль формалары. Хикәя фигыль. Хәзерге заман* хикәя фигыльнең, 1 нче зат берлек санда кыска (барам, киләм) һәм тулы (барамын, киләмен) вариантлары параллель кулланыла: *Астан тагы бер куфты кийәм, салкын булыр, дип. Эшлимен әле тагы, Алла теләсә. Казан астына ут кабызам. Йасама цәй, эцмимен, зайага китә.*

2 нче зат берлек санда хәбәрлек кушымчасының борынгырак *-сын/ -сен* варианты сакланган: *барасын* (барасың), *киләсен* (киләсең).

Хәзерге заман хикәя фигыльнең 3 нче зат берлек саны, әдәби телдән аермалы буларак, *-дыр/-дер* хәбәрлек кушымчасы ялганып ясала: *Ул цабадыр* (чаба) *минем арттан, калгысы келәми. Безнең ызбабыз куригы белән тырадыр* (тора). *Барадыр* (бара) *да братына сүлидер* (сейли).

Әдәби телдәге *ди* формасының сөйләштә *дир* варианты кулланыла: *Сиңа Казанга барырга, дир* (ди). *Саламга бардым, дир* (ди), *кицә.*

Билгеле үткән заман, әдәби телдәге кебек, фигыль нигезенә *-ды/-де* кушымчасы ялганып ясала: *бар-ды-м, кил-де-м: Гумергә акцага мохтанмадым. Мени wак-түwәк алдым.*

Шуның белән беррәттән, сөйләштә категорик үткән заман мәгънәсендә нәтиҗәле үткән заман формасы да кулланыла: *Аны без күрмәгән* (күрмәдек), *белмәгән* (белмәдек). *Мин гумер буйына ачки кимәгән (*кимәдем). *Без бер каа да цыкмаган* (чыкмадык). *Мин Норлатта булмаган* (булмадым). *Мин бер тен куwартирда кунмаган* (кунмадым).

Нәтиҗәле үткән заман, әдәби телдәгечә, *-ган/-гән* кушымчасы ялганып ясала *(күр-гән-мен, күр-гән-сең)*, аны зат һәм сан кушымчаларыннан башка куллану очраклары да бар: *Син хат йазган* (язгансың), *әле дә салмаган* (салмагансың). *Аны без күрмәгән* (күрмәгәнбез), *беренце күрүwебез.*

2 нче зат берлек санда, тау ягы сөйләшләрендәге кебек, шикләнүне белдерә торган *-дыр/-дер, -тыр/ -тер* кушымчалары еш кына төшеп кала: *Пинсийәгә чыккансың* (чыккансыңдыр) *инде син? Аwылга кат'а тыргансыз* (кайта торгансыздыр)?

Күптән үткән заман сөйләштә, әдәби телдәгечә, *-гән иде* формасын белдерелә (*барган иде, килгән иде).* Моннан тыш, сергач һәм чистай сөйләшләрендәге кебек, *-ты/-те, -ды/-де* һәм *иде* формасы кулланыла: *Тенә сүләшергә тытындык иде* (тотынган идек). *Мында йымырка хазерләү эше белән эшләдем иде* (эшләгән идем).

Дәвамлы үткән заман сөйләштә әдәби *(-а иде*) форма белән белдерелә: *Күрше катны wанә бишеген элә иде дә бун'ына, ыланны тыта. Атлар белән ташый идек келтәне, эскәмийәгә куйа идек.*

Билгесез киләчәк заман *(-ыр-мын/-ер-мен)* формасында, сүзнең нигезе *р* авазына беткән очракта, 1 нче һәм 2 нче зат берлектә һәм күплектә кушымчадагы *р* авазының берсе төшәргә мөмкин: *барымын – барыбыз, барысың – барысыз. Кышын аларга барымын* (барырмын) *дип тырам. Йарый, газит китеремен* (китерермен) *хазер.*

Билгеле киләчәк заман *(-ачак/-әчәк)* сөйләш өчен характерлы түгел. Бу форма, күпчелек татар сөйләшләрендәге кебек үк, сирәк кенә *йук* һәм *төгөл* сүзләре белән кулланыла: *Умердә дә анда баратчагым йук* (бармаячакмын), *теләдегез нишләгез, дир. Анда тыратчак төгөл* (тормаячак), *кат'ыр ул.*

Боерык фигыльнең 2 нче зат берлек саны, әдәби телдәгечә, фигыль нигезе белән тәңгәл килә: *укы, эшлә.*

Теләк фигыль. Эчке теләк (*ашыйсы килә)* сөйләштә *-гы/-ге, -кы/-ке + кели* конструкциясе белән белдерелә: *Бакцасына керсәң, цыккың келәмәс* (чыгасың килмәс). *Анда минем тыргым келәмәде* (торасым килмәде). *Киленнең кат'кысы келәмәс* (кайтасы килмәс).

Максатны, теләкне белдерү өчен инфинитивның кыскартылган *-ма/-мә* формасы һәм *кели* (< тели) ярдәмче фигыле белән ясалган конструкция кулланыла: *Заирны персидәтел куйма келәделәр* (куярга теләделәр). *Мында*

*кат'ып та кан'ашма келисеңме?* (булышырга телисеңме?) *Туры йермә кели* (йөрергә тели) *дә, эше цыкмый. Мишәртчә сүләмә келиләр* (сөйләргә телиләр), *барып цыкмый.*

Ният, максатны белдерү өчен *-рга/-ргә ит-, -рга/-ргә әт-* формаларын куллану да очрый: *Хазер китәргә итте* (китмәкче булды) *инде кийәүгә. Теннә белә маталанырга әтәм* (маташмакчы булам).

*-асы/-әсе иде, -ыйсы /-ийсе иде, -рга/-ргә иде, -рга/-ргә булган* формалары, әдәби телдәге кебек, теләкне, киңәшне, үтенечне белдерә: *Калай куйасы урынга улак куйасы иде. Суны аннан ташыйсы иде. Ул утынны ташыйсы иде. Сезгә шно берәр пешереб ашатырга иде. Башта ул'арга булган.*

Әдәби телдәге -асы/-әсе бар (юк) формасы урынына сөйләштә *-ырга/-ергә бар (юк)* формасы кулланыла: *Миңа тагы бер йыл укырга бар* (минем тагы бер ел укыйсым бар). *Минем пеән үwәргә* (өйәсем) *бар.*

Фигыль юнәлешләре чүпрәле сөйләшендә әдәби телдәгедән аерылмый. Башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, йөкләтү юнәлешендә *-гыз/-гез, -кыз/-кез* кушымчаларының актив кулланылуын билгеләп үтәргә мөмкин: *Йугары менгерсәң* (менгезсәң), *аwызы ачыла. Без умерне белми үткәзгәнбез* (үткәргәнбез). *Зур ыштанын оланга кигезергә* (кигерергә) *булган.*

Төп юнәлеш урынына уртаклык юнәлешен куллану очраклары бар: *Сабан туйына атлар йебәрешәйек* (җибәрә идек).

Фигыль дәрәҗәләре сөйләштә *-гакла/-гәклә, -акла/-әклә, -ыкла/-екла* кушымчалары белән ясалалар: *Орлакладылар* (урлаштырдылар) *кызларны да, төшеп кацалар. Мының әтәсе шылай йагада йерекли* (йөрештерә). *Казанга баргаклыйм* (баргалыйм) *мин. Суга цумырыр кабан дуңгызы, карала* (караштырып) *тор.*

*-гала/-гәлә, -кала/-кәлә* кушымчасы фигыль нигезенә яңа мәгънә өстәми: *Бер малайым бар, ул да каста, шонда туңгалаган* (өшегән). *Ырашутканы берсен түбән, берсен йугары торкаламагыз* (тотмагыз)*, дир.*

*Затланышсыз фигыль формалары.* Инфинитив. Чүпрәле сөйләшендә *-рга /-ергә* формасы төп форма булып тора (*барырга*, *килергә): Клатка гына үwәргә хазер пецәнне. Үзләре дә теләмәгәндер мында калырга. Мәзелескә барсам да мин, әтәм, ашарга килгән.*

Тамыры *р* авазына тәмамланган фигыльләргә *-ырга* кушымчасы ялганганда, кушымчадагы *р* төшә: барыга, күрегә.

Мишәр диалектының чистай, сергач сөйләшләреннән аермалы буларак, -ырга/-ергә формалы инфинитив тартым кушымчаларын кабул итми: *Мунца керергә бар* (керәсебез бар) *әле безнең. Миңа тагын бер йыл укырга* (укыйсым) *бар.*

Сөйләштә исем фигыльнең әдәби телдәге *-у/-ү* кушымчалы формасы кулланыла: *Уклаwың эзелеп төшә, кешегә керү йук. Бабайның сүләwе буйынча, башта этч йырт булган. Сүләмим дә инде, анда пецән цабу, (иге) сугу. Керәк белән басу (җирне).*

*Сыйфат фигыль*. Сөйләштә сыйфат фигыльнең түбәндәге формалары бар: *-ыр/-ер: сүләр сүз, тырыр урын; -асы/-әсе: бирәсе әйбер, суйасы каз; -ачак/-әчәк: барачак йер, күрәчәк күрмеш: Безнең тыратчак йеребез шул инде.*

*-уцы/-үце* формалы сыйфат фигыль кешегә карата актив кулланыла: *Беркем дә ит сатмый, ит суйуцы йук. Минем белән эшләүцеләр бетенесе китеп беттеләр. Сез йыклап йатуцылармы, дир.*

Сөйләштә сыйфат фигыльнең борынгы *булдаң (бул-* фигыленә *-даң* кушымчасы ялганып ясалган) формасы кулланыла *(кийәү булдаң, килен булдаң, кыда булдаң): Кийәү булдаң белән бергә кат'тылар.*

*Хәл фигыль. -ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең юклыгы әдәби телдә *–мыйча/-мийчә* формалары белән белдерелә. Сөйләштә бу функциядә *-минца /-минцә*, *-мица/-мицә* вариантлары да актив: *Ике флаг, барабан бара алыннан шаунаминца* (шауламыйча). *Лаука алдына килминцә* (килмичә) *китми ул.*

*-гац/-гәц, -гацтан/-гәцтән* кушымчалы хәл фигыльләр актив кулланыла: *Суның бу йагына цыгаргацтан* (чыгаргач), *аwыл куwат алган.* Мына бак, быралгацтан (борылгач) *ук клуб. Дҗирләребез йанаша булгацтан* (булгач), *тчуwашлар белән ду йәшәдек.*

*-ганчы/ -гәнче* кушымчалы хәл фигыльнең *-гынцы/-генце, -ганца/-гәнцә, -гинца/ -гинцә, -гынцак/- генцәк* кушымчалы вариантлары да киң таралган: *Иптәше үлгенце* (үлгәнче*) бергә йәшәделәр. Таң аткынцы* (атканчы) *кат'ып йетәрләр. Кийаш күтәрелгинцә йыклыйбыз. Син алмалар утырткинца* (утыртканчы) *таптыңмы бала?*

*-уwышлый / -үwешли, -уwынца.* Әдәби телдәге *барганда, барышлый* формалары белән беррәттән, сөйләштә хәл фигыльнең *баруwышлый, баруwынца* формалары да кулланыла: *Кат'уwышлый* (кайтышлый*) атка утырып кат'ырмын, диләр. Баруwынца* (барганда*) сезгә кере цыгармын әле. Килүwешли* (килешли) *үк безгә керде, диб әтә, дир.*

*-мастан/-мәстән (-мас өчен) формалы хәл фигыльнең өйләштә актив булуы күзәтелә*: *Терлек кереп батмастан* (батмас өчен)*, кыршап куйганнар. Идән астына пираклат куйалар идән бегелмәстән* (бөгелмәс өчен). *Быдайны кесәләренә тутыралар, ул бырылып тыра күрмәстән* (күрмәс өчен*). Шоно алып бирмәстән* (бирмәс өчен*) үземнекен бирдем.*

Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр. Чүпрәле сөйләшендә, нигездә, әдәби телдәге бәйлекләр кулланыла. Шуның белән беррәттән, аларның түбәндәге вариантлары да бар: *белә/белән* – белән: *Өстәл. йапма белә* (белән)

*йабалар тубалны.*

*Хатлем, чикле, чәке, чәкле, тәке, тәкле, тике, тиңелте, тиңентен (кадәр, хәтле): Цирта уйынында, бердән уникегә хатлем* (хәтле) *сикерәсен. Калхузга чәке* (хәтле*) арпа цәцтек. Гумер бар тиңелте* (кадәр) *саулык бирсен. Тешкә тәкле* (хәтле) *йыклады. Казарма йарты* аwыл *тәке* (кадәр) *салынган иде. Никегә тәкен* (кадәр) *бер ссәәт бар.*

*Ката, сәтә* бәйлекләре, вакыт аралыкларын белдергән сүзләр белән килеп, дәвамлы вакытны белдерә: *кыш ката* (кыш буе), *тен, ката* (төн буе), *кен сәтә* (көн буе): *Йан тартырсын кыш ката* (кыш буе). *Тен ката* (төн буе) *бардым. Кен сәтә* (көн буе*) бырцак суга идек цибагац белән*

Теркәгечләр. Сөйләштә  әдәби телдәге теркәгечләр кулланыла:  *да/дә, та/тә, ни, әле, ә , тик, әгәр дә ки: Йә калпак кийәләр туйда, йә йебәк шәл*

*Әгәр дә ки* теркәгече, әдәби тел белән чагыштырганда, ешрак кулланыла: Әгәр дә ки  *wакытында барса, күреп калыр иде. Әгәр дә ки акцам йетми икән, эшләдем.*

Кисәкчәләр. Чүпрәле сөйләшендә әдәби телдәге кисәкчәләр *(бик, инде, гына, ук, -мы/-ме* һ. б.) актив кулланылышта. Кайбер үзенчәлекләрне дә билгеләп үтәргә мөмкин.

*Бит* раслау кисәкчәсенең *вет* варианты актив. *Пецән шул кадәр асыл кипкән вет* (бит) *инде.*

Мәгънәләре ягыннан күрсәтү алмашлыкларына якын торган *мени, мыни, муни,* рус. *вана, вата* кисәкчәләре актив күзәтелә: *Муни* (менә бит) *йаңгыр туктамый.*

Кайбер синтаксик үзенчәлекләр. Иярченле кушма җөмләләрдә иярчен җөмлә баш җөмләгә аналитик юл белән бәйләнергә мөмкин: *Йәделәрне* (ав. ис.) *шонoң белән беләм, йеде гиктар йере бар иде.*

## Лексик үзенчәлекләр

Сөйләштә әдәби телдә булмаган сүзләр шактый күп. Мишәр диалекты өчен характерлы булган сүзләрнең күбесе чүпрәле сөйләшендә дә бар.

Лексиканың иң зур өлешен гомумтатар сүзләре яки тамырлары тәшкил итә. Алардан тыш, сөйләштә башка (рус, гарәп, фарсы, чуваш һәм мордва) телләрдән кергән сүзләр дә бар. Биредә диалекталь лексиканы кайбер тематик төркемнәрен кыскача күрсәтеп үтәбез.

*Йолалар, бәйрәмнәр* белән бәйләнешле сүзләр һәм сүзтезмәләр: *алаша йибәрү* – ат чабыштыру, *ара йөрү* – кодалау; яучылап йөрү, *бәби майы* – 1. балага исем кушу мәҗлесе; 2. яңа туган балага беренче тапкыр каптырыла торган май, *мәзәк* – яшьләр кичәсе; аулак өйдә үткәрелә торган кичә, *мәзәк*

*утырып йөрү* – яшьләр кичәсендә катнашу, *саwым* – туйга алып барыла торган күчтәнәчләр, туй аулагы – туй алдыннан кыз өендә үткәрелә торган яшьләр мәҗлесе, задатка – кызны килешкәч, егет ягыннан кыз ягына китерелә торган бал, чәй, акча.

*Туганлык-кардәшлекне* белдерә торган сүзләр: *әнәй – әни*, *атай//әтәй* – әти, *зур әнәй, карт әнәй* – әби; әнисенең яки әтисенең әнисе, *зур әти* – бабай, әнисенең яки әтисенең әтисе, *алыск әби* – әнисенең әнисе, *игәч//игәц – тута* – бертуган апа, *абыти – аптый – әптәй* – үзеннән олы кыз туганына эндәшү сүзе, *хәрендәш* – сеңел, *тудыкай – туганнан туган хатын-кызга эндәшү сүзе, әбзәй* – абый; абзый, ылан / олан – бала, нук – онык, оланшак – бала-чага, төп – нәсел; токым, бикәц – кәләш, бәбәй әбисе – кендек әбисе, апатем – үзеннән яшьрәк кешеләргә иркәләп эндәшү сүзе, тайым – иркәләп, яратып эндәшү сүзе, *тудык* – бергә үскән якын дуска, ахирәт дуска эндәшү сүзе.

*Кешенең тән төзелешен, сыйфатларын, халәтен* белдерә торган диалекталь сүзләр: *җаурын* – янбаш, *йәйәк* – яңак, *петәй* – түш, ими, *сын* – гәүдә, кыяфәт, *табан* – үкчә, *гузна* (< рус. козны) – тубык сөяге, *йадак* (< рус. едок) – җан, кеше саны, *акыш-макыш* – аңкы-миңке, *ардаклы* – хөрмәтле, *дәртле* – кайгылы, хәсрәтле, *дебет* – чукрак, *дыдык* – тотлыгучан, *зәwыклы* – шат күңелле, *иркәк* – сөяркә, *карсак* – тәбәнәк, *салийәтле* – сәләтле, *цирак* – җитез, *тәләй* – бәхетле, *шаукын* – паралич, *бекшенү* – күз тию, *ирегү* – сагыну, *илекмәү* – ошамау, килешмәү, *йөрәкләнү* – ачулану, *маскар иту* – шаярту, нере ыцу – чырае качу, *хыйт күрү* – интегү, *тарыгу* – мохтаҗ булу, зарлану, *эрәнҗү* – авыру, *каушау* – кабалану, ашыгу.

*Аш-су: йымшак* – бодай оныннан пешерелгән ак ипи, *йакмыш //кыстырымбый* – кыстыбый, *катлама* – каймак, сөт, йомырка салып басылган ак он камырын юка гына җәеп, тар тасмалар кисеп, шуларны трубка формасында төреп, кайнап торган майга салып пешерелгән ризык, *йука* – бодай оныннан сөт, каймак, йомыркага гына басып, юка гына җәеп майда пешерелгән камыр ашы, *питырац* – күәсне кырып җыйган камырдан әвәләнгән кечкенә ипи, *кәлҗемә* – сумса, *цәлпәк / цәцәк* – кош теле, *цыгыт* – эремчекне йомырка белән туглап табада мичтә пешерелгән ризык, эре – көрпә, *сыгыз* – сызык, *кукыл'* (< чув.) – пирог, *кагыт* – как, *ләкшә* – өйдә ясалган токмач, *кәкеш* – эремчек пәрәмәче.

*Хуҗалык, тормыш–көнкүреш* белән бәйле диалекталь сүзләр: *аран* – кыш көне маллар ябар өчен җылы абзар, *болдыр* – өйалды баскычы, *ишегалды* – өй алды, *йорт* – ишегалды, *кабак* – капка, *нешеш* – почмак, *кура* – киртә, *зәмәт* – койма, *пуграп* – кар базы, лаука – кибет, *эргә* – тышкы нигез, *фылант* – йорт урыны, *пайыт* – лапас, *суллык* – киртәлек, *себерке* – ат тырмасы, *тәртешкә* – кисәү агачы, *сийау* – шөшле, *герәплә* – кул тырмасы, *урдык* – урындык, *тезмә*

*урдык* – сәке, *эскәми* – артлы урындык, *мәдәк* – кул арбасы, *тратайкы* – ике тәгәрмәчле арба, *матик* – китмән, *церге* – киез, *пелпел /целцел* – сукыр лампы, *дустыган* – су чүмече, *күпцек* – мендәр, *шөлдөрмә* – ыргак, *балук* – бәләк, кер бәләге һ.б.

*Кием-салым: дуплы* (< рус. дубленка) – тышсыз тун, кайры тун, б*арига* – бияләй, *ыркача* – зур күн бияләй, *биш бармак, пәцәткә* – пирчәткә, *зыбын* – чикмән, *тәлпәк* – түбәтәй*, шалавар* – чалбар, *кәркеш* – чабата киндерәсе, *кылак баwы* – чабатада киндерә үткәру өчен тишек, *әлце салу* – (баш киемен) кырын салу һ.б.

*Үсемлекләр: айбагар/гымбагар* – көнбагыш, *айукамыр* – гөлҗимеш, *алма* – бәрәңге, *кырмаwык* – тигәнәк, *карагай* – нарат, *дыбраулык* – имәнлек, туйралык, *куwак* – агач, *карагат* – карлыган, *кәлшә* – коелган орлыктан яки камыл төбеннән үсеп чыккан солы, *ут* – үлән, *пәзи* - киндер, киндер сүсе, *цаукабаш* – тукранбаш, *таракан циклаwыгы* – эрбет чикләвеге*, элән* – җитен, *цәпе* – нарат яки чыршы ботагы*, паңгы* – гөмбә, *нүwек* – мүк.

*Хайваннар: болан сийры* – болан, *сырка* – байбак, *алаша* – ат, *кәнәш* – яңа туган колын, *кыртмыш* – кырыкмыш, *йарка* – бер яшьлек теше бәрән, *котчык* – эт, *тәпә* – эт баласы; көчек, *кур* – сасы көзән, *кучат* – әтәч, *кисеркә* – кәлтә еланы, *пивек* – бибек, *л'ил'ук/ цебеш* – каз, үрдәк бәпкәсе, үрмәкце – үрмәкүч, коморочка – кырмыска, йү*wеш таракан* – кыргаяк*, цигеркә* – чикерткә*, камка тутка* – камка, чуар таракан*, пугай* – кызыл таракан*, кырмыш* – шөпшә.

*Табигать күренеше*, *рельеф*: *айаз йәшен* – арыш камчылау, аҗаган, *зәрә йарылу* – таң ату, *зил калу* – җил тыну, *дуйын* – үзле балчык, балчыкка салам кушып ясалган кирпеч, *кизләү* – чишмә, *атламыш* – авылда төрле агачлар үә торган урын.

# КУШЫМТА



Чувашстан Республикасы Батыр районы Шыгырдан авылындагы йорт



Чувашстан Республикасы Батыр районы Шыгырдан авылындагы йорт



Шыгырдан авылында пешерелгән бавырсак



Татар Согыты авылында Шәрәфетдинова Сания Абделвәли кызының өендә



Чувашстан Республикасы Батыр районы Шыгырдан авылындагы капка



Чувашстан Республикасы Батыр районы Шыгырдан авылындагы капка

ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз.............................................................................................3
Чувашстан Республикасы Батыр районы татарларының җирле сөйләм үрнәкләре .............................................................................................4
Авыл тарихы, туган як турында .............................................................4
Сугыш хатирәләре .............................................................................
Ышанулар, сынамышлар ...................................................................19
Бала туу һәм балага исем кушу турында..............................................23
Уеннар, уен җырлары турында ............................................................24
Аулак өй уеннары ................................................................................28
Танышу, кияүгә чыгу, өйләнешү һәм туйлар турында .......................36
Каз өмәсе турында.................................................................................47
Күмү йоласы ..........................................................................................49
Тормыш-көнкүреш турында ................................................................50
Халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләре ..............................................82
Әкиятләр ................................................................................................82
Мәзәк .....................................................................................................84
Җырлардан үрнәкләр ............................................................................85
Мөнәҗәтләр ...........................................................................................91
Бәетләр ..................................................................................................94
Авторлар иҗаты ..................................................................................109
Чүпрәле сөйләше ................................................................................113
Кушымта ..............................................................................................125

Подписано в печать 22.12.2016. Формат 60x84 1/ 16
Бумага офсетная. Печать резографическая.
Усл. печ. л. 8. Тираж 50. Закз №2712/1

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии “Вестфалика” (ИП Колесов В.Н.)
420111, г. Казань, ул. Московская, 22. Тел.: 292-98-92
e-mail: westfalika@inbox.ru